# МӘГАРИФ

education

mәğәrif

просвещение

## ТАТАР ТЕЛЕ

№5 / 2023



Оештыручысы:
**«ТАТМЕДИА»**
**АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ**

*Яңа 2024 ел белән!*

МӘГАРИФ
education
mağarif
просвещение
ТАТАР ТЕЛЕ

25 ДЕКАБРЬ, 2023 ел

№ 5

## ЯҢА ЕЛ КОТЛАВЫ

**РАСИХА ФАИЗОВА**
МИЛЛӘТНЕ САКЛАУ ХАКЫНА СТРАТЕГИК ПЛАНГА КЕРЕРЛЕК МӘСЬӘЛӘ....5

**ФӘНИЯ ЛОТФУЛЛИНА**
ИЛСУР ҺАДИУЛЛИН: «УКЫТУЧЫЛАРНЫ ХӨРМӘТ ИТКӘН ХАЛЫКНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ ӨМЕТЛЕ!»... ...............................................................13

**КАДРИЯ ФӘТХУЛЛОВА**
ЯҢАРТЫЛГАН ФДББС ШАРТЛАРЫНДА УКЫТУЧЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ.....19

**РУЗИЛӘ ФӘТТАХОВА**
ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ ПОРТРЕТЫ..........23

**РАМИЛӘ СӘГЪДИЕВА**
ЯҢА БУЫН ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ............26

**ГӨЛЧӘЧӘК ТАҖЕТДИНОВА**
ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ «ЭШ» ШИГЫРЕН ӨЙРӘНҮ.........................30

**ВЕНЕРА ФӘСАХОВА**
СҮЗ ЯСАГЫЧ ҺӘМ ФОРМА ЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР...............................34

**ГӨЛҮЗӘ ҖӘЛӘЕВА**
ӘЙТҮ МАКСАТЫ ЯГЫННАН ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ...........38

**МИЛӘҮШӘ АЛЕКСЕЕВА**
ЛЕКСИКОЛОГИЯ. СҮЗНЕҢ ЛЕКСИК МӘГЪНӘСЕ......................................43

**ЗИЛӘРӘ ГЫЙРФАНОВА**
ТУГАН ТЕЛЕМ – ИҢ ТӘМЛЕ ТЕЛ...........................47

**АЙСЫЛУ МӨХӘММӘТОВА**
УКУ ЭШЧӘНЛЕГЕН ҺӘМ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮДӘГЕ АЛЫМНАР.........54

**ГҮЗӘЛ ДӘҮЛӘТШИНА**
ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘРНЕ КАБАТЛАУ...................................57

**РАУШАНИЯ КӘБИРОВА**
КИТАП ЯЗМЫШЫ – ХАЛЫК КӨЗГЕСЕ............60

**НУРФИЯ ЮСУПОВА**
ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕ ҺӘМ БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ИМТИХАНЫ...................................................65

**ЭЛЬМИРА СӘЛАХОВА**
ЛЕВ ТОЛСТОЙ БЕЛӘН АРАЛАШКАН ТӘТЕШ МӨГАЛЛИМЕ...72

**НУРФИЯ ЮСУПОВА**
ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕ ҺӘМ БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ИМТИХАНЫ...................................................76

**ӘЛФИЯ ЙОСЫПОВА, ГӨЛНАЗ ГАЙНУЛЛИНА**
ГАЛИМӘ ФӘҺИМӘ ХИСАМОВА...........................................83

**АЛСУ СӘФӘРОВА**
ТӘНКЫЙДИ ФИКЕРЛӘҮНЕ ҮСТЕРҮ ТЕХНОЛОГИЯСЕ АЛЫМНАРЫ................87

**АЙСЫЛУ ХӘЙРУЛЛИНА**
ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЦИФРЛЫ РЕСУРСЛАР.............89

**ЛАРИСА ИСМӘГЫЙЛОВА,**
ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫКНЫ ҮСТЕРҮ.................92

12+

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА».**
Телефон редакции: (843) 222-06-09
Адрес издателя:
420097, г.Казань,
ул. Академическая, 2
www.magarif-uku.ru

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.
**Эл № ФС 77 – 59204**

Периодичность выхода – 1 раз в квартал.

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

Почтовый адрес:
**420066, г.Казань, а/я 47**
**e-mail:** magarif@bk.ru

**Адрес:** 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе, а/т 47
**E-mail:** magarif@bk.ru
**Сайт:** magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2023 ел

Баш мөхәррир: **Таишева С.Н.**
Чыгаручы мөхәррирләр:
**Фаизова Р. Г., Сабирҗанов Т. А.**
Әдәби редактор: **Газизова И.М.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Вёрстка: **Халитова Э.И.**

*Беренче тышлыкта:*
*Коллектив журнала «МАГАРИФ»*
*Юлия КАЛИНИНА фотосы*

*3, нчы битләрдә Сөмбел Таишева фотолары*

Журналда кулланылган фотосурәтләр «Мәгариф» редакциясе архивыннан алынды.

*Журнал распространяется бесплатно.*

1




# ЯҢА ЕЛ КОТЛАВЫ

# 110 ЕЛЛЫК «МӘГАРИФ»КӘ СЫЕНЫП

Зыялыларның зур катламы – укытучылар, мәктәп директорлары, галимнәр, балалар бакчалары мөдирләре, тәрбиячеләр, китапханәчеләр, музей хезмәткәрләре өчен чыгарыла торган һәм республикабызда мәгариф сәясәтен алып баручы бердәнбер басма булган «Мәгариф» журналы быел үзенең 110 еллык юбилеен билгеләп үтте.

Ел гомумән коллектив өчен уңай килде дип әйтә алабыз. Иң мөһиме журнал укучыларыбыз безгә тугры калды. «Авыл укытучысы» бәйгесе унынчы тапкыр үзенең җиңүчеләрен атады. Актанышның Сәләтле балалар гимназиясендә Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, А. Халиков исемендәге Археология институты, Актаныш муниципаль районы белән берлектә «Кама аръягы татарлары тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүнең актуаль проблемалары» дигән темага форум уздырдык. Республикада Авыл укытучылары форумы шулай ук «Мәгариф» журналы редакциясе тәкъдиме белән үтте дип әйтә алабыз.

Бөтен дөньясына Интернет баш булган хәзерге глобальләшү заманында «Мәгариф» янәшәсендә «Мәгариф. Татар теле» кебек электрон басма булу шулай ук үзен аклый. «Мәгариф. Татар теле» ана телебезне үстерү, саклап калуда үз сүзен әйтә килә һәм шул ук вакытта ул татар теле укытучыларын, галимнәрне бер урынга туплый.

Якынлашып килүче 2024 елда да бергә-бергә булып, бер максатка эшлик! Яңа ел хезмәтегездә яңа уңышлар, шатлык-сөенечләр, гаиләләрегезгә иминлек, татулык алып килсен! Сау-сәламәт булыйк!

Зур ихтирам белән,
«Мәгариф» журналы коллективы

2



# МИЛЛӘТНЕ САКЛАУ ХАКЫНА СТРАТЕГИК ПЛАНГА КЕРЕРЛЕК МӘСЬӘЛӘ

*«Мәгариф» журналы редакциясе әдәбият-сәнгать әһелләре катнашында «Яңа мәктәпләргә – лаеклы исемнәр» дигән темага түгәрәк өстәл уздырды. Әлеге чарага әзерләнгәндә, без кайсы мәктәпләр нинди исем йөртә икән дип барлап чыктык. Мәктәп, гимназия, лицейларга килсәк, Г. Тукай, К. Насыйри, Ф. Аитова, Н. Лобачевский, М.Җәлил, А. Алиш, А. Умеркин, Б. Кузнецов кебек күп кенә шөһрәтле исемнәргә тап булабыз. Музыка мәктәпләребез П.Чайковский,*

*Ә. Бакиров, Р. Яхин, А. Ключарёв, Ж. Фәйзи, М. Хәбибуллин, Ф. Шаляпин, С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, О. Лунстрим кебек исемнәрне йөртсә, балалар сәнгать мәктәпләре, көллиятләр исә Х. Якупов, Б. Әлменов, М. Хәйретдинов, Н. Фешин белән чикләнә. Бөекләребезнең исемнәрен мәңгеләштерүнең әһәмияте турында барган сөйләшүдә сүз, мәктәпләр белән генә чикләнмичә, урам, китапханәләрне, элмә такталарны, һәйкәлләрне дә колачлады. Бу теманы күтәрүебез очраклы түгел, моңа этәргән алшартлар шактый саллы.*

**Сөмбел ТАИШЕВА,** *«Мәгариф» журналының баш мөхәррире – «Татмедиа» АҖ генераль директоры урынбасары:*

– Редакция почтасына Казандагы «Галәм» дип аталучы мәктәпкә Туфан Миңнуллин исемен бирергә кирәк, дигән һәм моның өчен җитди дәлилләр китерелгән хат килеп төште. Хат уңаеннан без әлеге мәктәпнең директорына чыктык, бер журналистыбыз анда барып та кайтты. Хатны бер үк вакытта ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына һәм шәһәр мәгариф идарәсенә дә юлладык. Аннан: «Бу мәктәпнең инде исеме бар», – дигән җавап алдык. Шуңа да карамастан мәсьәлә безнең өчен ачык калды, чөнки барыбыз да күреп тора, соңгы вакытта гына да күпме яңа мәктәпләр ачылды. Җәй көне Буаның берничә мәктәбендә булдык. Мәгариф идарәсе җитәкчесе белән очрашкач, ул: «Бездә Р. Сәгъдиев исемендәге мәктәп бар. Без нигә аның исемен йөртергә тиеш, ә Ушинский исемен түгел?» – дигән иде. «Р. Сәгъдиев – бөек галим, безнең татарның исемен бөтен дөньяга таныткан шәхес. Аның чыгышы Буа ягыннан. Әйдәгез, булган әйберне җимерергә генә тормыйк, яңа мәктәп төзелгәч, аңа Ушинский исемен тәкъдим итәрсез», – дидем. Дөрес, исем алу җиңел генә башкарылмый. Ул күпмедер көч таләп итә. Бу бер мәктәп директоры гына башкарып чыга торган эш тә түгел. Бәлкем, безнең сүзебез тиешле урынына барып җиткән очракта, алга таба мәктәпне ачканда ук, бу мәсьәлә хәл ителер дигән фикердә без. Шуңа күрә дә бу очрашуның нәтиҗәсе итеп Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов исеменә мөрәҗәгать әзерләргә дигән тәкъдим бар.

**Расиха ФАИЗОВА,** *«Мәгариф» журналының баш мөхәррир урынбасары:*

– Сүзне соңгы вакытта гына К.Насыйри исемен алган 80 нче мәктәптән башласак, аның директоры Роберт Мансуров белән шушы арада гына сөйләштем. Ул әлеге процессның ничек барышы белән кем генә мөрәҗәгать итсә дә уртаклашырга




әзер булуын белдерде. Дөресен әйтергә кирәк, ул мәктәп эшкә ныклы әзерлек белән тотынды, мәгърифәтченең сынын эшләттеләр, аның исеме белән бәйле бәйге, конференцияләр уздырылды, ут күршесе К.Насыйри музее белән уртак проектлар булдырылды, стендлар эшләнде, күргәзмәләр оештырылды. «Бу эштә бер бик мөһим нәрсәне искә алырга кирәк, мәктәпкә исем бирергә уйлыйлар икән, ул шәхес балаларга һәрьяклап зур үрнәк булырга, исем уку йортының киләчәктәге эшчәнлегенә юнәлеш бирерлек булырга тиеш», – дип белдерде директор.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,** *Татарстан Республикасының халык шагыйре:*

– Бу – бик четерекле әйбер. Исем бирелгән икән, монда бернинди шик тә булырга тиеш түгел, баш иеп китәрлек булсын. Әйтик, Бакый Урманченың яисә Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхинның скверы бар икән, моңа берәү дә каршы килә алмый. Мондыйларны сайлау җиңел түгел. Исем мәсьәләсен топономик комиссияләр хәл итә. Безнең Казанның үзәге – чып-чын рус шәһәре. Туристлар еш йөри торган үзәкнең татарлыгы бик чамалы, кеше күзенә күрсәтердәй җирләрнең барысына да «тамга» салынган. Татар дөньясына электән үзәктә рәт булмаган инде, үзегез беләсез. Яңа бистә

тирәләрен тузган йорт дип сүтеп-җимереп бетерделәр. Мин инде уйлап куям, җитәкчелекнең, Рәисебезнең аларны карарга вакыты да юктыр, ә әйтик, Н. Фишман, О. Балтусова кебек ярдәмчеләре татар дөньясы дигәндә нәрсә белә соң? Аларны гаепли дә алмыйм, әмма бит «Бу йорт шуныкы, әйдә, аңа элмә такта куябыз» дигәндә, эш шундыйлар кубызына бара. Жуковский урамындагы почмакта Фатих Әмирхан яшәгән йорт бар. Шуны гел әйтеп киләм: әйдәгез, эшлик инде дип. Дөрес, шәһәр мэры килеп, биредә Ф.Әмирханга бер почмакмы, бүлмәме булачак, дип карап киткән. Урамнарда Шамил Усмановка бер такта эленгән, Сәхибҗамал Волжскаяга бар... Бетте. Юньле-рәтле йорт булса, «бусы фәләннеке, бусы фәләннеке» дип бөтенесенә мөһер сугылган. Безнең язучыларның урамнары юк дип әйтеп булмый. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Һ. Такташ, С. Хәким кебек классикларыбызның исемнәрен йөртүче урамнар байтак. Мин фәлән кеше исемендәге урам кирәк дип дөрләп кабынмыйм хәзер. Шулай да без үз тәкъдимнәребезне әйтергә тиештер дип уйлыйм.

Безнең халык нигәдер бөтенесен чыгарып атарга бик мастер. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы артистларның костюмнары, күлмәкләрен таба алмыйсыз. Мин моны нигә әйтәм, язучылар бакыйлыкка күчә, талантлы язучылар гаиләсендә варислары булмый икән юньләп, шалт, Мөхәммәтҗан, әйберләрен чыгаралар да аталар.

**Зиннур МАНСУРОВ,** *Татарстан Республикасының халык шагыйре:*

– Без белем йортларына, мәдәният учреждениеләренә, теге яки бу олуг шәхеснең исемен кушабыз икән, ул инде– үзебезнең җирлеккә казык кагу дигән сүз. Аның мәгънәсен аңлыйсыз: бу безнең территория дигәнне аңлата. Без теге яки бу мәктәпкә асыл шәхесебезнең исемен кушабыз икән, ирексездән, анда бер почмакмы, музеймы оештырыла. Монда безнең татар халкының мирасы җыела башлый. Безнең халыкның мирасы яндырылган, урланган, таланган. Затлы исем биреп, без шул мирасны җыябыз. Бу гаять зур әһәмияткә ия, чөнки шушы юл белән барып кына, без үзебезнең халыкның менталитетын саклый алабыз. Яшь буынга шушы шәхес ярдәмендә без үзебезнең татарлыгыбызны сеңдерәбез. Тукай исемендәге гимназия дибез икән, ул үзеннән-үзе, дәрес бирмәсәң дә, сүзсез рәвештә балаларга 24 сәгать дәвамында аңлатып тора. Туфан Миңнуллин исеме дә, бернинди өстәмә чыгымнар таләп итмичә, тәүлек буе балаларга тәрбия бирә. Минем игътибар иткәнем бар, Тукай исемендәге гимназиягә килгән балалар үзләрен башкача тота башлый. Бу – тәрбия дип атала. Алар үсә-үсә әлеге исемгә лаек булырга тырышалар.

Исем кушуга безнең ислам дине дә зур әһәмият биргән. Бу – төбенәчә бик аңлап бетерә алмый торган гамәл. Исем кушылган мәктәпнең язмышы үзгәрә башлый, бу аның тәкъдиренә үтеп керә һәм

киләчәк үсешенә уңай йогынты ясый. Миңа ике елдан артык Ерак Көнчыгышта яшәргә туры килде. Байтак шәһәрләрдә һәм Татар бугазында булдым. Минем бер дустымның: «Балтыйк буенда Татар күле бар, шуннан алып Татар бугазына кадәр безнең ата-бабаларыбыз яшәгән», – дип әйткәне бар. Ул җирләрдә байтак кына татар-төрки исемнәре әле дә саклана. Болар – безнең казыклар. Кызганыч, соңгы елларда күп кенә мәктәпләребез рус мәктәпләренә әверелде. Татарча укытуны ата-ана ихтыярына калдырып, бик зур хата эшләнде. Киләчәктә без мәктәпләрне милләтебезгә якынайтырга тиешбез. Казык кагып, бу безнеке дип ачыктан-ачык әйтергә тиешбез. Шәһәрдә, район үзәкләрендә генә түгел, авыллардагы лаеклы мәктәпләргә дә безнең әдәбият-сәнгать әһелләренең исемнәрен бирергә кирәк. Шәхсән үзем укыган мәктәптән генә дә, мактанып әйтүем түгел, өч Тукай бүләге лауреаты чыккан, андый мәктәпләр бар. Мамадышның Шәйхи Маннуры, Буаның Зәки Нурие, Әлкинең Нәби Дәүлие, Актанышның Гамил Афзалы, Яшел Үзәннең Мәхмүт Хәсәновы бар. Без бары тик шәхесләр тирәсенә тупланып кына телебезне дә, милләтебезне дә саклый алабыз. Апас районында, әйтик, бер мәктәпкә Шәүкәт Галиев исеме бирелде. Исеме бирелгәч, аның музее да үзеннән-үзе төзелде. Безнең районда да Камил Вәлиев дигән академик бар. Кечкенә генә, караңгы гына авылдан чыккан шәхес– дөньякүләм танылган академик, Ленин премиясе лауреаты. Нигә ул укып чыккан мәктәпкә яки район үзәгендәге бер мәктәпкә аның исемен бирмәскә. Бик кирәкле, милләтебез өчен мөһим тема күтәрелә бу түгәрәк өстәлдә. Бу – безнең милләтебезне саклау юнәлешендәге стратегик планга керерлек мәсьәлә.

**Расиха ФАИЗОВА:**

– Бу мәсьәләдә безнең рәссамнарыбыз, сынчыларыбыз да һәрдаим үз сүзләрен әйтә килә. Рәссамнар арасында тарихи шәхесләребезгә, әдәбият-сәнгать әһелләренә, мәгърифәтчеләргә багышлап тулы серия-ләр эшләүчеләр дә шактый.

**Рөстәм ГАББАСОВ,** *сынчы:*

– Монда 80 нче мәктәп директоры телгә алынды. Ул Кукмарада эшләгәндә дә андагы гимназиягә Чыңгыз Айтматов исемен бирдертү өчен тырышып йөреп, әдипнең әнисе Нәгыймә ханымга һәм кечкенә Чыңгызга һәйкәл куйдырган иде. Мемориаль такталарга килсәк, алар безнең шәһәрдә бик аз. Алар әлегә бөтен шәхесләребезне дә колачлый алмый. Сыннарны да зур итеп куярга булыр иде. Хөкүмәт моны эшләргә бик ашыкмый. Кечкенә генә такта куйганда да бик зур алышлар аша узарга туры килә.

**Рабис СӘЛАХОВ,** *Татарстан Республикасының халык рәссамы:*

– Гомумән алганда, болар барысы да мәдәниятебезнең тамырына кайтып кала. Проблема бер Казанда гына түгел. Шәхесләрне барлап, кем каян чыккан, шуларны әзерләп куеп, исемлек төзеп куйсак, отачакбыз. Безнең сәнгать мәктәпләребезгә

килсәк, биредә өч исем генә телгә алынды: Харис Якупов, Байназар Әлменов, Мәснәви Хәертдинов. Болар – халык рәссамнары булган шәхесләр. Мәснәви агай– шунда яшәп, Лениногорск сәнгать училищесын күтәргән, шуңа гомерен багышлаган кеше. Никадәр шәкертләре бар аның! Илдар Зариповның әйбәт кенә галереясы бар иде – бетте бит. Галерея түгел инде ул хәзер. Бу гаять әһәмиятле проблема, аны бер тапкыр күтәреп чыгу гына түгел, һәрдаим күз уңында тотарга кирәк. Алабугада да өч рәсем мәктәбе бар. Дөрес, 1 нче Балалар сәнгать мәктәбе И.И.Шишкин исемен йөртә. Әнә бит Чаллыда, Азнакайда, Түбән Камада исемсез мәктәпләр күпме? Мәктәп кенә димәгән, көллиятләр, театрлар бар.

**Сөмбел ТАИШЕВА:**

– Ике әйбергә тукталам. Соңгы вакытта без Әлмәттә дүрт мәктәп турында яздык. Анда бик көчле инженерлык лицее бар, шулай ук «Адымнар»да булдык. Икесенең дә исемнәре юк. Шул ук вакытта Риза Фәхреддин исемендәге татар гимназиясен җитәкләүче Фирүзә Галиуллина белән дә очраштык. Бик сәер, әмма ремонт ясаганда аларга диварлардагы милли орнаментларны калдырырга рөхсәт итмәгәннәр. Мәктәп директоры район башлыгы белән сүзгә килеп булса да, ул бизәкләрне калдырган һәм шул ук вакытта Р. Фәхреддиннең «Гыйлем алу – эшләрнең иң олысы һәм теләкләрнең иң газизе» дигән сүзләрен дә яздырган – бу бер.

Икенчесе, берничә ел элек мин «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйковка кердем һәм: «Безнең баш мөхәррирләр Кырымда булмаганнар, әйдәгез, мөмкинлек барында барып кайтыйк», – дидем. Риза булды һәм оештырырга кушты. Кырымга киткәнче, Казанның антиквар кибетләрендә булып, заманында ике-өч ел гына эшләп калган нәшриятларның берсендә 1915 елда Гаспринский фотосурәте белән чыккан открытка тапкан идем. Аны музейга бүләк иттек – билгеле музей хезмәткәрләре өчен бу зур яңалык булды. Юл йөреп кайткач, Зөһрә Акчуринага һәм Исмәгыйль Гаспринскийга уртак бер һәйкәл куярга кирәк дигән тәкъдим белән Президент Аппаратына чыктык. Аннан безгә бер кеше дә җибәрделәр. Берничә тапкыр очраштык та, ләкин без тәкъдим иткән проспектка «Фестиваль проспекты» дигән исем бирелде. Әлеге идея тормышка ашкан очракта, ул бик тирән мәгънәгә ия буласы иде, чөнки нәкъ шулчакта Татарстан һәм Бакчасарай арасында үзара багланышлар турында килешү дә төзелгән иде. Тәкъдим рәвешендә генә калмасын иде мондый башлангычлар. Менә мин Рабис Магалимович белән килешәм, чыннан да исемлек төзеп җибәрергә кирәк. Барлык районнар буенча шәхесләребезне барлау җиңел эш булмас, әмма аны булдырганнан соң да, безгә тагын бер кат очрашырга һәм югарыга мөрәҗәгать әзерләргә кирәк булачак.

**Зиннур ХӨСНЕТДИНОВ** *(әдәби псевдонимы Зиннур Хөснияр), язучы, «Сәхнә» журналы редакторы:*

– Исем алуның бернинди

катлаулылыгы юк, әгәр дә республика Рәисенә хат язып, шуны ничектер уздырып була икән, аның имзасы, ихтыяры булган очракта, аны бөтен оешмалар йөгерә-йөгерә эшләячәк. Рәисебез Рөстәм Миңнехановның мондый милли мәсьәләләргә, тәрбия мәсьәләсенә мөнәсәбәте бик позитив икәнен беләбез. Казанда 169 мәктәп бар. 90 нчы елларда шуның 50 се татар гимназиясе исемен йөртә иде. Хәзер алар 38 гә калды. Безнең язучылар, рәссамнар, композиторлар арасында 38 генә дә түгел шәхесләребез. Безгә, бәлкем, әлеге мәктәпкә шул конкрет шәхеснең исемен бирик дип чыгаргадыр. Аннан без мәктәпләр белән мавыгып китеп башка ягын да онытмыйк. Хатыны Руфинә ханым сөйләве буенча, мин Казанда урамга Нурихан Фәттах исемен алу тарихын беләм. Башкарма комитет каршындагы комиссия тәкъдимне кире кага, һәм шуннан соң, акыллы кешеләр киңәш биреп, алар күренекле кешеләрдән имза җыялар. Хәзер «Салават Күпере» торак комплексында бер тирәдә Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах исемендәге урамнар бар. Бүгенге көндә Яшел Үзән белән Казан арасында тулы бер шәһәрчеккә нигез салынып ята. Монда яңа урамнар, мәктәпләр, сәнгать мәктәпләре булачак. Менә шуларга баштан ук үзебезнең милли исемнәрне бирү турында әйтәм мин монда. Гел язучы, композитор гына дибез икән, без кайбер шәхесләрне төшереп калдырырга мөмкин, әйтик, Садри Максуди.Бүгенге көндә Садри Максуди кебек шәхесебез әлегә юк. 1953 елда ике төрекне һәм аны Төркия президентлыгына кандидат итеп тәкъдим итәләр. Төрекләрнең бөтен юридик документларын эшләгән галим, җәмәгать эшлеклесе. Тагын килеп, ни өчен Казандагы «Адымнар» мәктәбенә Әмирхан Еники исемен бирмәскә, ди. «Адымнар» хәзер бик күп.

**Зиннур МАНСУРОВ:**

– Исем бирү объектларын барлаганда, безгә китапханәләрне дә онытмаска кирәк.

**Зиннур ХӨСНЕТДИНОВ:**

– Татарстанда 1556 китапханә бар. Боларның бик сирәгендә генә исем бар. Балык Бистәсе районының Юлсубино авылында Равил Фәйзуллин исемендәге мәктәптә әдипнең музееn ачтылар, ә нигә район үзәгендәге китапханәгә аның исемен бирмәскә, ди. Мамадышның үзәк китапханәсенә нигә бүген үк халык шагыйре Зиннур Мансуров исемен бирмәскә?! Бу – тәрбия, ә тәрбия милли компонентсыз була алмый. Биектауда әнә 5 нче яңа мәктәпкә Максудилар исемен биргәннәр.

**Марсель ГАЛИЕВ,** *Татарстан Республикасының халык язучысы:*

– Мин Парижда йөргәндә, гид сөйләп бара машинада: «Менә сез Людовик XIV, Мопассан, Бальзак яшәгән шәһәрне күрәсез», – ди һәм дүртенче итеп Рудольф Нуриевны әйтә. Мин шаккатып калдым. Борынгы классикларны санаганнан соң, әле кайчан гына яшәгән милләттәшебезнең исемен атый. Европаның мөнәсәбәте икенче– талантларга карата. Безнең Кремль янында да гидлар бик күп йөри. Минем алар белән йөри алганым юк, әмма татар

тарихын белеп сөйләмиләрдер дигән шигем бар. Ярым йорты яки безгә каршы сөйлиләрдер. Журналистлар барып, халык белән тыңлап, шуларга бер анализ ясасалар иде, дим. Читтән килгән кешегә безнең тарихны бирүчеләр бит гидлар. Аннан Парижда Сталинград урамы, метрода Сталинград станциясе бар. Руслар үзләре бу исемне үзгәртте, французлар үзгәртик димәгәннәр. Соңгы вакытта күп кенә һәйкәлләр куелды. Татарның кулы ташка тисә, таш та курка дип әйткән сүзем бар. Нишләптер һәйкәл ясый белмибез без? Кем кабул итә, аларны белми дә, күрми дә калабыз.

**Рабис СӘЛАХОВ:**

– Совет заманында комиссиясез, сәнгать советыннан башка плакат та үтми торган инде. Хәзер тендер диләр. Зәйдә пластиктан ясалган һәйкәл яндымы? Ул бит чүптән ясалган иде. Менә кая илтә ул тендер.

**Марсель ГАЛИЕВ:**

– Татарның бөтен биналарын үзәктән куу бара. Татар театрын да читкә җибәрмәкчеләр. Югыйсә әле без кайтып кына килә идек бит үзәккә. Урын җитмәсә, каршыдагы йортны алырга була бит астан юл ясап. Кемдер өскә һәрвакыт үз фикерен әйтеп торырга тиеш. Чөнки беркем беркемнән зарланмый, мәгънәсез бер битарафлык туып бара. Екатерина патша 2 млн яһүдне безнең илгә керткәч, тегеләргә җир биреп карыйлар. Эшкәртмиләр, кабаклар ача башлыйлар. Ике гасыр буена патшаны гел бимазалап үзләрен канәгатьләндермәгән нәрсәләрне җиткереп торалар яһүдләр, ә без дәшмибез.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН:**

– Казанда берәр китапханәгә Әбрар Кәримуллин исеме бирелсә, бу бик мантыйк гамәл булыр иде, ул исем ябышып торыр иде аңа. Ул китап галиме бит.

**Зиннур ХӨСНЕТДИНОВ:**

– Равил абыйга өстәп, балалар бакчалары турында әйтәсем килә. Башың буталып бетә: 99 нчы, 11 нче... Ул бакчаларның берсенең дә исеме юк. Исемле булса истә калыр иде. Анда тәрбияләнгән баланың гомер буе исендә калачак.

Рабис СӘЛАХОВ:

– Казан Экспода Илһам Шакиров исемендәге концерт залы бар. Мин анда Илһам Шакировның күзгә бәрелеп торган музей-почмагын күрмим. Анда җырчыбызның барельефы, аның турында мәгълүмат булырга тиеш.

Сөмбел ТАИШЕВА:

– Бәлкем, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм республикада яшәүче халык-
лар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышын әлеге темага багышларга тәкъдим итәргәдер.

**Илһам БАЙТИРӘК,** *композитор:*

– Теге яки бу конкурсны Җәүдәт Фәйзи мәктәбе оештыра дигәндә, барысы да истә кала. Фәләненче мәктәп дигәндә, чыннан да кайда әле ул дип бутала башлыйсың. Соңгы елларда шуңа игътибар итәм: мәктәпләрдә театр куябыз, дип актёрлар йөри. Шабашниклар, ике артист була инде ул. Бөтен мәктәптән сеанслап акча җыялар. Үзләре сценариен яза, үзләре әллә каян музыка эләктереп ала, әмма эчтәлегенә килсәк, бернинди

тәрбияви нәрсә юк. Мин шундый берничә спектакльне караганым булды. Хәзер бит патриотизм тәрбияләргә кирәк. Бу хакта бөтенләй уйлау юк. Шул 30 минутлык «спектакльләр» рекорд куя.

**Илнар ФӘЙЗЕТДИНОВ,** *дирижёр, композитор:*

– Бакыйлыкка күчкән композиторларның ноталары саклансын дип, мин аларны компьютерда җыя барам. Бу эшне Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә үк башлаган идем, хәзер инде ансыз яши дә алмыйм. Мин аларны Композиторлар берлеге архивына тапшырам. Киләчәктә безнең Композиторлар паркы булырга тиеш. Татарстан Рәисе вәгъдә итте. Анда безнең 11 яки 15 композитор кергән стенд яки бюстлар куелачак.

Без хәзер таралган мирасны электрон форматта җыябыз. Безгә Татарстанда милли музыканың электрон китапханәсе бар диләр. Мин аны күргәнем юк. Яшь кеше милли китапханәгә Фәйзине тыңларга дип килә икән, менә сиңа кушымта, телефоныңны ач, теркәл, анда бөтен нәрсә бар – менә шулай булырга тиеш, чөнки яшьләр бүген телефонда, Интернетта. Бүген яшьләр белән эшләү мөһим.

**Раиф ЗИННӘТУЛЛИН,** *Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы:*

– Бүгенге көндә татар мәктәпләренең байтагы диярлек исемле, әмма бер нәрсә шикләндерә. Гадәттә, мәктәпләрдә татар теле укытучылары йөреп, музей да оештыра, конференцияләр, семинарлар уздыралар. Күпмедер вакыттан ул лаеклы ялга китә дә аның белән бергә эш тә китә. Мәктәпләрдә белем, тәрбия бирү төрлечә куелган. Моны да уйларга кирәк, әгәр дә мәктәп артта сөйрәлә икән, аңа атаклы язучының исемен бирү матур булырмы? Трибунадан тәнкыйть сүзе белән телгә алыну – язучыны зурлау түгел. Исем бирүдә аерым шәхесләр дә зур роль уйный. Ф. Аитова исемен бирдертергә йөрүчеләрнең берсе – тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Тәэминә апа Биктимерова булды. Т.Миңнуллинның да аны ачтыруда, яңа бина төзетүдә хезмәте искиткеч зур. Шуңа да карамастан бер мәктәпкә ике исем биреп булмый. Бүген без әдәбият-сәнгать әһелләренә күбрәк тукталдык. Шул ук вакытта безнең укытучыларыбыз да бар. Алар исемен йөрткән мәктәпләр бик аз. Балтачта Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган мәктәбе бар. 184 нче гимназия Мирза Мәхмүтов исемен йөртә. 102 нче – Устинова, 122 нче гимназия Жанетта Зайцева исемнәрен йөртә. Исем биргәнче, коллектив, үзе бу эшне башлап йөреп, моңа омтылырга тиеш. Билгеле, сезнең белән килешергә дә мөмкин, шулай да өстән генә исем төшерү ничек була икән? Эшләп китсә ярый да шул юнәлештә. Оптимизация башлангач, бөек шәхесләр чыккан авыллардагы мәктәпләрне саклап калып булды. Авыл мәктәпләренең 99 проценты исемсез. Бервакыт 25 ел директор булып, шушы мәктәптә эшләде дип, директорларның исемнәрен бирә башладылар. Күпмедер вакыт узгач, мәктәпне үзгәрттеләр дә, исем дә югалды. Мондый нәрсә булырга тиеш түгел.

**Расиха ФАИЗОВА**




# ИЛСУР ҺАДИУЛЛИН: «УКЫТУЧЫЛАРНЫ ХӨРМӘТ ИТКӘН ХАЛЫКНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ ӨМЕТЛЕ!»




*Бүген авылларда күпме укытучы эшли, аларның хәле ничек? «Авыл укытучысы – 2023» конкурсы җиңүчеләрен кайчан котлаячаклар? Шушы һәм башка сорауларга җавапны Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин журналистлар белән еллык йомгаклау матбугат конференциясендә җиткерде.*

«Уку-укыту елы, гадәттә, майда тәгәлләнә, Чынлыкта мәгариф өлкәсендә ел нәтиҗәләрен без август аенда ясыйбыз», – диде министр, журналистларны үз дулкыннарында уйларга көйләп. Ул сүзен матбугат хезмәткәрләренә мәгариф темасын һәрдаим яктыртып барулары өчен рәхмәтен белдерүдән башлады һәм аннары ел дәвамында мәгариф өлкәсендә башкарылган эшләр, хәл итәсе мәсьәләләр турында сөйләде. Очрашуда 2024 елда республикада төзеләчәк мәктәп һәм бакчалар, инженерлык сыйныфлары, балаларның өйдә белем алуы, дәреслекләр, татар телен укыту, тәрбия мәсьәләләре дә, яшь белгечләр һәм кадрлар әзерләү хакында да сүз кузгатылды. Шулай ук министр Татарстанда ачылачак Мәгариф музее һәм Укытучы скверы турында да сөйләде.

## УҢЫШЛАРЫБЫЗ ТУРЫНДА

– 2023 елда Россия күләмендә берничә һөнәри конкурс узды, аларда безнең республикадан да педагоглар катнашып, җиңү яулады. Бу бәйгеләрнең

максаты – алдынгы мәктәп укытучыларын, тәрбиячеләрне ачыклау, аларга ярдәм итү, үсешкә-камиллеккә дәртләндерү, аларның педагогик тәҗрибәсен тарату һәм укытучы хезмәтенең абруен күтәрү, – дип сөйләде Һадиуллин. Алар арасыннан Казанның 41 нче мәктәбе татар теле тәрбиячесе Айсылу Лотфуллина, 13 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алинә Шәгәрәева, «Иннополис лицееның» математика укытучысы Арман Костанян, 101 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Юлия Токмакова һәм башка педагогларның исемнәрен аерым атап үтте.

Министр мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадаларында җиңүчеләр һәм призёрлар саны буенча Татарстанның инде берничә ел дәвамында лидерларның берсе булып калуын да билгеләп узды. Безнең төбәктә сәләтле балаларны ачыклау һәм алар белән эшләү өчен барлык шартлар да тудырылган. 2014 елдан Республика олимпиада үзәге эшли, ул Татарстан Республикасында олимпиада хәрәкәте координаторы булып тора. Мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасының өч этабында ел саен 250 меңнән артык бала катнаша. Республика укучылары даими рәвештә илебезнең олимпиада хәрәкәтендә алдынгы урыннарны били.

**Мәктәпләр төзү турында.** Быел Татарстанда барлыгы 10 меңгә якын укучыга исәпләнгән 11 мәктәп ачылган. Министр мәгариф учреждениеләре киләчәктә дә 2023 елгы темп белән төзеләчәген әйтте.

– Киләсе ел өчен рәсми рәвештә расланган исемлек юк. Әлегә фикер алышулар бара. Якын арада Татарстан Рәисе тарафыннан карар кабул ителүен көтәбез. Беренче чиратта, Лаеш районы Усад авылында мәктәп төзелергә тиеш. Шулай ук Лаеш районы Сокуры авылында 1224 урынга мәктәп корылу көтелә. Биектау районы Чернышевка авылында 1224 урынга яңа мәктәп, ә Питрәч районы Көек авылы мәктәбенә 600 урынлы янкорма төзеләчәк.

«Балалар бакчаларына килгәндә, аларның Казанның «Салават Күпере» микрорайонында, Лаеш районы Сокуры, Олы Кабан, Комлы Кавал авылларында, Яшел Үзән районы Васильево бистәсендә, Биектау районы Шигали авылында, Питрәч районы Царёво бистәсендә төзелүе көтелә», – диде Илсур Һадиуллин. 2024 елда Казанның «Горки», «Весна» һәм «М 14» торак комплексларында да яңа мәктәпләр ачылыр дигән өметен белдерде.

**Инженерлык юнәлеше турында.** Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы 2023 елда мәктәпләрдә инженерлык сыйныфлары ачуга аеруча зур игътибар

биргән. Министр сүзләренчә, бу юнәлешкә эш бирүчеләр, кече һәм урта эшмәкәрлек тә җәлеп ителә.

– Быел «Уңыш» дигән концепция кабул иттек. Аның максаты – икътисадның бөтен тармаклары өчен кадрлар әзерләүне мәктәптән башлау. Инженерлык класслары ачуга аеруча зур игътибар бирдек. Мәсәлән, быел аэрокосмик, аграр класслар, физика-математика, химия-биология фәннәрен тирәнтен өйрәнә торган сыйныфлар ачтык. Бу юнәлешкә эш бирүчеләрне, кече һәм урта эшмәкәрлекне дә җәлеп итәбез, чөнки бөтен тармакларда да кадрлар кытлыгы сизелә, – дип сөйләде Һадиуллин.

**«Авыл укытучысы» бәйгесе турында.** Быел «Мәгариф» журналы редакциясе тарафыннан ТР Мәгариф министрлыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә үткәрелгән «Авыл укытучысы» конкурсы үзенең 10 еллык юбилеен билгеләп үтә. Шул нисбәттән, «Мәгариф» журналының баш мөхәррире Сөмбел Таишева министрның игътибарын авыл укытучылары мәсьәләсенә дә юнәлтте. Аның сүзләренчә, әлеге бәйгедә дистә ел дәвамында Татарстаннан һәм илебез төбәкләреннән, аерым алганда Башкортстан Республикасы, Ульян, Оренбург, Пенза өлкәләре, Пермь краеннан 2600 гә якын укытучы катнашкан. Җиңүчеләрне котлау тантаналары ТР Дәүләт Советында, Казан Ратушасында, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы бинасында узды.

– Бүгенге көндә «Авыл укытучысы» конкурсында көч сынашкан мөгаллимнәребезнең тагын да зуррак уңышларга ирешүләре аеруча сөендерә. Узган ел әлеге конкурста Балык Бистәсе районы Яңа Арыш авылыннан Руслан Нәбиуллин беренче урынга чыккан булса, быелгы җиңүчеләр арасында ир-ат укытучыларның саны тагын да артты, алар дүртәү булдылар. Елдан-ел әлеге бәйгегә ир укытучыларның да игътибары арта бара, быел алардан килгән гаризалар саны да чагыштырмача күбрәк иде, – дип билгеләп үтте баш мөхәррир үзенең киңәйтеп бирелгән соравында.

Илсур Һадиуллин сүзләренчә, Татарстанда барлыгы 36 мең авыл укытучысы бар. Шуларның 87 проценты – хатын-кыз, калган 13 проценты – ир-атлар. Министр авыл укытучыларның эшчәнлеген үстерүдә һәм аларның абруен күтәрүдә әлеге конкурсның әһәмиятен билгеләп, киләчәктә аны тагын да зуррак масштабларда дәвам итәргә кирәклеген әйтеп үтте. «Авыл укытучысы» конкурсының җиңүчеләрен бу елның башында министрлыкта кабул итеп, аларны, Укытучылар һәм остазлар елына нәтиҗә ясаганда, зурлап котларга вәгъдә бирде.

**Туган телне укыту турында.** Илсур Һадиуллинга туган

телебезне укыту буенча да сорау бирелде. 2023 елда Татарстанда ничә процент ата-ана туган тел буларак үз баласына татар телен сайлады? Татарстанда, туган телләрне укытмаучы мәктәпләр бармы? Татарстанда татар телендә укытучы мәктәпләр күпме? Министр алдына төрле матбугат чараларында эзләүче журналистлар тарафыннан шундый катгый сораулар куелды. Әмма, аяныччка, кайбер сораулар ачык калды.

– Республикада бүген укучыларның 63 проценты татар телен өйрәнә. Башкалада бу сан – 54, 4 процент. Республикада туган телне өйрәнмәгән бер генә мәктәп тә юк. Без туган тел укыту буенча берничә вариантны тәкъдим итәбез һәм шуны контрольдә тотабыз. Федераль программаларга күчү республикада мәгариф өлкәсендә алып барылган сәясәткә комачауламый. Безнең үз татар теле һәм әдәбияты дәреслекләребез бар.

Мәркәзебездәге милләт нисбәте 50 гә 50 дип әйтергә кирәк. Безнең башка милләт халыкларына татар телен мәҗбүри укытырга хокукыбыз юк, аның белән шөгыльләнмибез дә. Һәр халык үз телен сайлый, – дип җавап бирде министр.

**Дәреслекләр турында.** Дәреслекләргә килгәндә, мәгариф министры әйтүенчә, бүген республикада өлкән сыйныф укучылары тарих фәнен яңартылган дәреслек буенча укый. Аның фикеренчә, Татарстан мәктәпләрне яңа китаплар белән барыннан да алданрак тәэмин иткән төбәкләр арасына кергән. Яңартылган дәреслектә Россия тарихы гомумтарих белән берләштерелгән, аңа шулай ук Бөек Ватан сугышы һәм махсус хәрби операция турында заманча материаллар кертелгән.

– Бүгенге көндә республика мәктәпләрендә 7 тел туган тел буларак өйрәнелә, 6 телдә белем бирелә. Чыннан да, эшләнгән эшләр шактый, әмма хәл итәсе мәсьәләләр бик күп. Дәреслекләр турында сүзне иң элек туган тел дәреслекләрен яңа баскычка күтәргән үзгәрештән башлау урынлы булыр. 2022 елдан, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыгы нигезендә, яңа Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килгән дәреслекләр гамәлгә кертелде. Аерым алганда, татар теле һәм әдәбиятыннан – 60, удмурт теле һәм әдәбиятыннан – 27, чуваш теле һәм әдәбиятыннан – 17, мордва теле һәм әдәбиятыннан 10 дәреслек федераль исемлектә урын алды.

Министрлык ел саен уку йортларын мари, удмурт, мордва, чуваш, татар һәм рус телләре дәреслекләре, уку әсбаплары һәм матур әдәбият белән тәэмин итә. Өстәп шуны да әйтергә кирәк: 2023 елдан башлап мәктәпләргә дәреслекләрне мөстәкыйль сатып алу өчен субвенция бирелә. Чыннан да, дәреслекләрне яңартуга кагылышлы сораулар бар. Бу исә, беренче чиратта, федераль исемлек белән бәйле

фактор.

– Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү чорында, федераль исемлеккә кергән барлык дәреслекләрне һәм уку әсбапларын (нәшриятлар исемлеге Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 9 июнендәге 699 нчы боерыгы белән расланган) кулланырга мөмкин. Хәзерге вакытта безнең алда мәктәп китапханәләре фондында булган ресурсларны мөмкин кадәр нәтиҗәле файдалану бурычы тора, – дип сөйләде министр.

Укыту формалары турында. Очрашуда өйдә белем алучылар турында да сүз булды. Узган уку елы ахры белән чагыштырганда, аларның саны 751 гә кимегән. Өйдә уку формасын күбрәк башлангыч сыйныф укучылары сыный икән. Югары сыйныфта андыйлар күп түгел. Әмма нәтиҗәләр сөендерми. Өйдә укучыларның БДИ имтиханнары буенча күрсәткечләре рус теленнән – 7, математикадан – 11, тарихтан 15 баллга, географиядән 37 баллга кимрәк. Закон өйдә укытуга каршы килми. Әмма ничек кенә булмасын, бу мәсьәләгә карата фикерем үзгәрми: җитди сәбәпләрсез гаиләдә укуга күчүне хупламыйм. Әти-әниләр башлангыч сыйныфтан ук балаларын социальләшүдән мәхрүм итеп, җитди хата җибәрә, бу турыда уйлансыннар иде, – дип сөйләде министр.

**Остазларга хөрмәт турында.** Тагын бер матур яңалык – быелгы уку елы ахырына Татарстанда Мәгариф музеен ачарга ниятлиләр. Ул Казан федераль университеты базасында төзеләчәк. Министр фикеренчә, биредә студентлар күп, квалификация күтәрү өчен укытучылар, төрле кунаклар да килә.

– Анда интерактив җиһазлар урнаштырылачак, республиканың төрле почмакларыннан элемтәгә чыгарга, мәгълүмат алырга һәм дәресләр үткәрергә мөмкин булачак, – диде ул.

Һадиуллин шулай ук Казансу яр буенда барлыкка киләчәк Укытучы скверы турында да сөйләде. Аның сүзләренчә, Милли китапханәнең уң ягында балалар паркы булачак. Шушы парк һәм «УРАМ» паркы арасында укытучыга һәйкәл куелачак.

Язмабызны тәгәлләп шуны әйтәсе килә: Укытучылар һәм остазлар елында мөгаллимнәребезгә багышланган бик күп чаралар үтте, күп кенә хәл итәсе мәсьәләләр дә, төптән каралып, үз чишелешен тапты. Министр фикеренчә, педагогларга булган игътибар бер ел белән генә чикләнмәячәк, ул һәрдаим дәвам итәргә тиеш. Укытучыларны хөрмәт иткән халыкның киләчәге якты һәм өметле! Министр шундый ныклы фикердә тора.

**Фәния ЛОТФУЛЛИНА**

4




# ЯҢАРТЫЛГАН ФДББС ШАРТЛАРЫНДА УКЫТУЧЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Кадрия ФӘТХУЛЛОВА,**
педагогика фәннәре кандидаты,
КФУның гомуми тел белеме һәм
тюркология кафедрасы доценты

Минем фәнни эшчәнлегем татар телен укыту методикасына, «ТРның дәүләт (татар) теле» уку предметыннан Федераль эш программасына багышлана. 1–11 нче сыйныфлар өчен дәреслекләр, югары уку йортлары студентлары өчен татар теленнән уку әсбаплары, сүзлекләр авторы булып торам.

Яңартылган федераль белем бирү стандартларында билгеләнгән төп максат: туган ягын, туган илен яратучы, туган телен һәм Россиянең дәүләт телен белүче, үз халкын, аның мәдәниятен, рухи гореф-гадәтләрен хөрмәт итүче, гаилә, җәмгыять, күпмилләтле Россия халкының һәм кешелек дөньясының кыйммәтләрен аңлаучы шәхес тәрбияләү . Бүгенге шартларда һәр туган тел укытучысы әлеге юнәлештә эзлекле һәм системалы эш алып бара. Куелган максатка ирешү өчен, туган тел укытучысына билгеле бер педагогик компетенцияләргә (осталыкларга) ия булу мөһим. Аларны берничә төркемчәгә бүлеп карыйлар:

*1) социаль осталыклар:* җаваплылыкны үз өстеңә алу; дөрес карар кабул итә белү; күпмәдәниятле җәмгыятьтә яшәү шартларын ачык күзаллау; эштә һәм җәмәгать урыннарында төрле кешеләр белән телдән һәм язмача аралашуга әзер булу; Интернет һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урын алган хәбәрләргә тәнкыйть күзлегеннән карый белү;

*2) оештыру* осталыклары:укучыларны берләштерү; укучыларны танып белү эшчәнлегенә тарту; аларның эшчәнлегенә нәтиҗә ясау һәм объектив бәя бирү;

*3) дидактик осталыклар:* дәрес материалын аңлаешлы һәм эзлекле итеп җиткерә белү; укучыларның танып белү активлыгын үстерү;

*4) перцептив осталыклар:* укучыларның эчке халәтендәге үзгәрешләрне күрә белү; психик үзенчәлекләрен исәпкә алып эш итү;

*5) суггестив осталык:* укучыларга эмоциональ тәэсир күрсәтә алу;

*6) фәнни-тикшеренү осталыгы:* заманча фәнни белемнәргә ия булу; белем бирү өлкәсендәге үзгәрешләрне алдан тоеп эш итү; гамәли эшчәнлекне камилләштерүгә омтылу; фәндәге яңалыкларны, педагогик казанышларны укытуда һәм тәрбия эшендә куллану.

Методик осталыкларга килгәндә, алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «укытучы-укучы» системасы белән идарә итә белү (максат-бурычларны, дәреснең төп этапларын төгәл билгеләү, белем бирү процессын заманча оештыру); дәресләрдә танып белүнең актив формаларыннан файдалану; шәхескә юнәлтелгән һәм укучыларның социаль үсешен тәэмин итә торган педагогик технологияләрне куллана белү; укучыларга мөстәкыйль белем алу өчен шартлар булдыру; белем бирүнең сыйфатын яхшыртуга омтылу; үз эшеңдә планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү; үз эшеңне намуслы башкару.

Әлеге осталыкларга ия булган укытучы балаларның иҗади сәләтләрен үстерә; танып белү эшчәнлеген активлаштыра; фәнгә кызыксынуларын арттыра.

Татар теле укытучылары санап чыккан осталыкларга ияме соң? Бу сорауга җавап бирү өчен, бер мисал китереп үтик. 2022 елда беренче тапкыр Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Россия халыкларының телләре Федераль институты тарафыннан «Иң яхшы

туган тел һәм туган әдәбият укытучысы» Бөтенроссия һөнәри конкурсы үткәрелде. Әлеге бәйгедә Татарстан данын Зилә Әфтах кызы Габдинова, Казан шәһәре 116 нчы лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы яклады һәм лауреат дипломына ия булды. 2023 нче елда Алинә Илсур кызы Шәгәраева, Казан шәһәре 13 нче татар гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы конкурсның финалисты исеменә лаек булды.

Татар теле укытучыларының шундый абруйлы конкурста җиңү яулавы күңелдә канәгатьлек һәм горурлану хисе уята. Алар – үз хезмәтләреннән ләззәт табып эшләүче мөгаллимнәр, педагогик эшчәнлекләрендә нәтиҗәгә омтылучылар, укытучы дигән бөек исемне йөртүчеләр дип саныйм. Конкурста катнашучыларның чыгышларын тыңлаганда (мин үзем әлеге конкурсның жюри әгъзасы буларак катнаштым), үз фәнен яраткан, аңа чын күңеленнән гашыйк булган укытучы гына балаларга төпле белем бирә ала дигән сүзләрнең дөреслегенә тагын бер кат инанасың. Ел саен әлеге чарада үз эшенең чын остасы булган, Россия Федерациясенең төрле субъектларыннан килгән укытучылар көч сынаша. Алар методик остаханә, ачык дәрес, сыйныф сәгате, осталык дәресе кебек сынауларны узалар; эш тәҗрибәләре, методик табышлары белән уртаклашалар.

Туган тел дәресләрендә белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын яхшырту һәм нәтиҗәләргә ирешү өчен, укытучыга заманча технологияләрдән, цифрлы ресурслардан файдалану зарур: мәгълүмати технологияләр, дистанцион укыту технологияләре, тәнкыйди фикерләү технологиясе, проект технологиясе, үстерелешле укыту технологиясе, проблемалы укыту технологиясе, уен технологиясе, модульле укыту технологиясе, кейс технологиясе, кроссенс технологиясе, берләштереп укыту технологиясе һ.б.

Туган тел дәресләрендә укучыларны татар порталлары белән таныштыру шулай ук зур әһәмияткә ия. Моны дәлилләү өчен, күренекле язучы һәм тел белгече Галимҗан Ибраһимовның сүзләрен искә төшереп үтү урынлы булыр: «Күп белдерүгә караганда, аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр».

Моның өчен укытучы

порталларыннан файдалана ала. Бүгенге көндә әлеге юнәлештә КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында да эш алып барыла. Укытучыларга, тәрбиячеләргә методик ярдәм күрсәтү максатыннан **«Татар галәме»** порталы эшләнә.

Инновацион технологияләрне, Интернет ресурсларын куллану куелган максатларга ирешүдә өстәмә мөмкинлекләр тудыра:балаларда татар телен өйрәнүгә даими кызыксыну булдыру; укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру; укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ачып бирү һәм иҗади үсешен тәэмин итү; укучыларга җитәрлек мәгълүмат бирү; белемнәрне системага салу һәм гомумиләштереп

күрсәтү; үзлектән белем алу мөмкинлекләрен киңәйтү; укучыларда эзләнү-тикшеренү эшләре алып бару теләге уяту; предметара бәйләнеш булдыру.

Татарстанда һәм Россиянең төрле төбәкләрендә эшләүче татар теле укытучылары алдында торган мөһим бурычларны атап үтик.

***Беренчедән, балаларда милли горурлык тәрбияләү.*** Һәрбер халык тормышның төрле өлкәләрендә ирешкән казанышлары, иҗатлары, фәнни ачышлары белән дөньяда танылган, дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән бөек шәхесләре белән горурлана. Үз халкын таныткан татарлар да бихисап. Менә шулар үрнәгендә яшь буында үз халкыңның лаеклы уллары һәм кызлары булу хисе тәрбияләү зур әһәмияткә ия. Дәресләрдә дә, сыйныфтан тыш эшләрдә дә моңа аерым игътибар бирү сорала.

***Икенчедән, бала күңелендә туган телгә карата хөрмәт уяту.*** Туган телеңә мәхәббәт – бер үк вакытта Ватаныңа да, намусыңа да тугрылык дигән сүз ул. Бала кечкенәдән үк ана телендә әкиятләр, җырлар, танылган әдипләрнең әсәрләрен тыңлап һәм укып, милли чараларда катнашып үссә, ул ирексездән үз халкының баласы булып җитешә, милли җанлы, үз милләтен кайгыртырлык шәхес итеп тәрбияләнә. Күренекле мәгърифәтчебез Ризаэддин Фәхреддиннең сүзләре моңа дәлил булып тора: «Балачакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас».

Бүгенге көндә укытучының эшчәнлеген билгеле торган төп норматив документ – федераль эш программалары. Алар түбәндәге таләпләрне тәэмин итә: сыйфатлы белем алуга тигез мөмкинлекләр булдыру; белем бирү процессын оештыру шартларына бердәм таләпләр кую; белем бирү нәтиҗәләрен бердәм таләпләрдән чыгып бәяләү; уку предметының мәҗбүри эчтәлеген һәр уку елы өчен аерып күрсәтү; темаларны өйрәнүгә бүлеп бирелгән вакыт һәм аларны үзләштерүнең эзлеклелеген якынча билгеләү.

Федераль эш программалары укучыларда сөйләм, тел һәм этномәдәни компетенцияләр, функциональ грамоталылык булдыруны максат итеп куя.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: һәрбер халык туган телен саклап калу, үстерү, укыту, дөньяга тарату һәм таныту турында кайгыртып яши. Телне саклау – халыкны саклау дигән сүз ул. Әгәр бүгенге көн укучылары мәктәпләрдә туган телләрен үзләштермиләр икән, бу телләрнең киләчәге булмаячак. Тел бетсә, милләт тә яшәүдән туктый, чөнки милләтне саклау телне саклаудан башлана. Илебезнең киләчәге җәмгыятебездәге кешеләр белән бәйле. Ә ул кешеләргә укытучылар белем һәм тәрбия бирә. Шуңа күрә туган тел укытучысыннан үз эшен намуслы, нәтиҗәле итеп башкару сорала.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1. ФГОС ООО (дата обращения: 12.12.2023).
2. Единое содержание общего образования (дата обращения:12.06.2023).
3. Фахреддин Р. Жизнь длиною в жизнь. – Казань: Рухият, 2014. – 148 с.



# ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ ПОРТРЕТЫ

**Рузилә ФӘТТАХОВА,**

ТР Мәгарифне үстерү институты татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты, Туган (татар) тел һәм әдәбият укытучылары ассоциациясе җитәкчесе

Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин тарафыннан «Укытучылар һәм остазлар елы» дип игълан ителгән 2023 ел тәмамланып килә. Дәреснең соңгы этабы – рефлексия өлешендәге кебек бу ел вакыйгаларын яңадан искә төшерү, гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясау, үз-үзебезгә билгеләр кую вакыты җитте. Укытучы һөнәренең югары статусын тану һәм алар башкарган эшләрнең мөһимлеген белдерү юлында күренекле вакыйгалар булды, күркәм чаралар үткәрелде.

Агымдагы елда татар милли мәгарифе өлкәсендә тарихи вакыйгаларның берсе – Туган (татар) тел һәм әдәбият укытучылары ассоциациясе төзелде. Укытучылар җәмгыяте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Мәгарифне үстерү институты һәм Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан гамәлгә куелды. Ул, коммерцияле булмаган иҗтимагый оешма буларак, 7 августта РФ Юстиция министрлыгында теркәлде.

Уставта Ассоциациянең максаты укытучыларга методик күрсәтү дип билгеләнсә дә, аның эш юнәлешләре киңрәк күзаллана: берләшмә татар теле укытучыларын хокукый яктан яклаучы, аларның һөнәри мәнфәгатьләрен яктыртучы, татар теле укытучысы һөнәренең абруен күтәрүче, аларга шәхси һәм профессиональ яктан үсәргә ярдәм итүче иҗтимагый оешма булырга тиеш.

Яңа төзелгән берләшмәнең иң колачлы чараларының берсе – агымдагы елның 12–14 ноябрендә Бөтенроссия «Туган тел» форумы булды. Әлеге чарада ТР Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов, республикабыздан һәм РФ төбәкләреннән 800 вәкил катнашты. Форум делегатлары Татарстанда һәм РФ регионнарында милли мәгарифнең көнүзәк проблемалары, белем бирү оешмаларында туган телне укыту һәм милли тәрбия бирү, бу юнәлештә ата-аналар белән эшчәнлек алып бару, милли-мәдәни, дини оешмалар белән хезмәттәшлек итү мәсьәләләре турында фикер алыштылар, Ассоциациянең алга таба эш юнәлешләре һәм планнары турында тыңладылар, методик мәйданчыкларда эш тәҗрибәсе тупладылар, күргәзмәләр белән таныштылар.

Форумга килүчеләргә таратма материаллар арасында «Татар теле укытучысының өстәл китабы» бар иде. Бу китап укытучыга методик ярдәмлек буларак тәкъдим ителде. Монда туган телләрне укыту буенча норматив документлар, Федераль дәүләт белем бирү стандартлары, Федераль белем бирү программасының төп төшенчәләре, актуаль дәреслекләр, грантлар, һөнәри бәйгеләр исемлекләре, дистанцион белем бирү ресурслары һ.б. кирәкле мәгълүмат тупланган.

Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә барлыгы 4500 татар теле һәм әдәбияты мөгаллиме эшли. Бүгенге көндә аларның күпчелеге Ассоциациягә теркәлгән. Берләшмәгә кергән татар теле укытучыларының социаль портретын төзү максатында аналитик тикшерү эше башкарылды.

Гомумән, укытучының социаль портреты – күпкырлы образ, ул педагогның һөнәри һәм шәхси характеристикаларын, шулай ук аның белем бирү мохитенә һәм, гомумән, җәмгыятькә йогынтысын үз эченә ала. Әлеге портрет безгә укытучы белем бирү процессында нинди роль уйнавын һәм функцияләр башкаруын, укучылар, коллегалар, ата-аналар белән ничек эш итүен аңларга ярдәм итә.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысының социаль портреты – туган тел һәм әдәбият һәм аларны укыту методикасы буенча тирән белемнәргә һәм күнекмәләргә ия булган, татар телен һәм әдәбиятын саклап калуга һәм үстерүгә, шулай ук җәмгыятьтә татар мәдәниятен һәм тиңдәшлеген формалаштыруга ярдәм итүче һөнәр ияләре.

Берләшмәгә теркәлгән укытучыларның 62 % ы Татарстан Республикасыннан, 38 % ы – РФ субъектларыннан. Татар телен һәм әдәбиятын укыту географиясе масштабы белән таң калдыра. Республикабызда татар теле туган тел һәм Татарстан Республикасының дәүләт теле, ә Россия Федерациясе төбәкләрендә татар теле туган тел буларак укытыла. Башкортстан Республикасы, Оренбург, Саратов өлкәләре, Пермь крае укытучылары Ассоциациядә күпчелекне тәшкил итәләр. Бу – табигый күренеш: әйтелгән төбәкләрдә милләттәшләребез күпсанлы булып яши, татар телендә белем бирүче мәктәпләр бар, анда татар теле предмет буларак уку планының мәҗбүри өлешенә кертелгән. Әлеге төбәкләрдә эшләүче татар теле укытучылары, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырган төрле һөнәри бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр яулыйлар.

Педагогик коллективларның төп гендер составы хатын-кызлар булуы беркемгә дә сер түгел. Ассоциациягә теркәлгән укытучыларның да 98 % ы – хатын-кызлар. Гомуми санның 2 % ы гына тәшкил иткән ирләр татар телен, әдәбиятын укытуда һәм популярлаштыруда мөһим роль уйныйлар, алар укучылар өчен көчле, зирәк һәм белемле шәхес үрнәге булып торалар, балалар абыйларының дәресләренә аеруча теләп йөриләр.

Ассоциациягә теркәлгән укытучыларының уртача яше – 47 яшь. Мәктәпләрдә яшь педагогларга кытлык күзәтелә: 22 яшьтән алып 30 яшькә кадәр укытучылар саны 1 % кына тәшкил итә. Бу хәл кичекмәстән мәсьәләне тирәнтен анализлауны, яшь кадрларны мәгариф системасына җәлеп итүгә ярдәм итә торган чаралар әзерләүне таләп итә:

1. Яшь педагогларны материаль яктан мотивацияләү.
2. Уңайлы эш графигы, шәхси үсеш өчен мөмкинлекләр, психологик иминлек халәте булдыру.
3. Яшь педагогларның даими һөнәри белемнәрен күтәрүне оештыруга һәм стимуллаштыруга көчле игътибар бирү.
4. Татар теле укытучысы профессиясенең дәрәҗәсен күтәрү.

Ассоциациядәге укытучыларның күбесе, ягъни 97 % ы югары белем турындагы дипломга ия, 3 % ы – урта һөнәри белемле.

Хәзерге вакытта татар теле һәм әдәбияты укытучылары алты югары уку йортында: Казан федераль университетында, Яр Чаллы дәүләт педагогика университетында, КФУның Алабуга институтында (филиал), Башкортстан дәүләт университетында, Мифтахетдин Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университетында, Уфа фән һәм технологияләр университетының Эстәрлетамак филиалында әзерләнә.

Милли мәгариф өчен кадрлар әзерләү педагогик профильле ресурс үзәкләрендә – М. Җәлил исемендәге Минзәлә педагогика көллиятендә һәм Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятендә алып барыла.

Шулай ук РФ регионнарында татар теле әдәбияты укытучыларын әзерләү эшен ТР Мәгарифне үстерү институты татар теле әдәбияты кафедрасы оештыра. Соңгы ике елда 82 укытучы, «Туган (татар) телне һәм әдәбиятны укыту теориясе һәм методикасы» дигән белгечлек буенча укып, диплом алдылар һәм хәзерге вакытта үз төбәкләрендә туган телебезне һәм әдәбиятыбызны укыту, милли тәрбия бирү буенча актив эш башкаралар.

Димәк, татар теле укытучысының социаль портреты – 45–50 яшьтәге, югары филологик белемле, беренче яки югары квалификация категорияле, 25–30 ел стажлы мөгаллим. Ул үзе яшәгән регионның мактаулы грамоталарына һәм/яки Мәгариф өлкәсендә казанышлары өчен күкрәк билгеләренә ия. Ул ана телен укыту, милли тәрбия бирү һәм мәдәниятебезне саклап калу һәм үстерү өчен зур эш башкара, зыялы татар яшьләрен формалаштыру өчен көч куя, үз укучыларына һәр яктан үрнәк остаз булып тора.

6




# ЯҢА БУЫН ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

**Рамилә СӘГЪДИЕВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты, филология фәннәре кандидаты, Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр фәнни белем бирү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре

**2 слайд** XXI гасыр гаҗәп зур тизлек белән бара, заман үзгәрә, теләсә кайсы тармакта эшчәнлек алып барган хезмәткәр алдына да гел яңа таләпләр, бурыч-максатлар куела. Әлеге агымга без дә – укытучылар, остазлар һәм безнең укучыларыбыз да ияреп алга чаба. Шагыйрь Разил ага Вәлиевнең бик матур фикере бар: «Я булмаса дөньяны үзгәртәм мин бүген, я булмаса үзем үзгәрәм», – дип язган ул. Дөрес, без әлеге тизлекне, вакытны туктата алмыйбыз, заманны үзгәртү дә безнең көчтән килми, шуңа күрә теләсәк тә, теләмәсәк тә үзебезгә үзгәрергә туры килә.

2022 елның 1 сентябреннән барлык мәктәпләр дә яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчтеләр. Элек «Нәрсәгә өйрәтергә?» дигән сорау куелган булса, хәзер исә «Бу миңа ник кирәк? Бу белем миңа тормышта ничек ярдәм итәчәк?» дигән сораулар да өстәлә. Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартлары укыту һәм тәрбия эшчәнлегенең тыгыз бәйләнештә булуына һәм бердәмлегенә басым ясый. Документта тәрбия эшенең төп юнәлешләре ассызыклана.

2023 елның 1 сентябреннән Федераль белем бирү программасы расланды һәм башлангыч, төп, урта гомуми белем бирү оешмаларындагы барлык фәннәр дә әлеге документка таянып укытыла башлады.


Әлбәттә, әлеге үзгәрешләр төрле предметлардан өр-яңа УМКлар эшләүне таләп итә. Бу очракта Р.К.Сәгъдиева һәм К.Ф. Фәйзрахманова тарафыннан язылган туган тел (татар теле) дәреслеген атап китү урынлы булыр. Гомуми белем бирү оешмаларының 1–11 нче сыйныфлар өчен эшләнгән УМК РФ Мәгариф министрлыгы боерыгы нигезендә дәреслекләрнең федераль исемлегенә кертелде, һәм ул татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр өчен тәкъдим ителә. УМК басма һәм электрон дәреслекне, укытучы өчен методик әсбапны үз эченә ала, Федераль дәүләт белем бирү стандартларына һәм Федераль белем бирү программасына тулысынча туры киләләр.

**3 слайд** Бүгенге көндә милли телләрне өйрәтүгә таләпләр үзгәрде. Иң беренче планга яшь буынны тәрбияләү, туган телендә аралашырга өйрәтү мәсьәләләре куелды. Шуңа күрә дә һәр сыйныф өчен язылган туган тел (татар теле) дәреслеге, 4 чирек белән бәйле, «Мин», «Тирә-як, көнкүреш», «Туган җирем» һәм «Татар дөньясы» дип аталган 4 блоктан, ягъни 4 шмуцтан гыйбарәт.

**4 слайд** Һәр дәрескә тәрбияви максат куела һәм ул, әлбәттә, дәреслектә бирелгән лексик темалар аша тормышка ашырыла. «Мин» темасы, ягъни беренче чиректә сүз мәктәп һәм укучылар тормышы турында бара, туган телгә һәм ата-анага мәхәббәт, укытучыга хөрмәт тәрбияләү алгы планга чыга, балаларны өлкәннәргә ярдәм итәргә өйрәтәбез, укучыларда кешелеклелек сыйфатлары булдыру һәм китап укырга теләк уяту кебек тәрбияви юнәлешләр

белән бәйле аралашу эшләре башкарыла.




«Тирә-як, көнкүреш» темасы кысаларында урын алган текстлар төрле ел фасылларының матурлыгы, хайваннар һәм кошлар дөньясы, агачларның, чәчәкләрнең кеше тормышындагы роле, су чыганаклары, табигый байлыклар, күк җисемнәре һ.б. турында. Әлеге икенче чиректә укучыларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү максат итеп куела.

**5 слайд** «Татар дөньясы» темасы 4 чиреккә туры килә. Анда исә татар халкының гореф-гадәтләрен чагылдырган текстлар урын алды. Укучылар фактик мисаллар аша татар халкының милли гореф-гадәтләре, мәдәнияте, көнкүреше, танылган шәхесләре белән танышалар, милли киемнәр һәм аларның бизәлешенә игътибар итәләр.







Яңартылган Федераль белем бирү стандартлары нигезендә, бүгенге көндә укучыларда патриотизм, толерантлык, туган ил белән горурлану хисләре тәрбияләү алгы планга чыкты. 2023 ел да Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы дип игълан ителгән иде. «Туган җирем» темасы белән бәйле бүлектә, ягъни өченче чиректә, укучыларда нәкъ менә патриотизм, толерантлык хисләре тәрбияләү максат итеп куела. Укучыларны туган илнең матурлыгын күрергә өйрәтәбез, шәһәр һәм авыл тормышы, милли ризыклар, милли бәйрәмнәр белән таныштырабыз.

**6 слайд** Теге яки бу теоретик материалны ныгыту максатыннан алынган текстлар Россия шәһәрләре, елга-күлләрен тасвирлаган микротекстлар аша тормышка ашырыла. Төрле шәһәрләр, елга-күлләр турында кызыклы мәгълүматлар бирелде, аларның бик матур фотосурәтләре дә урнаштырылды. Чыннан да, шундый эш төрләре ярдәмендә туган илнең байлыгына, матурлыгына таң каласың, сокланасың, һәркемдә аларны барып күрү теләге уяна.

**7 слайд** Дәреслекләрдә «Бу кызыклы» дип аталган рубриканың аерым бирелүе дә юкка түгел. Әлбәттә, алар теге як бу теоретик материалны аңлату яисә кабатлаттыру максатыннан түгел, ә укучының күзаллавын арттыру, өстәмә мәгълүматләр белән таныштыру өчен тәкъдим ителә. Бу исә һәр дәреснең таләбенә бәйле

предметара (мәсәлән, география, җәмгыять белеме, тарих белән) бәйләнешләр булдыру юнәлешендәге эш тә.

**8 слайд** Һәр предмет укытучысы үзалдына һәр баланы тәрбияләүне максат итеп куя. Туган тел укытучылары, әлбәттә, бу эшне, төрле әсәрләр кулланып, тормышка ашыра ала. Дәреслекләрдә төрле халыкларның бәйрәмнәрен, төрле регионнарда эшләп килгән үзенчәлекле музейлар белән бәйле текстларның урын алуын аерым ассызыклап китү кирәк.

Теге яки бу теоретик биремне аңлатканда, төрле милләт халыкларының милли ризыклары белән таныштыру да яшь буын өчен кызыклы эш төре санала. Удмуртларның пәрәпәчләрен, мордваларның эрзәннәрен, мариларның сокталарын һ.б. милли ризыкларны берничә дәрес кысасында тәкъдим итү башка милләт халкына хөрмәт уятуга юнәлеш була.

**9 слайд** Укучыга белем бирү процессында сүзлек эше башкарыла. Бу очракта да кызыклы алым куллану отышлы. Мәсәлән, мунча яисә йорт җиһазларының рәсемнәре, татарча һәм русча атамалары укучыларга танышу өчен лабиринт формасында тәкъдим ителә.

**10 слайд** Авыл һәм шәһәр тормышын тасвирлау аша да укучыларга туган җиргә мәхәббәт тәрбияләп була. Мәсәлән, Чувашиядәге Шыгырдан һәм Татарстандагы Шәле кебек зур авылларны тасвирлап биргәннән соң, балаларга, кызыклы факт буларак, Россиядәге иң зур авыл турында искәртеп узабыз. Анда 30 мең кеше яшәгәнлеге билгеле. Укучыларга иң зур татар авылының Татарстанда түгел, ә Пенза өлкәсендә икәнлеген белү дә кызык булачак.

Күргәнегезчә, бай һәм матур фактик материал аша укучыларның теоретик белемнәрен бәяләп була.

**11-12 слайд** Яңа буын туган тел (татар теле) дәреслегенең тагын бер үзенчәлеген ассызыклап китү урынлы булыр. Авторлар һәр дәреслектә текст белән эш алымын кулланалар. Ул, гадәттә, һәр чиреккнең бер сәгате кысасында үткәрелә. Әлеге эш алымы укучыда тыңлап аңлау, сөйләү, язу һәм уку күнекмәләрен булдыруга йөз тота.

Моннан тыш, үткән теоретик материалны кабатлаттыру, гамәлдә ни дәрәҗәдә куллана алуларына нәтиҗә ясау өчен дә бер әсәргә таянып биремнәр тәкъдим итү уңышлы.

Ни кызганыч, бүгенге көндә әдәби уку, туган (татар) телендәге әдәбият дәресләренә атнага бер генә сәгать бирелә. Туган тел дәресләрендә аерым текстлар белән эшләү, теге яки бу язучының иҗатын барлау юнәлешендәге проект эшләрен башкару әлеге бушлыкны билгеле бер дәрәҗәдә тулыландырыр дип өметләнәбез.

Заман үзгәрә. Бала ул һәрвакыт бала булып кала дисәк тә, һәр буынның үз характеры, аларның фикерләү дәрәҗәсе һәм кызыксынулары бөтенләй башка. Шуңа күрә уку-укыту методик кулланмаларны үзгәртә алу да укучы һәм укытучы файдасына.




# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ «ЭШ» ШИГЫРЕН ӨЙРӘНҮ

*(4 нче сыйныфта татар әдәбияты дәресе)*

**Гөлчәчәк ТАҖЕТДИНОВА,**

Самара өлкәсе Похвистнево районы Гали урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы

**Максат:** шигырь белән таныштыру, аңа анализ ясау;

– укучыларның йөгерек, дөрес, сәнгатьле уку күнекмәләрен арттыру, логик, иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү;

– эшкә, хезмәткә карата уңай караш тәрбияләү.

**Җиһазлау:** ноутбук, экран, Г.Тукай портреты, тактага Г.Тукайның:

«Үзем үлсәм дә газиз исемем үлмәсен, югалмасын,

Минем эшләрем, тырышлыгым бушка китмәсен» дигән шигъри юллары һәм «Агачны яфрак бизи, кешене хезмәт бизи» дигән мәкаль язылган.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше**

*(Талгын гына музыка уйный.)*

**Укытучы.**

Исәнмесез, балалар!

Хәерле көннәр сезгә!

Акыл һәм тел ачкычлары

Телимен һәммәгезгә.

Бүгенге көн сездә бары матур уйлар, якты хисләр генә тудырсын. Бу дәрес сезнең өчен кирәкле һәм файдалы булсын.

Әйдәгез, хәзер дәрестә кулланырга тиешле кагыйдәләрне искә төшерик әле. *(Игътибар белән тыңла, бүлдермә. Тулы җөмләләр белән сөйлә. Кеше фикерен кабатлама, үз фикереңне әйт.)*

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

**Укытучы.** Балалар, тактага карыйбыз. Анда бирелгән кроссвордны чишү өчен табышмакларның җавапларын табып, шакмакларга тутырабыз.

1. Акчасыз керәсең, хәзинә алып чыгасың. *(Мәктәп.)*

2. Кар өстенә биш малай иген чәчте. *(Язу.)*

3. Өй башына утырган, җир йөзен нуры белән тутырган. (Кояш.)

4. Ашамый, эчми, көне-төне эшли. *(Сәгать.)*

5. Күл тулы алтын балык. *(Йолдызлар.)*

**Укытучы.** Баганада нинди исем килеп чыкты?*( Тукай.)* Кем соң ул? *(Габдулла Тукай. Татар халкының бөек шагыйре.) (Экранда Г. Тукайның портреты күренә.)*

– Г. Тукай кайда һәм кайчан туган? *(Ул 1886 елның 26 апрелендә Татарстанның Арча районы Кушлавыч авылында туган.)*

– Ул озак яшәгәнме? *(Габдулла Тукай 27 яшендә үлгән.)*

– Г. Тукай балалар өчен нинди шигырьләр язган? (Ул «Бала белән күбәләк», «Кызыклы шәкерт», «Гали белән кәҗә» h.б. шигырьләрне язган.)

– Сез аның нинди әкиятләрен беләсез? *(Без аның «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләрен укыдык.)*

**Укытучы.** Рәхмәт, балалар! Елдан-ел Тукай турында белемнәрегез арта. Сез күп белергә омтыласыз. Бу мине бик сөендерә. 1–3 нче сыйныфларда без Габдулла Тукайның «Бәхетле бала», «Эш беткәч уйнарга ярый» әсәрләре белән танышкан идек. Әйтегез әле, «Эш беткәч уйнарга ярый» шигырендә баланың тырышлыгы үзенә нинди яхшылык булып кайткан? *(Балага кояш – җылы нурын, сандугач – җырын, алмагач алмасын бүләк иткән.)* Ә «Бәхетле бала» шигыре белән автор нәрсә әйтергә тели? *(«Яхшылык эшләгән, эшне яраткан бала бәхетле була», – ди автор.)*

Балалар, экранга игътибар итәбез. Анда язылган мәкальне укыйбыз. *(«Агачны яфрак бизи, кешене хезмәт бизи».)*

**Укытучы.** Бу мәкальнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? *(«Кеше хезмәте белән матур», – дип аңлыйм.)* Эш турында үзегез нинди мәкальләр беләсез? *(Яхшы эш үз-үзен мактый. Эш беткәч уйнарга ярый. Кем эшләми, шул ашамый).*

**III. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру**

**Укытучы.** Балалар, бүген без Габдулла Тукай иҗаты белән танышуны дәвам иттерербез һәм аның «Эш» шигырен укырбыз, сөйләм телен үстерербез.

**IV. Шигырь тексты өстендә эш**

**Укытучы.** Шигырьне игътибар белән тыңлагыз. Аңлашылмаган сүзләрне карандаш белән билгеләп барыгыз.

Сезгә нинди сүзләр аңлашылмады? *(Тынма, Тәңре, соңра, күп арасында, күк, иҗтиһад итсәң).*

Сүзлек өстендә эш *(Экран ачыла.)*

– Шул сүзләрнең мәгънәсен укыгыз.

Тынма – тынычланма, туктама *(не ленись).*

Тәңре – Алла, Ходай (Всевышний).

Соңра – соңыннан, ахырдан *(потом, позже).*

Күп арасында – кешеләр арасында *(среди людей).*

Күк – кебек *(как).*

Иҗтиһад итсәң – тырышсаң (*если будешь стараться).*

Укытучы. Аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләрен белдек. Инде, балалар, шигырьне үзалдына тагын бер кат укып чыгыгыз әле. *(Укучылар укый.)*

– Ягез әле, кайсыгыз әсәрнең эчтәлеген кыскача гына сөйләп китә? *(Автор сабыйга иртән торгач, дәресеңне укы, яз, тик торма, җомга көнне генә ял итәрсең, ди. Ул кояштан үрнәк алып, көндез кояш кебек эшләргә, ә төнлә ял итәргә куша.)*

**Укытучы.** Габдулла Тукайның шигырьләре күп телләргә тәрҗемә ителгән. Без аның бу шигырен русча да укып карыйк әле. Чылбырлап, икешәр юл укыйбыз.

– Сез ничек уйлыйсыз, бу шигырь нәрсә турында? *(Бу шигырь эш турында.)*

– Әсәрне ничә өлешкә бүлеп була? *(Без аны ике өлешкә бүләбез.)*

– Беренче өлешне сәнгатьле итеп укып чыгыгыз.

– Анда нәрсә турында язылган? *(Анда автор балага эшләргә куша.)*

– Икенче өлешне укыйбыз. Икенче өлештә нәрсә турында сүз бара? *(Икенче өлештә кояшның эше турында сүз бара).*

**Ял минуты**

Без инде хәзер зурлар,
Күп эшли безнең куллар.
Без идән дә юабыз,
Без керләр дә уабыз,
Гөлләргә су сибәбез.
Менә шундый уңган без,
Менә шундый булган без.

Балалар, эшебезне дәвам иттерәбез. Г. Тукайның «Эш» шигырендә нинди геройлар катнаша? *(Әсәрдә бала һәм кояш катнаша.)* Әсәрдә кояш нишли? *(Кояш иртә тора, таң аттыра. Кояш көн буе эшли, яктырта. Кояш арыгач, йокларга ята, җир йөзен йоклата.)* Кояш үзенең эшләре белән кемгә охшаган? *(Кояш кешегә охшаган.)* Ул нинди кешегә охшаган? *(Ул тырыш, эшчән, тәртипле, шәфкатьле, мәрхәмәтле, игътибарлы, яхшы, тыныч, сабыр, әдәпле кешегә охшаган.)*

Укытучы. Шагыйрь: «Тырышып эшлә», – дип, сабыйга гына мөрәҗәгать итәме? (*Юк, ул безнең дә тырышып эшләвебезне тели.)* Димәк, Габдулла Тукай үзенең «Эш» шигыре белән безгә нәрсә әйтергә теләгән? *(Ул безгә кояштан үрнәк алырга, тырышып*

*укырга,эшләргә кушкан. Вакытында ял итә дә бел, дигән. Яхшы эшләсәң, үзеңне дә яратырлар, хөрмәт итәрләр, ди шагыйрь.)* Шулай итеп, без сезнең белән кояш образына автор салган мәгънәне таптык.

**V. Синквейн төзү**

**Укытучы.** Ә хәзер без төркемнәрдә эшлибез. «Эш» темасына сиквейн төзибез. Сезгә сүзләр бирелгән. Шулардан кирәклеләрен сайлап, дөрес тәртипкә куярга кирәк. Төзеп бетергәч, һәр төркем үз эшен тактада күрсәтә. Башладык.

– Яхшы. Сез, синквейн төзүнең тәртибен бозмыйча, иң кирәкле сүзләрне сайлагансыз. Димәк, эшләргә кирәк икәнлекне аңладыгыз инде.

**VI. Тема өйрәнүне дәвам иттерү**

**Укытучы.** Габдулла Тукай хезмәт турында бер «Эш» шигырен генә язмаган. Аның «Эшкә өндәү», «Эш беткәч уйнарга ярый» дигән шигырьләре дә шушы темага. Мин сезне шулардан бер өзек белән таныштырып китәргә телим.

И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә – эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.

Ни өчен Габдулла Тукай эш турында бик күп язган соң? (Чөнки кеше үзенең эшләре белән бәхетле.) Балалар, татар шагыйрьләре хезмәт турында күп шигырьләр язган. Әйдәгез әле, «Алтын куллар» дигән шигырь юллары белән дә танышып китик.

Һөнәрләр күп җир йөзендә,
Үз теләгең – сайлап ал.
Нинди һөнәр сайласаң да,
Тырышып укы, белем ал.
Һөнәрләрнең барысы да
Тигез кеше каршында.
Күңел тарткан бер һөнәр
Сайла, сине кешеләр:
«Алтын куллы», – дисеннәр.

– Бу шигырьдә сүз нәрсә турында бара? (Шигырьдә: «Һөнәрләр күп. Ошаганын сайлап ал, тырышып укы», – диелгән.) Ә сез нинди һөнәрләр беләсез? (Сатучы, тегүче, шофёр, укытучы, төзүче, ипи пешерүче һ.б.)

**VII. Дәресне йомгаклау**

**Укытучы.** Балалар, бүген без дәрестә нәрсә эшләдек? (Без Г. Тукай шигыре белән таныштык, эш турында сөйләштек.) Күптәнге бер әйтем бар: «Яхшы эшне бүген эшли аласың икән, иртәгә калдырма, иртәгә бит синең тагын бер яхшылык эшләргә мөмкинлегең туачак».

– Көн саен сез нинди яхшы эшләр башкарасыз? (Идән, савыт-саба юабыз. Бүлмә җыештырабыз, тузан сөртәбез. Ялгыз карчыкларга булышабыз. Күршедәге кечкенә малайны уйнатабыз.) Дөрес, боларны сез барыгыз да эшли аласыз.

– Балалар, дәресне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: юкка гына Габдулла Тукай: «Үзем үлсәм дә, газиз исемем үлмәсен, югалмасын. Минем эшләрем, тырышлыгым бушка китмәсен», – дип язмаган икән. Чыннан да, шагыйрьнең исеме югалмады, эшләре бушка китмәде. Ул һаман безнең күңелләрдә. Аның тирән мәгънәле шигырьләрен өйрәнәбез, әкиятләрен укыйбыз. Габдулла Тукайның «Туган тел»е татар халкының гимны булып тора. Шул җыр белән бүгенге дәресебезне тәмамлыйсы килә. («Туган тел» җырын басып җырлыйлар.)

**Укытучы.** Рәхмәт! Утырыгыз. Балалар, дәрестә бик тырышып эшләдегез. Барыгызга да дәрестәге җавапларыгыз өчен билгеләр куям.

**VIII. Өй эше**

Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнеп, эчтәлеге буенча рәсем ясап килергә.




# СҮЗ ЯСАГЫЧ ҺӘМ ФОРМА ЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР

*(4 нче сыйныфта татар теле)*

**Венера ФӘСАХОВА,**

Әлки муниципаль районы Нәби Дәүлии исемендәге Базарлы Матак гимназиясенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** алдагы дәрестә алган белемнәрен гомумиләштерү; сүз ясагыч һәм форма ясагыч кушымчалар турында төшенчә бирү, аларны аерырга өйрәнү, сөйләмдә куллану. Сүзнең лексик мәгънәсе турындагы белемнәрне ныгыту,тирәнәйтү; чагыштыру, күзәтү, анализ ясау, логик фикер йөртү сәләтен үстерү, эшчәнлек ихтыяҗы тәрбияләү; туган ягыбыз табигатенә сакчыл караш, бер-береңә хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Дәрес тибы:** яна белем һәм күнекмәләр формалаштыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Метапредмет:* рус теле белән чагыштыру.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

– укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; анализлый белү; уку эшчәнлеген оештыра белү; уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

– уку максатын мөстәкыйль билгеләү; тиешле мәгълүматны табу, билгеләү; сөйләм берәмлекләрен логик эзлеклелеккә салу; объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү, чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

– фикерне төгәл итеп җиткерү; әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү; мәгълүматны туплау өчен парларда эш башкару, уйлау һәм фикерләү сәләтен үстерү.

**Предмет:** тамыр һәм ясалма нигезле сүзләрне аера белү.

**Шәхескә кагылышлы**: кышкы табигатькә мәхәббәт, бер-береңә хөрмәт, ихтирам хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау**: мультимедиа кушымтасы, презентация, карточкалар

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру моменты**

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальлаштерү**

Үткәннәрне искә төшереп үтәбез. Сүз төзелеше нәрсәне өйрәнә?

*Нәрсә ул тамыр сүз?

*Нинди сүзләргә тамырдаш сүзләр дип әйтәбез?

*Ясалышы ягыннан сүзләр нинди була?

*Тамырга ялганып килә торган кисәк нәрсә дип атала?

**III. Уку мәсьәләсен кую**

**Укытучы.** Мин сезгә бүген серле сүзләр әйтәм. Нинди серле сүзләр икән алар?

кар кар

карлыкарсызкарны

Укучылар тактадагы сүзләрне укыйлар. Дәфтәрләрне ачып бүгенге числоны язалар, сүзләрне күчереп язалар, шартлы билгеләр белән билгелиләр.

**Укытучы.** Бу сүзләр нәрсәләре белән охшаш? *(Тамыры.)* *(Укучыларның фикере тыңлана.)*


**Укытучы.** Ә нәрсәләре белән аерылалар? *(Кушымчалары белән.)* Һәрбер сүзнең мәгънәсен аңлатабыз. Бу сүзләрнең лексик мәгънәсе үзгәрде, ягъни яңа мәгънәле сүзләр барлыкка килде. Ә икенче баганадагы сүзләрнең грамматик мәгънәсе үзгәрде, ә төп лексик мәгънәсе үзгәрмәде.

Укытучы. Аны нәрсәләр

үзгәртте соң? *(Кушымчалар.)* Андый кушымчаларны ничек атар идегез? *(Укучылар үз вариантларын әйтәләр.)*

*(Аларның фикерләрен тыңлап, гомумиләштереп, укучылар белән бергә модульләштерә.)* Димәк, кушымчалар мәгънәләренә карап та бүленәләр.

Кайбер кушымчалар сүзнең төп мәгънәсен үзгәртмиләр. Аларны форма ясагыч кушымчалар дип атыйлар: кар, карны. Ә кайбер кушымчалар яңа сүзләр ясыйлар: кар, карлы. Аларны сүз ясагыч кушымчалар дип атыйлар. *(Тактада модуль төзелә.)*




Парларда бер-берсенә сөйләп ныгыталар.

Укытучы кушымчаларны рус теленә тәрҗемә итеп аңлата.

Укытучы.Нинди яңалык белдек инде? *(Кушымчалар ике төрле була: сүз ясагыч һәм форма ясагыч.)*

Укучылар, димәк, без бүген нәрсәләрне өйрәнәбез? Әйе, кушымчаларны, аларның төрләрен өйрәнербез. Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр икән?

**Көтелгән җавап.** Сүз ясагыч һәм форма ясагыч кушымчалар.

**Укытучы.** Әйе, дөрес, укучылар, нинди максат куябыз? *(Җаваплары тыңлана.)*

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү**

**Укытучы.** Дәреслекләрне ачабыз. Кагыйдәне табабыз, эчтән укыйбыз, аннары чиратлап кычкырып укыйбыз. Нәтиҗә чыгарып сөйлибез.

Хәзер алган белемнәребезне ныгыту өчен күнегүләр эшлибез. Дәреслектән 12 нче күнегүне табабыз. Дәфтәрләрне ачабыз, парларда эшлибез. *(Бер укучы тактда, калганннар дәфтәрдә эшлиләр. Сүзләрне кушымчаларын кушып язабыз, билгелибез. Нәтиҗә ясыйбыз, тикшерәбез.)*

**V. Ял минуты. «Кышкы урман»**

**Укытучы.** Укучылар, тактага карыйбыз. Җөмләләрне укыйбыз, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен билгелибез.

Туган ягыбызга **ямьле** кыш килде. Бөтен **җирне** йомшак ак кар каплады. **Канатлы** дусларыбызга азык табу кыенлашты. Аларга ярдәм итү – **безнең** төп бурычыбыз.

– Сез кыш көне кошларга ярдәм итәсезме? *(Әңгәмә.)*

Ә хәзер **«Дөрес, хаталы»** уенын уйнап алабыз. Мин сезгә җөмләләр әйтәм, дөресме, юкмы? Килешсәгез, дөрес,чөнки дип үз фикерегезне дәлиллисез, килешмәсәгез, ни өчен икәнлеген аңлатасыз.

*Акыллы – ясалма нигезле сүз (дөрес).*

*Матурлык – сүзе тамыр һәм ясагыч кушымчадан тора ( дөрес).*

*Болыннарда - сүзенең тамыры болыннар ( хаталы).*

*Җылы –ясалма нигезле сүз (хаталы).*

*Зурлык - сүзенең нигезе зур (хаталы) һ.б.*

**VI**. **Уку мәсьәләсен ныгыту**

**Укытучы.** Сезнең өстәлләрдә карточкалар. Карточкаларны алабыз. Туры килгән билгеләмә белән сүзләрне тоташтырабыз. Фикерләшәбез, бергә тикшерәбез.

**Сүзләр:**

1нче төркем

| | |
|---|---|
| А) тәмлерәк | 1) тамыр |
| Ә) озын | 2) тамыр-ясагыч кушымча |
| Б) зурлык | 3) тамыр-ясагыч кушымча- форма ясагыч |
| В) уйладылар | 4) тамыр-ясагыч кушымча, форма ясагыч |
| Г) баскычта | 5) тамыр-ясагыч кушымча- форма ясагыч- форма ясагыч |

2 нче төркем

| | |
|---|---|
| А) зур | 1) тамыр- форма ясагыч |
| Ә) аклык | 2) тамыр-ясагыч кушымча- форма ясагыч |
| Б) куяннар | 3) тамыр |
| В) дуслыкның | 4) тамыр- форма ясагыч |
| Г) кешегә | 5) тамыр- ясагыч кушымча |

**Укытучы.** Нәтиҗә ясыйбыз, тикшерәбез. Сез килешәсезме? Сүзнең мәгънәле кисәкләрен шартлы билгеләр белән күрсәтәбез. *(Укучылар тактада сызып күрсәтәләр.)*

Укучылар, тамырга кушымчалар ялгану тәртибе нинди? *(Укучыларның җаваплары тыңлана.)* Димәк,тамырга беренче ясагыч кушымча ялгана, аннары, форма ясагыч, ясагыч кушымча булмаса, форма ясагыч кушымча ялгана.

Ә хәзер, укучылар, белемнәребезне «Кем күбрәк?» уены белән ныгытып китәбез. Төркемнәрдә эшлибез. Кайсы төркем билгеле бер вакыт эчендә ясалма сүзләрне күбрәк яза, шул төркем җиңүче була. Нәтиҗә ясыйбыз, тикшерәбез.

Мультимедиа кулланмасын шушы сылтама аша http://tatarschool.ru/media/tth4

(мультимедиа кулланмасы, 4 нче сыйныф) ачабыз. Биремне укыйбыз. Башта бергә тыңлыйбыз. Аннары бу биремне парлап эшләргә киңәш итәм. Әлеге кушымта укучыларның белемнәрен ныгыту һәм кабатлау өчен бик уңайлы. Укучылар анда кагыйдәгә төшеп калган тиешле сүзләрне куеп укырга, темага туры килгән биремнәрне эшләргә тиеш булалар. Аннары нәтиҗә ясала.

Укучыларга, дәрестә катнашканнарын бәяләп, билгеләр куела.

**VII. Рефлексия**

**Укытучы.** Укучылар, дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Сез дәрестә нәрсәләр белдегез? Тормышта сезгә бу кирәк булачакмы? Ни өчен кирәк? Нәрсәгә өйрәндем дип уйлыйсыз?

**VIII. Өй эше**

1) 19 нчы күнегү,кагыйдәне укырга.

2) «Гаилә һәм мәктәп» журналыннан тамыр, ясалма 5 әр сүз язарга.

3) https://disk.yandex.ru/i/YD7Swu2fXbAeHw Шушы сылтама буенча кереп, рәсем буенча сүз ясагыч һәм форма ясагыч кушымчалы сүзләре булган 5 җөмлә уйлап язарга.




# ӘЙТҮ МАКСАТЫ ЯГЫННАН ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ

*(5 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Гөлүзә ҖӘЛӘЕВА,**

Казан шәһәре Г. Тукай исемендәге 1 нче татар гимназиясенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** гади җөмлә турындагы белемнәрне камилләштерү; әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен өйрәнү.

**Принциплар:**

**Дидактик принциплар**: теория белән практиканың бәйләнеше.

**Методик принциплар:** коммуникатив.

**Лингвистик принциплар:** функциональ принцип.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Предмет нәтиҗәләре:*** әйтү максатына ярашлы җөмләләрне дөрес төзергә һәм кулланырга өйрәнү, тыныш билгеләрен дөрес куярга өйрәнү.

***Метапредмет нәтиҗәләре:*** укучыларның сөйләм телләрен, иҗади фикер йөртү сәләтләрен, танып белү активлыгын һәм мөстәкыйльлекне, бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү, карарлар кабул итү, тормышка ашыру.

***Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:*** активлыкка, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртергә өйрәнү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү.

**Укыту ысуллары:** өлешчә эзләнү ысулы.

**Технологияләр:** компьютер, коммуникатив, уен технологияләре.

**Укыту алымнары:** карточкалар, дәреслек белән эшләү.

**Дәреснең төре:** яңа материалны үзләштерү дәресе, кереш дәрес.

**Предметара бәйләнеш:** татар теле, әдәбият, технология.

**Җиһазлау:** картиналар, интерактив такта, карточкалар, колонкалар, дәреслек.

**Дәрес планы**

**1) Мотивлаштыру-ориентлаштыру. (10мин)**

**Дәресне оештыру. (2 мин)**

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, уңай психологик халәт тудыру.

2) Актуальләштерү. (6 мин)

Татар мәдәнияте турында сөйләшү.

Мәдәни карта турында аңлату.

Әкиятләр.

Җөмлә төрләре турында мәгълүмат бирү.

**3. Танып белү эшчәнлеге. (19 мин)**

1. Дәреслек белән эш (кагыйдәләр уку).

2. Төркемнәрдә эш (милли ризыклар).

3. Карточкалар белән язма бирем (халык бәйрәмнәре).

4. «ТИЗЗАРЯДКА» «борма» бию хәрәкәте өйрәнү (халык биюләре).

5. Интерактив уен «Ат чабышы» (милли киемнәр).

II. Рефлексив бәяләү. (6 мин)

Йомгаклау.

Пультлар белән тест.

Үзбәя; билгеләр кую.

Өй эше. (Милли бизәк рәвешендә.)

**Дәрес конспекты**

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

1. Дәресне оештыру.

Укытучы. Исәнмесез, укучылар!

Хәерле көн телимен мин
Сезгә чын-чын күңелдән,
Теләкләрнең иң сафлары
Чыга күңел түреннән.

Хәерле көн, укучылар! Кәефләр ничек? Бик яхшы рәхмәт, укучылар. Бер елмаю көне буена җитәрлек яхшы кәеф бирә, диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезгә карап, елмаеп алыйк. Дәресебез уңышлы үтәр, дип уйлыйм.

**Актуальләштерү.**

**Укытучы.** Укучылар бу нәрсә? (Карта.) Бу нинди карта? (Тарихи карта.)

Ә монысы нинди карта? (Географик карта.)

**Укытучы.** Укучылар, без бүген башка төрле карта ясарбыз. Ә менә нинди икәнен хәзер үзебез билгеләрбез.

(Экранга рәсемнәр чыгарыла. «Логика кайда?» (Татар халык җырлары, биюләре, бәйрәмнәре йолалары.) Укучылар, бу рәсемнәрдә логика кайда? Аларны бер сүз белән ничек әйтә алабыз? (Культура; мәдәният; татар халкына карый; татар мәдәнияте.)

**Укытучы.** Бик дөрес! Бүген без сезнең белән мәдәни карта ясарбыз.

Игътибар итегез әле, сезнең алдыгызда карта макетлары ята. Бу кайсы ил яисә төбәк картасы булыр икән? (Бу – Татарстан Республикасы картасы.)

Укытучы. Афәрин! Әлегә алар буш. Дәрес дәвамында татар мәдәниятенең байлыгын күрербез. Сез әзерме? (Әзер!) Алайса башлыйбыз!

Экранга игътибар белән карагыз, тыңлагыз һәм уйлагыз. Бу нинди геройлар? Алар нинди интонация белән сөйләшәләр?

(Экранда татар халык әкияте геройлары төрле җөмләләр әйтәләр. Видео карыйбыз.)

«Ак бүре». Ак бүре. Кем рөхсәте белән урмандагы үләннәрне таптап килеп кердегез?

«Өч кыз» әкияте. Төлке. Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма!

«Төлке белән Каз». Каз. Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит.

**Укытучы.** Укучылар, бу нинди геройлар? (Бу – татар халык әкияте геройлары.) Афәрин! Бик дөрес! Әкиятләрдә халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган.

Әйдәгез, карталарыбызга әкият тамгасынябыштырып куйыйк әле. Әкиятләр, фольклор материаллары татар халкының мәдәниятен тәшкил итә.

**Укытучы.** Укучылар, әлеге җөмләләр нинди интонация белән әйтеләләр? Нинди җөмләләр кулланылган?

Көтелгән җавап. Хикәяләү, сорау, боеру, мөрәҗәгать. Сорау җөмләне укыганда сорау интонациясе белән, боерык җөмләне боеру интонациясе белән, хикәя җөмләне хәбәр итү интонациясе белән укыйбыз.

**Укытучы.** Укучылар, бу җөмләләргә тыныш билгесе куелмаган. Әйтегез әле, сез нинди тыныш билгеләре беләсез? (Нокта, сорау, өндәү.)

Ә бу җөмләләрдә нинди тыныш билгеләре куярсыз? Укучылар, әгәр без дөрес интонация белән сөйләшмәсәк, нәрсә булырга мөмкин?

( Кешеләр безне дөрес аңламаска мөмкин.)

**Укытучы.** Әйе, бик дөрес, укучылар, шуңа күрә дөрес, матур итеп сөйләшергә кирәк. Бәлки, киләчәктә кайберләрегез журналистлар, радио-телевидение хезмәткәрләре, дикторлар булып китәрсез. Димәк, без җөмләләрне ничә төргә бүлдек?

Көтелгән җавап. Өч төргә бүлдек. Хикәя, сорау, боерык.

**Укытучы.** Димәк, без бүген нинди тема үтәрбез? («Җөмлә төрләре» темасы үтәрбез, «Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре»).

Афәрин, укучылар! Без бүген дәрестә нәрсәгә өйрәнербез? (Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрне дөрес итеп укырга,

язганда җөмлә ахырында тыныш билгеләре куярга өйрәнербез.)

**3. Танып белү эшчәнлеге.**

**Укытучы.** Укучылар, әйдәгез әле, дәреслекләрнең 115 нче һәм 118 нче битләрендәге кагыйдәләр белән танышыйк. Безнең фикерләр дәреслек авторлары фикерләре белән туры киләме икән? Бүген без тирәнтен хикәя һәм сорау җөмләләрне укырбыз. (Дәреслектән кагыйдәләрне карыйбыз, укыйбыз.)

Тактада схема бирелә. (Укучылар укыган вакытта, укытучы тактада күрсәтеп, ишарәләп ала.)

**Укытучы.** Укучылар, бу нинди бәйрәм? (Сабантуй.)

Сезнең Сабантуй бәйрәмендә булганыгыз бармы? Нинди бәйге ярышларын беләсез? (Туры колгага менү, көрәш, авыш колгага менү, йөгереш, аркан тарту, ат чабышы һ.б.)

Бик дөрес! Бүген без сезнең белән ат чабышында катнашырбыз. Әйдәгез әле, атыбызга исем уйлыйк. («Алмачуар» булсын.)

**Укытучы.** Атыбыз финишка беренчерәк килеп җитсен өчен безгә сорауларга җавап бирергә кирәк. Сез әзерме? (learning.app программасында уен эшләнә.) Әйдәгез, такта янына рәхим итегез.

Җөмлә төрләре (хикәя, сорау, боерык).

Нинди тавыш белән (тыныч тавыш).

Татар хатын кызларының баш киеме?

Укучылар, баш киеме ничек атала? (Калфак.)

Чыннан да, калфак татар хатын-кызларының баш киеме.

Милли киемнәр элек-электәннән иң затлы, иң матур, якты төстә булганнар. Милли кием халкыбызның мәдәниятен тәшкил итә. Укучылар, әйдәгез, татар халык киемнәре тамгасын макетка ябыштырып куйыйк.

**Укытучы.** Сезнең алдыгызда төсле конвертлар ята. Шуларны ачыйк. Биремне кычкырып укыйбыз.

**Карточка.**

**Хикәя җөмләләрне сорау җөмләләргә әйләндереп языгыз.**

1. Сабантуй бәйрәмендә капчык сугышы уены бар.
2. Яңа ел көннәрен Нардуган вакыты дип йөрткәннәр.
5. «Карга боткасы» бәйрәмендә ботка пешергәннәр.

**Укытучы.** Бу җөмләләр нинди темага язылганнар? (Татар халык бәйрәмнәре белән бәйле.) Татар халык бәйрәмнәре – мәдәниятебезнең бер өлеше, мәдәни коды. Әйдәгез, халык бәйрәмнәре тамгасын тактага беркетик. Димәк, халык бәйрәмнәре – мәдәниятебезнең аерылгысыз элементы. (Укытучы тактадагы макетка беркетә.)

Укучылар, күп эшләдек, бик тырыштык, ә хәзер ял итеп алыйк.

Татар биюе шулай ук халыкның үзенчәлеген чагылдыра.

Без сезнең белән бүген үзенчәлекле күнегү өйрәнербез. Күнегүне игътибар белән карыйбыз һәм кабатлыйбыз. (Укытучы күнегүләрне күрсәтә, аннан укучылар белән музыка «Бөрлегән» көе астында бергәләп кабатлый.)

Әйдәгез, бию тамгасын алып ябыштырып куйыйк. Халык бию-хәрәкәтләре мәдәниятебездә аерым урын алып тора. (Укытучы тактада ябыштыра.)

**Укытучы.** Өстәлләрдә татар халык ашларын күрәсез.

Беренче төркем сездә нинди аш?

(Өчпочмак, бәлеш, кыстыбый.)

Укучылар, төркемнәрдә җөмләләрне укыгыз, киңәшләшегез һәм җавапларны тәкъдим итегез.

**Татар халык ризыгын кулланып, хикәя һәм сорау җөмләләрне кертеп, кечкенә генә диалог төзегез.**

**Өчпочмак.**

**Бәлеш.**

**Кыстыбый.**

**Укытучы.** Афәрин! Татар халкы милли ашларга бик бай. Күп гасырларга сузылган тарих дәвамында милли оригиналь ашлар барлыкка килгән, алар үзләренә генә хас сыйфатларны әлегә кадәр саклаганнар. Әйдәгез, татар халык ашлары тамгасын карталарыбызга ябыштырып куйыйк. *(Укытучы тактадагы макетка ябыштыра.)*

**Рефлексив бәяләү**

**Укытучы.** Укучылар, бүген без дәрестә нинди тема турында сөйләштек? (Татар халкы мәдәнияте, традицияләре.) Тагын нинди тема үттек? (Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. Хикәя һәм сорау җөмлә.)

Әйдәгез әле, үзебезгә бәя бирик, бер-беребезнең белемнәрен тикшерик.

Интерактив пультларны алабыз. Дөрес җавапка туры килгән тамгага басабыз.

**Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре?**

А) Хикәя, сорау, максат

Ә) Сорау, боерык, шарт

**Б) Хикәя, сорау, боерык**

В) Сорау, фигыль, хикәя

**2. Кайсы җөмлә ахырында сорау куела?**

А) Бүген Сабантуй бәйрәме була

**Ә) Син бүген калфак киденме**

Б) Әби гөбәдия пешерде

В) Кунаклар татар халык көенә биеделәр

**3. Хикәя җөмлә нинди интонация белән әйтелә?**

А) Сорау интонациясе

Ә) Боеру интонациясе

**Б) Хикәяләү интонациясе**

В) Тойгы белән

Укучылар, грамматик темабызны аңлагансыз икән. Бик яхшы үзләштергәнсез.

**Өй эше**

120 нче бит, 238 нче күнегү. Хикәя җөмләдән сорау җөмләләр төзегез.

5 сорау һәм биш хикәя җөмлә язып килергә.

Әйтү максаты ягыннан төрле җөмләләрне кулланып, «Карга боткасы» темасына алты җөмләле диалог язып килергә.

**Укытучы.** Укучылар, дәресебез шундый күңелле үтте.

Безнең мәдәни картабыз да барлыкка килде. Бүген без сезнең белән татар халкының мәдәниятенә караган өлкәләрне искә төшердек. Без мәдәнияткә нәрсәләр керә, дидек? Әйдәгез, бергәләп бу сүзгә җавап табыйк. Сезнең өстәлләрегездә ак битләр ята. Аларны алып, дөрес тәртиптә тактага ябыштырыгыз. Мәдәният ул – ...

( 3 укучы чыга, тактага ябыштырып куялар.)

«Мәдәният – халыкның рухи көзгесе».

**Укытучы.** Әйдәгез әле, укучылар, дәресебезнең девизын горурланып әйтик, горурланып тәмамлыйк. ( Мәдәният – халыкның рухи көзгесе!)

Укучылар, мин дә сезнең киләчәктә халкыбызның горурлыгы булырсыз, туган телебезне онытмассыз дигән теләктә калам!

Сез бик тырыш, бик актив, бик белемле укучылар!

10




# ЛЕКСИКОЛОГИЯ. СҮЗНЕҢ ЛЕКСИК МӘГЪНӘСЕ

*(5 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Миләүшә АЛЕКСЕЕВА,**

Казан шәһәре 187 нче күппрофильле лицейның югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** тел белеменең лексикология бүлеге турында мәгълүмат бирү, аның үзенчәлекләрен ачыклау, сүзнең лексик мәгънәсе турында төшендерү; укучыларның сүз байлыгын арттыру; мөстәкыйль фикерли алу, гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясый белү күнекмәләрен үстерү; укучыларда үз-үзләренә карата таләпчәнлек, төгәллек, әйләнә-тирә дөньяга, янәшәдәге кешеләргә карата игътибарлык, ярдәмчеллек сыйфатлары булдыру, әхлак тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:* уку материалына кызыксыну уяту; уку эшчәнлеген мотивлаштыру, иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру.

*Метапредмет нәтиҗәләре:*

Танып белү УУГ: булган белемнәргә таянып, танып белү процессында катнашу, гомуми нәтиҗәне чыгару.

*Коммуникатив УУГ:* уку һәм танып белү процессында позитив мөнәсәбәтләр булдыру; фикереңне дөрес әйтә белү.

*Регулятив УУГ:* алган белемнәрне истә тотып, күнегүләр башкару; эш этапларын истә тотып, аларга ияреп, мөстәкыйль эшләү.

*Предмет нәтиҗәләре:* сүзләрне сөйләмдә урынлы куллана белү.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне үзләштерү дәресе

I. Мотивлаштыру-ориентлашу. Уңай психологик халәт тудыру.

| | |
|---|---|
| Исәнмесез, укучылар!<br>Хәерле көннәр сезгә.<br>Зиһен һәм тел ачкычлары<br>Телим һәрберегезгә. | – Матур үтсен көнебез!<br>Көләч булсын йөзебез!<br>Дөрес, матур утырыйк,<br>Тырышып җавап бирик! |

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

**Укытучы.** Укучылар, сез инде тел белеменең берничә бүлеген өйрәндегез, шулай бит? Исегезгә төшерегез әле, нинди бүлекләр алар? *(Фонетика, орфоэпия, графика, орфография.)*

**(3 нче слайд)**

**Укытучы.** Өйрәнгән бүлекләр буенча белемнәрне тикшереп алыйк әле:

| | |
|---|---|
| – Фонетика бүлеге нәрсәне өйрәнә? | – Сөйләм авазларын өйрәнә. |
| – Орфоэпия бүлеге нәрсәләрне өйрәнә? | – Сүзләрнең дөрес әйтелешен өйрәнә. |
| – Графика бүлеге нәрсәләрне өйрәнә? | – Сөйләм авазларының язуда бирелүен өйрәнә. |
| – Орфография бүлеге нәрсәне өйрәнә? | – Сүзләрне дөрес язарга өйрәтә. |

**III. Уку мәсьәләсен кую**

**Укытучы.** Хәзер, киресенчә, мин билгеләмәне әйтәм, ә сез җавапларын әйтегез. Кроссвордта безнең дәреснең темасы белән бәйле сүз килеп чыгар.

Сөйләм авазларын өйрәнә – **фонетика.**

Сүзләрнең дөрес әйтелешен өйрәнә **орфоэпия.**

Сөйләм авазларының язуда бирелүен өйрәнә – **графика.**

Сүзләрне дөрес язарга өйрәтә – **орфография.**

Сөйдергән дә шул,
Биздергән дә шул.
Иң татлы да шул,
Иң ачы да шул – **тел.**
Бер байлык бар – янмый,
Карак та урлый алмый,
Төшеп тә югалмый – **белем.**
Әйтермен – миннән китәр,
Тыңламасаң – синнән китәр – **сүз.**

**(2 нче слайд)**

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 5 т | е | **л** | | | |
| | | | 6 б | е | л | **е** | м | | |
| 1 ф | о | н | е | т | и | **к** | а | | |
| | | | | | | 7 **с** | ү | з | |
| 2 о | р | ф | о | э | п | **и** | я | | |
| | 3 г | р | а | ф | и | **к** | а | | |
| 4 о | р | ф | о | г | р | **а** | ф | и | я |

**Укытучы.** Нинди сүз килеп чыкты? *(Лексика.)* Укучылар, бүгенге дәрестә без тел белеменең яңа бүлеген өйрәнә башларбыз. Нинди бүлек икән ул? Лексика белән бәйле.

**(3 нче слайд)** Экранга карагыз әле: уку елы башында без кластер төзегән идек. Әйе, фонетикадан соң ЛЕКСИКОЛОГИЯ бүлеге башлана. Ул – безнең дәресебезнең темасы. **(Кластерга ЛЕКСИКОЛОГИЯ сүзе куела.)**

**(4 нче слайд)**

Лексика нәрсә ул? Лексикология нәрсәне өйрәнә торган фән?

Сүзнең «лексик мәгънәсе» нәрсәне аңлата?

Бүгенге дәрестә безнең максатыбыз – менә шушы сорауларга җавап табу. Бу сүзләрнең яңгырашы охшаш, ләкин төшенчәләрендә аерма бар. Без менә шул төшенчәләрнең аермасын ачыкларбыз.

Шагыйрь Йосыф Гәрәй сүз турында болай яза: «Нинди генә сүзләр юк! Нәфисләре бар. Күңелсезләре. Мөлаемнары күп. Ачулылары. Хәтта мәкерлеләре йөри телдән-телгә.

Ачык күңелле сүзләр бик ишле. Моңлылар да аз түгел. Күңелсезләр, купшылар, шаяннар, ямьсезләр дә җитәрлек.

Кайсыберләре ялтырап тора, гүя зөбәрҗәт. Икенчеләре дөм караңгы. Әйтерсең мунча ташы.

Бер уйласаң, сүз җанлы кебек. Хәтта кеше кебек алар, берсе ачык йөзле, берсе шыксыз чырайлы. Төрле төс ала сүз. Ачу белән әйтелсә, «зифа» да зифа түгел. Елмаеп туса, «юньсез» дә күркәм».

**IV. УМ адымлап чишү**

**Укытучы.** Сүзләрнең нинди генә юк икән, укучылар. Ә нәрсә соң ул сүз? *(... җаваплар)*


Аның мәгънәсен аңлатмалы сүзлектән эзләп табып була. *(244 нче биттән укыйлар.)* Бу сүзлектә һәр сүзнең мәгънәсе бирелгән.

**Карточкалар таратыла. «Артык сүз» уены.** Парларда эшлибез. «Артык» сүзне түгәрәкләп алыгыз.

яфрак, үлән, чәчәк, кәҗә
нарат, усак, алма, чыршы
Искәндәр, Акбай, Алия, Марат
парта, укучы, урындык, экран

**Укытучы.** Укучылар, бу сүзләрнең артык икәнен каян белдегез? *(Сүзнең мәгънәсенә карап белдек.)* **(5 нче слайд)** *(Экраннан кагыйдәне укыйлар.)* Әйе, һәр сүз билгеле бер мәгънә белдерә, ул лексик мәгънә дип атала. Лексик мәгънә ул – сүзнең үзенә генә хас мәгънәсе.

**(6 нчы слайд)** Рәсемнәр астына мәгънәләре буенча туры килә торган сүзләрне яз. Кем күбрәк яза?



Менә рәсемнәр астында сүзләр җыелмасы хасил булды. Димәк, лексика нәрсә икән инде?

**(7 нче слайд)** *(Экраннан кагыйдәне укыйлар.)*

Телдәге барлык сүзләр җыелмасы

лексика дип атала. Димәк, телнең лексикасын сүзләр тәшкил итә.

*(Кластерга ЛЕКСИКА сүзе куела. )*

**Укытучы.** Рәсемдә агачлар, үсемлекләр, хайваннар, кошлар бирелгән. Алар турында сез кайсы фәннәрдән укып беләсез? – Биология.

Экология дигән сүз дә бар. Экология – (грек сүзе) «Ойкос» – йорт, ә «логос» фән дигәнне аңлата, яшәгән урының, йортың турындагы **фән**.

Ә инде телнең сүзлек составын өйрәнә торган фән ничек аталыр? Әйе, лексикология дип атала.

**(8 нче слайд)** *(Экраннан кагыйдәне укыйлар.)*

**Ял минуты**

Без әле бераз ардык,
Ял итәргә уйладык.
Башны иябез алга,
Ә аннары – артка.
Уңга, сулга борабыз,
Аннан карап торабыз.

**V. Белемнәрне ныгыту**

**1.** Карточкалар таратыла. «Кем тизрәк?» уены.

Ак – кара, җылы – салкын, якты – караңгы.

Әдәпле, инсафлы, тәртипле, тыйнак.

Зирәк, зиһенле, тапкыр, акыллы.

Авыртмасын дисәң эч,
Кайнаган су гына эч.

**Укытучы.** Укучылар, бу сүзләрнең антоним, синоним, омонимнар икәнен каян белдегез? (Сүзнең мәгънәсенә карап белдек.)

**Кластерга АНТОНИМ, СИНОНИМ, ОМОНИМ сүзләре куела.**

2.- Сүзнең лексик мәгънәсен аңлатуның берничә юлы бар. Кластердан карап әйтәбез.

– Сүзгә кыскача аңлатма бирергә.
– Синонимнарын сайлау.
– Антонимнарын сайлау.
– Тамырдаш сүзләр сайлау.
– Рәсем яки фотография бирү.

Матур – 1 нче төркем. Сәламәтлек – 2 нче төркем.

3.«Тамчы шоу» уенына чыгабыз. Һәр төркемдә 4 әр укучы.

Укый, яза белмәүче кеше – надан.
Утыру өчен җайланма – урындык.
Салкын тиюдән саклый торган яшелчә – сарымсак.
Әнинең әнисе – әби.
Курку белмәс, тәвәккәл кеше – батыр.
Нәниләр яратып ашый торган азык – ботка.
Күзен һәм язын төсен алыштыра торган йорт хайваны – куян.
Безгә төнлә генә күренә торган җирнең ясалма иярчене – ай.
Мөгезле эре терлек – сыер.
Өйгә яктылык керсен өчен куела – тәрәзә.

**VI. Рефлексия**

**1. Сүзнең лексик мәгънәсе нәрсәне аңлата?**

а) сүзнең авазлардан торуын
ә) сүзнең грамматик төзелешкә ия булуын
**б) сүзнең үзенә генә хас мәгънәсе**
в) җавапларның берсе дә дөрес түгел

**2. «Лексика» нәрсә ул?**

а) сүзлекләр
ә) сүз
б) тотрыклы сүзтезмәләр
**в) телдәге сүзләр җыелмасы**

**3. «Лексикология» нәрсәне өйрәтә торган фән?**

а) телдәге авазларны
**ә) телнең сүзлек составын**
б) сүз ясалышын
в) җөмлә төзелешен

– Укучылар, без алдыбызга куйган уку мәсьәләсен чишә алдыкмы?

**VII. Билгеләр кую**

**Өй эше**

1. 215 нче күнегү.
2. * 216 нчы күнегү (Ш. Булат һәм Х. Кәрим).




# ТУГАН ТЕЛЕМ – ИҢ ТӘМЛЕ ТЕЛ

*(6 нчы сыйныфта татар әдәбияты. Алдагы дәрестә алган белемнәрне системалаштыру)*

**Зиләрә ГЫЙРФАНОВА,**

Казанның 146 нчы «Ресурс» лицееның I квалификация категорияле туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы

| | |
|---|---|
| Дәрес тибы (технологик төзелеше) | Уку мәсьәләсен кую һәм чишү. |
| Дәрес темасы | «Туган телем – иң тәмле тел». |
| Предметара бәйләнеш | Рус әдәбияты, тарих. |
| Эшне оештыру | Төркемдә, парларда, индивидуаль эшләү. |
| Төп төшенчәләр | Билгеләмә бирү, тәрҗемә итү, анализ ясау. |

**Максат:**

*Дидактик* – Мәҗит Гафури иҗаты турында белемнәрне системалаштыру; язучының иҗаты турында сөйләү, сөйләгәннәр буенча анализ ясау.

*Үстереш* – әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, ишетә белү, ишеткәнеңне үз фикерең белән чагыштыру, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру.

*Тәрбияви* – төркемнәрдә дустанә аралашып эшләү культурасын үстерү, татар шагыйрьләре иҗатына кызыксыну тәрбияләү.

**Формалашырга тиешле универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

***Шәхескә кагылышлы:*** укучыларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, туган телне яратырга, хөрмәт итәргә юнәлеш бирү; иптәшеңә терәк, таяныч булу (төркемдә, парда эшләгәндә); дөрес сөйләргә омтылу, үз сөйләм хаталарыңны тану, төзәтү; шәхесне (янындагы иптәшеңне) кимсетүдән саклану, вакытында тыелып калу.

***Метапредмет:***

*Регулятив***:** УМ куя белү, төркемдә чишү юлын билгеләү, адымлап биремнәр үтәү, нәтиҗә ясау һәм аны дөрес формалаштыру, үзбәя кую.

*Танып белү***:** әңгәмәдәшеңнән ишеткәнне үз фикерең белән чагыштыру.

*Коммуникатив:* әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, ишетә белү, чират белән чыгыш ясау, үз фикереңне курыкмыйча дәлилли белү, диалогик сөйләм күнекмәсен камилләштерү.

**Материал һәм җиһазлау:**

1. Методик кулланма. Татар әдәбияты. 6 нчы сыйныф / Ф.Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина. – Казан: Мәгариф – Вакыт нәшр., 2014.
2. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен методик әсбап. 6 нчы сыйныф / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина. – Казан: Мәгариф – Вакыт нәшр., 2014.
3. Компьютер, проектор, экран. PowerPoint программасында презентация.
4. «Татар теле – шагыйрьләр теле» китабы.
5. Ф. С.Сафиуллина, Г.Б.Ибраһимов. «Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел» китабы.

**Дәрес барышы**

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучылар эшчәнлеге** | **Көтелгән нәтиҗәләр (предмет УУГ)** |
|---|---|---|---|
| Мотивлаштыру этабы (3мин) 1) уңай психологик халәт тудыру | Укучыларны сәламләү, аларны уку эшчәнлегенә тарту. | Сәламләшү. Дәрескә әзерлек. Дәрестә төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшерү. | Бер-береңне сәламли белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| II. Белемнәрне актуальләштерү | Без үткән дәрестә нинди УМ (уку мәсьәләсе) өстендә эшләдек? | Мәҗит Гафуриның «Ана» шигырен өйрәндек. | |
| III. УМ кую ситуациясе (3 мин) | **(1 нче слайд)** «Туган телем» җыры тыңлана.<br>Бу җыр нәрсә турында? Шуның белән бәйләп, дәрескә УМ билгеләгез. | **Көтелгән җавап.**<br>Бу җырда туган тел турында сөйләнелә.<br>Без дә туган тел турында сөйләшербез. | Җырның эчтәлеген аңлата белү. |
| | Тактага теманы язу: «Туган телем – тәмле телем». | Дәфтәрләргә теманы язу. | Башкалар белән беррәттән теманы дөрес һәм матур итеп яза белү. |
| IV. Танып белү эшчәнлеге. Уку мәсьәләсен чишү (4 мин) | **1 нче бирем.** Нәрсә соң ул туган тел? Шул сорауга җавап биреп карагыз әле Моның өчен ДЖОТ ТОТС (үз фикереңне яз) структурасы ярдәмендә, сез аларны кәгазь битләренә язып чыгарсыз. Кәгазьне 1 нче төркем укучылары 2 кисәккә бөклиләр, аннары 3 нче төркем укучылары, тагы икегә аерып, командадагы һәр укучыга бирәләр. Алар, һәрберсе 4 кисәккә бөкләп, үзләренә язарга кечкенә битләр әзерлиләр. Аларны язабыз һәм кычкырып укыйбыз. Һәр өстәл нәтиҗә ясый, һәм 1 нче төркем укучылары һәр өстәлнең нәтиҗәсен укыйлар.<br>**(2 нче слайд)** Туган тел турында күренекле кешеләрнең фикерләрен уку.<br>И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!<br>Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.<br>(*Г. Тукай)* | Үз фикереңне белдерү. Төркемнәрдә фикер алышу, башкаларныкын да өстәп язу. Кемнең ничек катнашуына карап, бер-беребезне бәялибез.*Үзбәя.* | Туган телгә билгеләмә бирә алу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | – Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Ул ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бергә торган бөек, изге һәм кадерле сүз!<br><br>*( Г. Бәширов)*<br>Моңлы тел ул, нурлы тел – туган тел.<br>Баш очында кояш булып тора гел.<br><br>*(Факил Сафин)*<br>Әй син, телем, туган телем, тамыр телем.<br>Җир астыннан тарих серен табар телем...<br>Әй син, телем, рәхәт телем, авыр телем.<br>Телне тешләп канатырлык сабыр телем...<br>*(Лена Шагыйрьҗан)* | | |
| Өй эшләрен тикшерү (4 мин) | – Кем соң ул Мәҗит Гафури?<br>– Аның тормыш юлы турында ниләр белдегез?<br>– Сез аның нинди әсәрләрен беләсез?<br>– Без аның кайсы әсәрен өйрәндек?<br>– «Ана» шигыре нәрсә турында? | Укучылар Мәҗит Гафури иҗатын сөйләп күрсәтәләр. М. Гафуриның әсәрләрен санап чыгалар («Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек», «Карт ялчы», «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Ана», «Кара йөзләр», «Кыр казы»...) | |
| 3 мин | **Ял минуты**. Без сезнең белән хәзер аз гына ял итеп алабыз. Сорауларның җавапларын без сайлап кына алырбыз. Безгә моның өчен ТЭЙК ОФ – ТАЧ ДАУН (Встать – сесть), ягъни (утыр – тор) структурасын үтәргә кирәк булыр. Мин әсәрнең эчтәлегенә туры килгән яки туры килмәгән җөмләләрне укып барам, әгәр дөрес икән сез торып басасыз, ә дөрес булмаса утырасыз.<br>**(3 нче слайд)**<br>1. Мәҗит Гафуриның «Ана» шигырендә укучы бала турында сөйләнелә.<br>2. Кечкенә сабый йоклый, елый, көлми... | **Көтелгән җавап.**<br>Дөрес җаваплар:<br>*– М.Гафуриның «Ана» шигырендә нәни бала турында сөйләнелә.*<br>*– Кечкенә сабый йоклый, елый, көлми...*<br>*– Әнисе баласын тәрбия кылды.*<br>*– Әни кеше төнлә йокламады.*<br>*– Бала мәктәпкә киткәч, әнисе бик шатланды.*<br>*– Әнисе баласының яхшы укуын теләде.* | Әсәр эчтәлеге буенча уен оештыра алу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3. Әнисе баласын тәрбия кылмады.<br>4. Бала да, әнисе дә төнлә белән йокладылар.<br>5. Бала мәктәпкә киткәч, әнисе шатланмады.<br>6. Әнисе баласының яхшы укуын теләде. | | |
| V. Яңа белемнәрне куллану (3 мин) | 1. Без бүген, балалар, М. Гафуриның тагын бер шигырен өйрәнербез. 43 нче бит «Ана телем» шигыре.<br>2.Башта авыр сүзләрне карап алыйк әле.<br>3. Әйдәгез, чиратлап укыйк.Чылбырлап, «Ана телем» шигыре укыла.<br>Бу шигырь нәрсә турында? Ниләр аңладыгыз?<br>43 нче биттәге сорауларга җавап бирәбез:<br>1.Туган тел турында кайсы авторларның нинди әсәрләрен хәтерлисез?<br>2. М. Гафури ана теле турында, башка язучылардан аермалы буларак, ничек әйтә?<br>3. Дөньяны танып белү өчен, ана теленнән башка тагын нинди телләр белергә кирәк дип уйлыйсыз? | Сүзлек эше:<br>Макъсудымны – максатымны –свою цель.<br>Иман – вера в бога, вероисповедание.<br>Үгрәнәм – өйрәнәм – учусь.<br>Чактук – чакта ук – в то время<br>Көй – мелодия, музыка.<br>Хисап – счёт, математика. | Сөйли алу. |
| 4 мин | **2 нче бирем.** Әйтегез әле, балалар, туган телне белү ул, сөйләшә белү генәме?<br>ПЛЕЙСМЭТ КОНСЕНСУС (Карта согласия – килешү картасы) ясарбыз.<br>2 нче төркем укучылары кәгазьне башта икегә, аннары тагын икегә бөклиләр.<br>3 нче төркем укучылары, битне ачып, уртасына квадрат ясыйлар, бөкләм буенча сызып чыгалар һәм аның эченә сорауны язып куялар. «Телне белү ничек була?». Һәр укучы үз өлешенә тигән квадратка фикерен яза. 1 нче төркемнән башлап, язганнарыгызны кычкырып укыгыз, калган укучылар, ошаса, баш бармакларын күтәреп, җавапны кабул итәләр. Аннары уртак фикерләрегезне шакмак эченә язып куегыз. Ә хәзер инде барыгыз да сайлаган җавапны укыйбыз. | **Көтелгән җавап.**<br>1. Дөрес итеп укый, яза сөйләшә белү.<br>2. Аның әдәбиятын, сәнгатен, тарихын, мәдәниятен белү.<br>3. Аның гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен белү.<br>4. Аның милли киемнәрен, милли ризыкларын белү. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Онныту<br>(3 мин) | **3 нче бирем.** Ә хәзер бер җыр тыңлыйк. Ул да туган тел дип атала.Сезгә бу шигырь ошадымы? Ни өчен? Бу шигырьдәге бала ни өчен кайгыра?<br>**И родной тел**<br>И родной тел, и красивый тел,<br>Мамам-папамның теле.<br>Мог я узнать күп нәрсәне<br>Син родной тел аркылы.<br>Бу языкта коляскада<br>Мамам сказку көйләгән.<br>А затем төннәр буенча<br>Бабуля рассказ сөйләгән.<br>А потом ни сәбәптәндер<br>Өйрәткәннәр рус язык.<br>Якобы тик шушы телдә<br>Алам духовный азык.<br>Почему же нас детсадта<br>Сиңа өйрәтмәделәр?<br>В школе когда обучали,<br>Синдә өйрәтмәделәр?<br>И родной тел, и красивый тел,<br>Мамам-папамның теле,<br>Только я их обвиняю<br>Өйрәтмәгәнгә сине.<br>И родной тел, аңлаталар,<br>Можно жить и без синсез,<br>Мама, папа и бабуля<br>Оставили меня телсез.<br>*(Вил Казыйханов)* | **Көтелгән җавап**. Бу шигырьдә рус теле белән татар телен бутап бетергәннәр.<br>Бала ни татарча, ни русча сөйләшми. | Үткәрелгән чаралар турында мәгълүмат бирә алу. |
| 4 мин | Ә хәзер шигырьләр укып карыйк әле. Аларда нәрсә турында әйтелә икән? Сез үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз?<br>Татарча да яхшы бел,<br>Урысча да яхшы бел.<br>Икесе дә безнең өчен<br><br>Иң кирәкле, затлы тел.<br>Татарчасы – туган тел,<br>Безгә газиз булган тел.<br>*)*<br>Атаң-анаң, әби-бабаң<br>Сине сөя торган тел.<br>Тел кешене дус итә,<br><br>Бер-беренә беркетә.<br>Бел, балам, син рус телен<br>Һәм онытма үз телең!<br><br>(Шәйхи Маннур) | **Көтелгән җавап.** Башка телләрне өйрәнү ул кирәк әйбер, тик үз телеңне онытырга ярамый. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Күп телләрне белү – яхшы шөгыль,<br>туган телең үги калмаса.<br>Җанын салып әйткән әткәң сүзен<br>синең аша балаң аңласа.<br><br>Мәгълүм: дөнья көтү, заман өчен<br>файдалырак телләр бары да...<br>Тик шунсы хак: фәкать туган телдә<br>иман иңә кеше җанына!<br><br>Киләчәкнең башы – бүгенгедә.<br>Нинди шатлык картлык көнеңдә –<br>оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә,<br>матур итеп туган телеңдә!<br><br>(Равил Фәйзуллин)<br>Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,<br>Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер.<br><br>Катыштырма вәләкин телгә телне,<br>Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.<br>(Дәрдемәнд<br><br>Сез ничек уйлыйсыз, туган тел нәрсә<br>соң инде ул? | | |
| Рефлексив бәяләү этабы (5 мин) | Шулардан чыгып, без дәрестә нинди<br>УМ өстендә эшләдек? Сез үзегез<br>өчен нинди яңа белемнәр алдыгыз?<br>Мин сезгә карочкалар бирәм, ә<br>сез фикерләрегезне язып «Чыгу<br>билетлары»н миңа биреп китәрсез.<br>Аларны язгач, тикшереп алырбыз. Безгә<br>1 нче төркем укып крсәтер.<br>Язылганнар буенча кара-каршы<br>утыручы иптәшләрегезне бәяләгез.<br>*Бәя кую өчен критерийлар:*<br>*1) ул барысын да дөрес әйтте – «5» ле*<br>*2) ул 1 хата ясады – «4» ле*<br>*3) ул 2–3 хата ясады – «3» ле* | – Без туган тел турында сөйләштек.<br>– Мәҗит Гафури иҗатын өйрәндек.<br>– Туган тел турында шигырьләр укыдык.<br>– Башка телләрне өйрәнгәндә дә, үз телеңне онытмаска кирәген белдек.<br>– Төрле телләрне бутап сөйләшмәскә кирәклеген төшендек. | |
| Өй эше бирү (3 мин) | 1. «Ана телем» шигыре буенча 4<br>нче сорауга җавап бирергә. ( Бөтен<br>дөнья халкы бер генә телдә сөйләшсә,<br>әйбәтрәк булмасмы икән? Ни өчен<br>халыклар үз телләрен саклап калырга<br>тырыша?)<br>2. Туган тел турында 5 мәкаль язып<br>килергә.<br>3. Теләгән кешегә «Ана телем» шигырен<br>ятларга. | | |
| | Г.Тукайның «Туган тел» җырын җырлау. | | |

12



# УКУ ЭШЧӘНЛЕГЕН ҺӘМ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮДӘГЕ АЛЫМНАР

*(Туган (татар) тел һәм әдәбият укытучылары өчен осталык дәресе)*

**Айсылу МӨХӘММӘТОВА,**

Казанның 146 нчы «Ресурс» лицееның туган (татар) тел һәм әдәбият, инглиз теле укытучысы

Теләсә кайсы телне өйрәнү барышында уку эшчәнлеге төп урынны алып тора. Балаларны ничек уку эшчәнлегенә тартырга соң? Әлеге процессны ничек кызыклы һәм мавыктыргыч итәргә? Нинди юллар аша укучыларның сөйләм телен камилләштерергә? Һәм туган (татар) тел һәм әдәбият дәресен ничек иҗади якын килеп оештырырга?

Белгәнебезчә, ФДББС замана укытучысы алдында һәрьяклап камил булган, җәмгыятькә ярашлы шәхес формалаштыру бурычын куя. Функциональ грамоталыкның беренче баскычын тәшкил иткән уку грамоталыгын формалаштыру максатын күздә тоткан дәресләр оештыру – заман таләбе. Ә инде кабул ителгән стандартларда күрсәтелгәнчә, коммуникатив күнекмәләр формалаштыру – безнең тагын бер бурычыбыз.

«Уку – энә белән кое казу», – ди татар халык мәкале. Әлбәттә, әлеге сүзләр белән килешми мөмкин түгел. Шәхсән үзем дә һәрчак актив эзләнүдә булырга тырышам. Бөек мәгърифәтче педагогларыбыз Каюм Насыйри, Мирза Мәхмүтов, Константин Ушинский, Ибраһим Хәлфин, Мөхетдин Корбангалиев кебек әдипләребез – өлге алырлык шәхесләр. Ә инде татар теленнән тыш, инглиз теле белгече дә булуым мине Америка-инглиз галимнәре методикасы белән дә таныштырды.

Тәкъдим итәсе алымым да атаклы Америка педагогы, психология фәннәре докторы, профессор Elliot Aronson тарафыннан 1978 елда гамәлгә ашырыла башлый. Jigsaw-reading – үзара хезмәттәшлекне оештыруга юнәлтелгән алым. Аның төп өстенлеге шунда: ул уку күнекмәләрен генә активлаштыруны түгел, ә монологик һәм диалогик сөйләм эшчәнлеген дә формалаштыруны күздә тота. Jigsaw-reading укучыларның төркемнәрдә эшләвенә һәм коллективның бердәм булуына юнәлтелгән.

Әлеге осталык дәресемнең максаты – укыту грамоталылыгын формалаштыру чарасы буларак Jigsaw-reading алымын куллану буенча тәҗрибә уртаклашу.

Алымның структурасы белән якыннанрак танышып китик. Ул үз эченә берничә этапны ала.

1 нче этап (укытучының әлеге эш төренә әзерлек этабы). Уку өчен текст әзерләгез. Аны өч яисә дүрт тигез өлешкә бүлегез. Төркемдәге һәр укучы өчен әлеге текстның күчермәсен булдырыгыз.

2 нче этап. Текст эчтәлегендәге авыр аңлаешлы сүзләр белән танышып чыгыгыз, аларның мәгънәсен укучыларга аңлатыгыз. Укучыларны төркемнәргә бүлегез һәм төркемнең һәр әгъзасына үз хәрефләрен тапшырыгыз: беренче төркемдәге укучыларга «А» хәрефе, икенче төркемдәгеләргә «Б» хәрефе, өченче төркемгә «В”» хәрефе. Әлеге төркемнәрнең структурасы түбәндәгечә: ААА, БББ, ВВВ.

Һәр төркемгә текстның бары тик үз өлешен генә бирегез. Мәсәлән, беренче төркемгә текстның беренче өлеше тапшырыла, икенче төркемгә – икенче өлеш, өченче төркемгә – өченче өлеш. Һәр укучыга үз текстын укырга, төркемдә укылган өлешнең эчтәлеге буенча күмәк әңгәмә үткәрергә кирәк булачак. Төркемнең һәр әгъзасы үз текстының эчтәлеге белән таныш булырга тиеш.

Текстның эчтәлеген тагын да яхшырак

аңлау һәм уңышлы нәтиҗәләргә ирешү өчен һәр этаптан соң кечкенә күләмле биремнәр тәкъдим итү бик отышлы булачак. Укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү өчен арт-технология элементларын да кулланырга мөмкин. Беренче этаптан соң мин түбәндәге биремнәрне тәкъдим итәр идем:

1) Үз текстыгызга исем уйлагыз.
2) Үз текстыгызның эчтәлеген ачыклый торган рәсем ясагыз.
3) Текстны өлешләргә бүлегез һәм аның планын төзегез.
4) Тексттан «ачкыч сүзләрне» язып алыгыз.
5) Текстыгызның эчтәлеген «сүзләр чылбыры» ярдәмендә дәфтәр битендә күрсәтегез.

Укучылар төркемнәрдә әлеге биремнәрне башкаралар. Эш күмәк башкарылса да, һәр укучы үз битендә мәгълүматны теркәп барырга тиеш, чөнки ул аның өчен бик яхшы ярдәмлек булачак.

3 нче этап. Биремнәр үтәлеп беткәч, укучыларны төрле төркемнәргә урнаштырыгыз. Текст тәкъдим ителгән битләр кире җыеп алына, ләкин биремнәр башкарылган битләр укучыларда кала. Димәк, һәр яңа төркемдә барлык хәрефләр дә булырга тиеш. Яңа төркемнең структурасы түбәндәгечә: АБВ, АБВ, АБВ. Һәр укучы үзе укыган текстның эчтәлеген аңлаешлы итеп яңа төркемдәшләренә җиткерергә тиеш була. Башта «А» хәрефле укучы, аннан «Б», аннан «В» хәрефле укучы текст эчтәлеген сөйли. Һәр укучыга яңа мәгълүматны истә калдырып барырга кирәк. Текст эчтәлеге сөйләнеп беткәч, биремнәр тәкъдим итәргә мөмкин:

1) Сезне төгәл аңлаганнарына инану өчен яңа төркемдәшләрегезгә сөйләгән текстыгыз буенча 2–3 сорау бирегез.
2) Төркемдәшләрегез белән бергә әлеге текстның тулы версиясенә исем уйлагыз.
3) Сез нинди яңа мәгълүмат белдегез? Текстның планын төзегез.




4 нче этап. Яңа төркемдәге барлык укучылар да текстның эчтәлеген сөйләп, биремнәр үтәлеп беткәч, укытучы сораулар тәкъдим итеп, укучыларның текст эчтәлеген аңлау дәрәҗәсен тикшерергә тиеш. Моның өчен хикәя эчтәлеген чылбыр буенча сөйләтеп карарга мөмкин.

Мәгълүм булганча, туган (татар) тел һәм әдәбият дәресләрендә Jigsaw-reading алымын кулланып, уку эшчәнлеген камилләштерергә, укучыларның төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен булдырырга һәм, ФДББС таләп иткәнчә, коммуникатив компетенцияне, уку грамоталыгын формалаштырырга мөмкин.

XXI гасыр баласын китап уку белән кызыксындыру, ни кызганыч, бик авыр. Ләкин менә шундый үзенчәлекле алымнар аша, иҗади якын килеп, уку процессын кызыклы итеп оештыру бүгенге көндә бик актуаль.

13



# ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘРНЕ КАБАТЛАУ

*(8 нче сыйныфта туган тел дәресе)*

**Гүзәл ДӘҮЛӘТШИНА,**

Апас урта гомуми белем бирү, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәреснең темасы:** «Тезмә кушма җөмләләрне кабатлау».

**Дәреснең максатлары:**

*1.Белем бирү максаты.*

Тема буенча үтелгән материалны гомумиләштерү; тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә кулланырга өйрәтү.

*2. Үстерү максаты.* Укучыларның сөйләм һәм язма телен, фикерләү сәләтен камилләштерү; мөстәкыйль активлыкларын үстерү.

*3.Тәрбияви максат.* Төркемнәрдә эшләгәндә, аралаша, бер-береңне тыңлый белү культурасы, ярдәмчеллек сыйфатлары булдыру; укытучы-остазларыбызга карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** интерактив панель, презентация, таратма материаллар, тезмә кушма җөмләләр таблицасы, дәреслек.

**Дәрес төре:** үткән материалны ныгыту, белем һәм күнекмәләрне камилләштерү.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше**

1. Уңай психологик халәт тудыру.

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Әйдәгез, матур итеп, һәрберебезгә хәерле көн телик.

Хәерле көн, алсу таңнарга! (1 нче төркем)

Хәерле көн, зәңгәр күкләргә! (2 нче төркем)

Хәерле көн, якын дусларга! (3 нче төркем)

Хәерле көн, матур кызларга! (Егетләр)

Хәерле көн, батыр улларга! (Кызлар)

Рәхмәт! Күрегезче, бүген нинди матур көн! Көннең гүзәллегенә сокланып, илебезгә тынычлык теләп, бер-беребезгә карап елмайыйк та дәресебезне башлыйк, укучылар!

**II. Уку мәсьәләсе кую**

**Укытучы.** Бүгенге дәресебезнең темасын билгеләү өчен, ребус чишеп алабыз. Ничек булды? *(Тезмә кушма җөмләләрне кабатлау.)*

Үткәннәрне искә төшереп, кечкенә генә кроссворд эшлибез. *(Ребус һәм кроссворд слайдларда.)*

[ ],[ ], [ ]не  ҟт ,, 

Максатларны әйтеп карыйк.

**Кроссворд чишү өчен сораулар:**

1. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрнең бәйләүче чаралары нинди?
2. Үзара интонацияләр ярдәмендә бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр ничек атала?
3. Үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмләләр ничек атала?
4. Тезмә кушма җөмләләрдә күбесенчә нинди тыныш билгеләре куела?
5. Җыючы теркәгеч.
6. Без бүген нинди төр кушма җөмләләр өйрәнәбез?

Кроссвордтагы вертикаль баганадагы сүзне укыйбыз.

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | и | н | т | о | н | а | ц | и | я |
| т | е | р | к | ә | г | е | ч | с | е | з | | | |
| | | | | | | | ө | т | е | р | | | |
| | | | | | | | т | а | | | | | |
| | | | | | | т | е | з | м | ә | | | |

**Укытучы.** *(Остаз*) Кем соң ул остаз? *(Остаз – укытучы, җитәкче, өйрәтүче. Үз күңеленең бер өлешен башкаларга бүлеп бирә торган кеше, аның белән аралашу рухи үсешкә файда китерә.)* Димәк, бүгенге тел

дәресебез кемнәргә дан җырлаячак? *(Укытучылар һәм остазлар елы белән бәйле булачак.)* Рәхмәт, теманы һәм максатларны билгеләдек. Әйдәгез, хәзер дәфтәрләрне ачып, бүгенге датаны һәм сыйныф эше дип язып куябыз да карточкалар белән эш эшләп алабыз.

**III. Уку мәсьәләсен чишү**

Төркемнәрдә эш.

Һәр төркемгә аерым-аерым карточкалар бирелә. Тезмә кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясыйбыз. 1 укучы тактада эшли. Җөмләне язып куя, җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерә, схемасын төзи, телдән синтаксик анализ ясый.

1. Бу – теркәгечле яки теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.Ул ике җөмләдән тора: беренчесе – ; икенчесе –
2. Гади җөмләләр үзара санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгән.
3. Санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгән җөмләләр арасына өтер куела.
4. Җөмләнең схемасы:[ ], [ ]

**Укытучы.** Хәзер төркемнәрдә бер-берегезнең эшләрен тикшереп алыгыз әле. Афәрин, укучылар!

**Дәреслек белән эш.** Хәзер дәреслек белән эш башкарабыз. 55 нче күнегүнең биремен укыйбыз, дәфтәрләргә эшлибез. Аркаларны төз итеп тотабыз.

**Ял минуты**

Укытучылар турында матур җыр куела һәм һәр төркем укытучылар турында канатлы сүзләр җыя. Тезмә кушма җөмләләрне таба. Телдән тикшереп күрсәтә.

**Укытучы.** Афәрин, укучылар, бүгенге уңышыгыз мине сөендерә.

**IV. Белемнәрне ныгыту**

**Укытучы.** Дәресебезне дәвам итәбез. Игътибарны экранга юнәлтәбез. *(Текст слайдка да куела, укучыларга да таркатыла.)* Танышып чыгу өчен 5 минут вакыт бирелә. Сорауларга җавап бирү барышында, текстның эчтәлеге, темасы ачыла. Исем куела. Һәр төркемгә бер абзац бирелә. Шуннан тезмә кушма җөмләләр табарга кирәк була. *(Габдрахман Әпсәләмовның «Яшел яр» әсәреннән өзекне укып, биремнәрне эшләп, уку грамоталылыгын үстерәбез.)*

**Укучылар.** Текст укытучы Гәүһәр апа турында. Ул барлык күңелен биреп, балаларны укыта, үз балаларыдай якын күрә. Киләчәкләре өчен борчыла.

**V. Рефлексив бәяләү**

**Укытучы.** 1. Сез нәрсә белә идегез?

2. Бүгенге дәрестә нәрсә белдегез?

3. Нәрсә белергә теләр идегез?

**VI. Өй эше** (Слайдта)

**1 нче вариант (мәҗбүри).** Дәреслектәге 56 нчы күнегүне эшләргә. Тиешле тыныш билгеләрен куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.

**2 нче вариант (ярым иҗади).** Тезмә кушма җөмләләр кергән «Уку, гыйлем алу» темасына биш мәкаль табып язарга.

**3 нче вариант (иҗади).** Тезмә кушма җөмләләр кулланып, «Укытучыма» дигән хат язарга.

**VII. Йомгаклау**

**Укытучы.** Укучылар, тезмә кушма җөмләләр турында нинди яңалык белдегез?

**Укучылар.** Күп кенә шигырь мәкаль һәм әдәби әсәрләрдә тезмә кушма җөмләләр кулланылышын белдек. Аларны тексттан табу, аеру өчен күнекмәләрне ныгыттык.

**Укытучы.** Афәрин. Рәхмәт, укучылар! Әгәр сезгә бүгенге дәрес ошаган икән елмаю йөзе, ә ошамаган икән борчулы йөз ясагыз һәм җавапларыгызны миңа күрсәтегез.

**Билгеләр кую.**

**Укытучы.** Игътибарыгыз һәм хезмәтегез өчен зур рәхмәт. Сау булыгыз!




# КИТАП ЯЗМЫШЫ – ХАЛЫК КӨЗГЕСЕ

*(9 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәресе)*

**Раушания КӘБИРОВА,**

Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек урта мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Татарстанның атказанган укытучысы

**Максат:** укучыларны татар китабы язмышы белән таныштыру; китап турында кызыклы фактлар һәм күренекле кешеләрнең фикерләрен укучыга җиткерү; балаларда китапка мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** китап турында күренекле кешеләрнең фикерләре язылган плакат, викторина сораулары, Ә. Кәримуллин турында материаллар; Казандагы Милли китапханә рәсемнәре; китаплар күргәзмәсе һ. б.

**Дәрес барышы**

Тактага күренекле кешеләрнең түбәндәге фикерләре язылган таблица эленә:

1. «Китап – бакча ул, андагы язулар – шул бакчаның гөлләре».

(К. Насыйри)

2. «Китапны – белем чишмәсен яратыгыз... Тик ул гына безне рухи яктан баета, көчле, намуслы, акыллы кеше итә, кешене чын күңелдән яратырга, аның хезмәтен ихтирам итәргә, шул бөек хезмәтнең гүзәл җимешләрен йөрәгең белән тоярга өйрәтә». (М.Горький)

3. «Китап – нинди дә булса текстны эченә алган, битләре билгеле бер тәртиптә бергә җыйналып төпләнгән басма». («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән)

Укучыларга алдан түбәндәге викторина сораулары тәкъдим ителә:

1. Россиядә китап басу эше кайчан һәм кем тарафыннан башлана? (1564 ел. Иван Фёдоров белән Пётр Мстиславец башлап җибәрә. «Апостол» китабы.)

2. Татарча китап беренче тапкыр кайчан басыла? (1722 елның 15 июлендә Әстерханда Пётр I нең күчмә хәрби типографиясендә гарәп шрифты белән татар телендә басылып чыккан Пётр I нең Манифесты. 150 мм зурлыгындагы дүрт битле брошюрага теркәлгән бу Манифестны Пётр I кушуы буенча Дмитрий Кантемир татарчага тәрҗемә иткән.)

3. Дөньяда иң зур китапханә кайда? (Мәскәүдә.)

4. Дөньяда иң кечкенә китапханә кайда? (Һиндстанның Амритсаре шәһәрендә. Бу китапханәдә нибары бер китап саклана. Ул – мәрмәр плитәгә чокып язылган пәһлеван китап.)

5. Нинди әсәрләрнең исемнәре саннардан башлана?

6. Татар телендә кечкенә һәм матур итеп эшләнгән нинди сувенер китапларны беләсез? (Г. Тукай, Г. Камал, М. Җәлил, Х. Туфан һ.б.ларның сувенер китаплары.)

7. Кеше исемнәре белән аталган нинди китапларны беләсез?

(Дәрес башында ике укучы Г.Тукайның «Китап», Х. Шабановның «Анам сүзләре» шигырьләрен укый.)

**Укытучы.**

Укы, бәгърем, син аны,
Китапның син дусты бул!
Бик күп сорауларыңа
Җавап биреп торыр ул.

Әйе, тормышыбызга тирән үтеп кергән китап дигән могҗизага без шулхәтле күнеккәнбез, аңа сулый торган һава, эчә торгән су кебек гадәти нәрсә дип кенә карыйбыз. Бу бөек могҗизаны уйлап табу өчен, кешелек дөньясына мең еллар кирәк булган. Без ияләшкән китапка хәтле нинди китаплар гына булмаган: таш китап, агач китап, сөяк китап, тукыма китап. Мондый китапларны язу өчен күп вакыт, зур көч соралган, аларны куллану да җиңел булмаган, китапны җиңеләйтү өчен кешеләр төрле юллар эзләгәннәр. Шуның нәтиҗәсендә папирус, пергамент, ниһаять, кәгазь уйлап табылган. Дөрес, мондый материалларга язылган китаплар да арзан булмаган.

Уртача гына күләмле китапны күчереп язу өчен дә күп көч, озак вакыт, хәтта айлар, еллар кирәк булган. Европада үлемгә хөкем ителгән кешеләрнең җәзасын еш кына китап күчереп язу белән алмаштырганнар. Әнә шуннан китап язуның нинди авыр хезмәт икәнен чамалап була.

Кешелек тарихы алга барган саен, белемгә, аралашуга ихтыяҗ арткан, китапка да сорау үсеп торган. (Китап турында күренекле кешеләрнең фикерләре укыла. Викторина сорауларына җавап алына, бер укучы татарча китап басылу тарихына тулырак туктала.)

**Укучы** (бу темага язылган проект эше белән таныштыра). Билгеле булганча, язусыз китап булмый. Ә бездә язу бик ерак гасырларга барып тоташа. Борынгы төрки бабаларыбыз моннан мең ярым еллар элек үк рун язуын кулланганнар. Рун язулары белән бергә төрки халыкларга әкренләп гарәп язуы да керә башлаган. Сәбәбе бик яхшы билгеле: бөек гарәп культурасы тугач, бабаларыбыз бу казанышлары белән бергә аларның язуын да кабул иткән. Бу хәл VIII – IX гасырлар тирәсендә булган дип исәпләнелә. Ул чорларда безнең бабайларга уйгур язуы да билгеле булган. Бездә уйгур язуы нык таралмаган, аны гарәп графикасы җиңеп чыккан. Рун графикасы да бөтенләй онытылып бетмәгән. Кыскасы, китап басу өчен иң беренче һәм төп шарт язу бездә V – XI гасырларда ук булган.

Китап басу өчен икенче шарт – халыкның китапка ихтыяҗы булырга тиеш. Мәгълүм булганча, чын мөселман булу өчен укый-яза белү зарури саналган. Шуңа күрә ислам динен кабул итү белән бергә бездә мәктәп-мәдрәсәләр дә барлыкка килгән.Аларда уку-укыту өчен китаплар кирәк булган. Болгар чорында да бездә китап, дөресрәге, кулъязма китап шактый киң тарала, шул чорларда ук китап язу белән шөгыльләнүче, көн күрүче хәттатлар булган. Бу күренеш бездә Казан ханлыгы чорында да, милләтебез руслар кул астында булган елларда да яшәп килгән. Христиан миссионерлары татар кулъязма китабын гына түгел, язулы кабер ташларын да юк итеп торуга карамастан, халыкта язуга, белемгә омтылыш сүрелмәгән. Әнә шундый фактлар бездә китап басу өчен шартларның күптән яшәп килүен, аңа булган ихтыяҗның елдан-ел артып торуы турында сөйли.

**Укытучы.** Киләсе елда татар китабының 300 еллыгын билгеләп үтәчәкбез икән бит. Юкка гына республикабыз мәркәзе – Казан шәһәре 2024 елда Россиянең китапханәләр башкаласы дип игълан ителмәгән икән бит!

**Укучы** (татар китабы тарихы белән таныштыруны дәвам иттерә). Бу елда Пётр I Пруссия походына чыга. Бу походның максаты Һинд океанына чыгу өчен юл ачу, территорияләрне басып алу була. Бу походка тупланган гаскәрләрнең күпчелеге татар солдатларыннан торган. Пётр I, сугыш районнарында яшәүче мөселман халыклары арасында үзенә теләктәшлек табу йөзеннән, Манифест чыгара һәм аны татар телендә бастырып, ул якта яшәгән татарлар, нугайлар, кумыклар арасында тарата. Бу Манифестны татар теленә Пётр I нең яшерен советында тәрҗемәче, соңыннан Россиянең Иранда илчесе булган Тәфкилев дигән татар тәрҗемә итә. Китап җыю серләренә

типографиянең директоры Дмитрий Кантемир өйрәтә. Менә шушы басманы без беренче татар китабының башлангычы дип санйыйбыз.

1799 елда чыккан Указ нигезендә Казанга китап басу өчен шрифтлар, типография машиналары, башка кораллар алып кайтыла. Бу эш белән Петербургта отставкадагы татар прапорщигы Габделгазиз Бурашов шөгыльләнә. Казанда беренче татар типографиясе ачылуы һәм китабы басылуы менә шушы фидакяр затның тырышлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Татар китабы репертуарында шактый күп урынны уку китаплары, төрле фәннәр буенча дәреслекләр алып тора. Татар китабының нихәтле күп басылуы, тиражы буенча гына да без милләтебезнең грамоталылыгының ни дәрәҗәдә торганын күзаллый алабыз. Милли китап аша татар укучысы дөнья әдәбияты, дөнья фәненең төп уңышлары, кешелек тудырган рухи байлык белән шактый таныш булган дип расларга була.

**Укытучы.** Әйе, сүзебез татар китаплары турында. Милли китап – халыкның көзгесе, анда милләтнең меңләгән еллар дәверендә үткән тәҗрибәсе, уңышлары, хыял һәм өметләре, кайгы һәм хәсрәтләре – бөтен тарихы чагылыш тапкан. Ул – халыкның тарихи көзгесе генә түгел, аның рухы, мәдәнияте, күңел көзгесе дә. Татар китабы язмышы да халык язмышына охшаган. Аны да яндырганнар, юк иткәннәр. (Укучылар үзләренең өйләрендә сакланган борынгы китаплар белән таныштыралар. Шуннан соң китапханәләр турындагы сорауларга җаваплар алына.)

Укытучы. Милли басма сүзебезнең өч гасырлык тарихы, бай мирас чыганагы, халкыбыз тарихының көзгесе булуга карамастан, аның моңа хәтле игътибардан читтә калып килүе – гаять аяныч хәл. Язу, әлифбалар алмаштыру аркасында, басма сүзебезнең кадере бетте, аның күп өлеше мәңгегә юкка чыкты. Татар халкының хәтере кыскара бару милли мирасыбызның хәзинәсе булган китапка карашыбызга, аңа булган шундый мөнәсәбәткә дә нык бәйләнгән. Бу юнәлештә беркадәр эш алып барыла үзе. Татарстан Милли китапханәсе каршында,татар тарихында беренче тапкыр буларак, татар басма сүз мирасын барлау, тасвирлау, саклау, аның документаль каталогын төзү буенча тәркем оештырылды. Милли китапханә яңа биналы булды: ул хәзер элеккеге Казан милли-мәдәни үзәге бинасында урнашкан. *(Экранда Милли китапханәнең рәсеме куела, читтән торып экскурсия ясала. Аудиоязмадан түбәндәгеләрне тыңлыйлар.)*

160 елга якын тарихлы китапханә... Бай рухи ризык, бихисап акыл-гыйлем алырлык йорт – Татарстанның Төп китап сарае ул! Нинди милләттән, кайсы илдән, ничә яшьтә, нинди һөнәр иясе булуга карамастан, һәркемгә Милли китапханә дип аталучы бу йортта хезмәт күрсәтәләр. Китапханәгә йөрүчеләрнең максаты – үзләренең нинди дә булса китапка, әдәбиятка булган ихтыяҗын канәгатьләндерү. Тукаебыз үз заманында «Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур», – дип язган булган. Татарстан Милли китапханәсе – дә күп гасырлык рухи хәзинәбез сандыгы ул. Ул иң зур милли китапханәләрнең берсенә әверелә.

Казанның күренекле библиофилы Иван Алексеевич Второвның шәхси

коллекциясенә нигезләнгән кечкенә генә җәмәгать китапханәсе 1865 елда ачыла. 1844 елда Николай Иванович Второв Казаннан Петербургка хезмәткә күчкәндә, әтисе гомер буе туплаган китапханәсен шәһәргә бүләк итеп калдыра. Ул китаплар халыкка хезмәт итә башлаганчы, 20 еллап вакыт кирәк була. Ул заманнарда китапханә, нигездә, русларга хезмәт итә. 1906 елда Әхмәтһади Максуди тырышлыгы белән Казан шәһәре җәмәгать китапханәсенең мөселман филиалы ачыла. Шул көннәрдән башлап, китапханә чын милли китапханәгә әверелә, татар зыялыларына, китап сөючеләренә хезмәт итә.

Биредә тәҗрибәле, оста, белемле, тырыш хезмәткәрләр эшли. Китапханә киштәләрендә барлыгы 3 миллионнан артык китап урын алган, биредәге китапларны бер рәткә тезеп куйсаң, 12 км га сузылыр иде.

Укытучы. Татар китабы тарихын өйрәнүче галимнәребезнең иң күренеклесе – Әбрар ага Кәримуллин. *(Бер укучы кыскача аның бу өлкәдәге эшчәнлеге белән таныштыра.)*

**Укучы.** Академик Ә. Кәримуллинның тормыш юлы бик кызыклы һәм гыйбрәтле, халкыбызның тарихы белән бик охшаш. Ул 1925 елда Татарстанның хәзерге Саба районы Чәбия-Чүрчи авылында туа. Урта белем алганнан соң, төрле эшләрдә эшли: тракторчы ярдәмчесе, бухгалтер, башлангыч мәктәп укытучысы. Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, университетның фәнни китапханәсенә эшкә алалар. Аңа яңа һөнәр – китап тарихын өйрәнергә туры килә, һәм ул бөтен гомерен татар китабы тарихын өйрәнүгә багышлый. Татар китабы тарихы буенча фәнни-тикшеренүләре аерым китаплар булып басылып чыга. Төрки халыкларының китап тарихы буенча аның белән ярышырлык кеше юк. Аның һәр хезмәте таныш фактларга, вакыйгаларга яңача караш белән аерылып тора. Әбрар Кәримуллин – татар китабының әллә кайчан, беленә генә башлаган вакытыннан алып, чын мәгънәсендә милли китап булып оешып җитү дәверенә кадәр күзәтеп чыккан кеше. Фәндә бер күренешне башыннан алып ахырына кадәр тикшереп чыгу бик сирәк кешеләргә насыйп була.

*(Икенче бер укучы – озак еллар Татарстан Милли китапханәсен җитәкләгән күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевнең Татарстан Милли китапханәсен торгызуда, андагы сирәк китапларны, кульязмаларны саклап калуда куйган эшчәнлеге белән таныштыра. Укытучы киң җәмәгатьчелек тәкъдиме белән Татарстан Милли китапханәсенә Разил Вәлиев исемен бирү буенча эш башлануын әйтә.)*

**Укытучы.** Китап – күп кешенең хезмәт җимеше нәтиҗәсе. Ә китапларны ничек укырга соң? (Язмада Ш. Галиевнең «Тамаша» шигыре яңгырый, укучылар белән фикер алышу уздырыла. Бергәләп дәрескә йомгак ясала, өй эше бирелә.)

**Өй эше.** «Китап акылы – кояш яктылыгы» дигән темага сочинение язарга.

**Укытучы.** Китабына хөрмәте булмаган халыкның киләчәге өметле булуына мин ышанмыйм. Китабына хөрмәте булмаган халыкның милли әдәбияты да гомерле була алмый. Китап ул – тел сакчысы һәм халык хәтере дә. Хәтерен югалта баручы халык үз йөзен җуярга бик мөмкин. Милләт буларак хәтеребезне югалтмасак, китаптан аерылмасак иде.

15




Фотода «Мәгариф» журналының 110 еллыгына багышланган конференция, 29 ноябрь 2023 ел

# ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕ ҺӘМ БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ИМТИХАНЫ

**Нурфия ЮСУПОВА,**

филология фәннәре докторы,
Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры,
татар әдәбиятыннан республика фән комиссиясе рәисе

Әдәбияттан белемне бәяләү формалары арасында дәүләт йомгаклау аттестациясе һәм бердәм республика имтиханы укучыларның татар әдәбиятыннан белем дәрәҗәсен, әзерлек сыйфатын стандартлаштырылган биремнәр ярдәмендә бәяләүне күздә тота һәм IX, XI сыйныфларны тәмамлаучы укучыларның татар әдәбиятыннан белем дәрәҗәсен билгеләү мөмкинлеген бирә. Алар ике юнәлеш – туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары һәм рус телендә белем бирү мәктәпләренең татар укучылары өчен тәкъдим ителә.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен һәм бердәм республика имтиханын татар әдәбиятыннан сайлаган укучы өчен 3 документ тәкъдим ителә: спецификация (әлеге эшнең үзенчәлеге), күрсәтмә вариант һәм әдәбият исемлеген үз эченә алган кодификатор. Татар әдәбиятыннан 2024 нче елгы ДЙАнең төзелеше һәм эчтәлеге, нигездә, моңа кадәрге структурага тәңгәл. Аның нигезендә татар әдәбиятыннан КИМнар төзүнең берничә еллык эффектив тәҗрибәсе ята. 2024 елга үзгәрешләр, нигездә, кодификаторга бәйләнгән. Әсәрләр исемлеге баетылып, теоретик төшенчәләр исемлеге кыскартылды.

Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе 2 бүлектән гыйбарәт. Беренче бүлектә мәҗбүри белем бирү эчтәлегендә билгеләнгән әсәрләргә анализ ясау тәкъдим ителә. Ул ике альтернатив варианттан тора, укучы үзе теләгән бер вариантны сайлап алу хокукына ия. Беренче вариантка эпик яки драма әсәреннән өзек тәкъдим ителә, икенче вариант лирик әсәргә кагылышлы биремнәрне яктырта. Икенче вариантта тәкъдим ителгән лирик әсәр тулы текст рәвешендә укучының алдында тора, ә беренче вариантта өзекне укып, укучы әсәрнең сюжетын искә төшерергә тиеш була. Һәр ике вариантта урын алган әсәрләр бары кодификаторга кертелгән әдәби үрнәкләр була, ягъни укучы алдан ук нинди әсәрләр тәкъдим ителергә мөмкин икәнлекне якынча күзаллап килә. Һәр вариантта 3 бирем күрсәтелә, аларның беренче икесе тәкъдим ителгән аспектта әсәргә өлешчә анализ ясауны таләп итә, өченчесе исә ике әсәрне бәяләп, чагыштырма аспектта җавап язуны сорый.

Беренче вариантның беренче бүлегендәге 1.1.1, 1.1.2 биремнәренә җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә, 3–5 җөмлә күләмендә формалаштыру мөһим. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Өченче бирем исә (1.1.3 һәм 1.2.3) чагыштырма планда җавап язуны таләп итә һәм аны 5–8 җөмлә күләмендә формалаштыру сорала.

Икенче вариантта лирик әсәргә бәйле сораулар тәкъдим ителә. Беренче бүлегендәге 1.1.1, 1.1.2 биремнәренә җавап язганда, темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә, 3–5 җөмлә күләмендә формалаштыру мөһим. Әмма бу сан да якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Өченче бирем исә (1.1.3 һәм 1.2.3) чагыштырма планда җавап

язуны таләп итә һәм аны 5–8 җөмлә күләмендә формалаштыру сорала.

Бу бүлекләрдә укучының әдәби әсәрләрнең эчтәлегенә караган төп төшенчәләрне, сыйфатларны (темасын һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны, сюжет һәм сюжет элементларын, образлар системасын, әдәби алымнарны, тел-сурәтләү чараларын һ.б.) дөрес белгели белү дәрәҗәсе тикшерелә. Анализ өчен тәкъдим ителгән текстлар укучының әсәрнең сюжетын белү дәрәҗәсен ачыклауга, әдәби текстка бәя бирү, теге яки бу күренешкә үз мөнәсәбәтен белдерү мөмкинлекләрен билгеләүгә йөз тота.

Өченче бүлек дүрт сочинение темасын үз эченә ала. Алар аерым әсәрләргә мөнәсәбәтле кечкенә күләмле сочинение язуны күздә тота. Җавап бирү барышында шуның БЕРСЕНӘ генә сочинение форматында татар мәктәпләрендә укучыларга 200, рус мәктәбендә укучыларга 150 сүздән дә ким булмаган сочинение язу сорала, 100 сүздән дә ким булган язмалар 0 балл белән бәяләнә. Сочинение өчен әдәбиятның төрле чорларына һәм төрле әдәби төр, жанрларына караган темалар тәкъдим ителә, бу – укучыга үзе кулай дип санаган теманы сайлау мөмкинлеген арттыра. Биредә укучының билгеле бер әдәби әсәр (әсәрләр) турында тупланма фикере, билгеләнгән үзенчәлекне аңлата белү сәләте тикшерелә. Эшнең мондый эзлеклелектә оештырылуы әсәрдән алынган өзекнең тексттагы урынын, әсәрнең сюжет-композицион, тема-проблема-идея үзенчәлекләрен билгеләү, укучының геройларга карата үз фикерен җиткерә алу мөмкинлеген бирә.

Имтихан эшен башкару өчен 210 минут вакыт бирелә. Эшнең беренче бүлегендәге биремнәрне башкару өчен (эпик яки драма әсәре алынган өзеккә анализ ясауга) – 120 минут, икенче бүлекне үтәүгә калган вакытны бирү киңәш ителә.

Сезнең игътибарга рус телендә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен эшләнгән бер вариантны тәкъдим итәбез. Һәр юнәлеш өчен эшләнгән үрнәк вариантлар һәм имтиханга кагылышлы документлар ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына (https://mon.tatarstan.ru/obschee-obrazovanie.htm) һәм белем сыйфатын мониторинглау үзәге сайтына (https://rcmko.ru/gia-9-po-rodnym-yazykam-i-rodnoj-literature-2024/) урнаштырылган.

1 НЧЕ БҮЛЕК

**1 нче бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

1 НЧЕ ВАРИАНТ

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи хәлендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына — Таһирәнең кул сузымы гына җирдә җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры... Аһ, моңнардан да кадерлерәк һәм ләззәтлерәк нәрсә булырга мөмкинме соң?!

...Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып менеп китте. Аның хәтта тәне, һавада йөзгәндәй, җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде.

...Менә кыз әкрен генә башлап, аннан тавышын күтәрә төшеп, сузып кына җырлый:

Сарман буйлары, ай, киң ялан,
Печәннәре җитәр бер заман шул,
Печәннәре җитәр бер заман...

Һәм егетнең күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак җил кибеп яткан покосларның хуш исен китерә кебек, тик егет печән чабучылар ягына нигәдер борылып карый алмый, имеш. Ул да булмый, аның күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә. Хәтта бер мәлгә егет үзе дә ике рәт үлән арасындагы тәгәрмәч эзеннән, җылы туфракка яланаяк баса-баса, китеп бара кебек, ә каршысына киез эшләпә кигән, таяк таянган ак сакаллы бер бабай килә кебек.

Күпмедер вакыт узгач, кызның тагын моңлы җыры ишетелә:

Кояш бата, айлар калка,
Бик ямансу шул чакта...

Һәм егетнең күз алдына үзләренең шәһәрдәге кечкенә өйләре килеп баса. Эңгер-меңгер вакыты, имеш. Өйдә әнисе ялгызы гына икән. Менә ул, ак яулык бәйләгән кечкенә карчык, ут кабызып, бисмилласын әйтә-әйтә, тәрәзә пәрдәләрен төшереп йөри, тәрәзә төбендәге гөлләрнең кипкән яфракларын чүпләп-чүпләп ала, имеш. Өстәлдә яңа гына кайнап чыккан самавыр тора икән. Әнисе аның институттан кайтканын шулай чәй әзерләп көтә, имеш.

– Әнием, әнием! – ди егет, эченнән үксеп, һәм аның йомык күзләреннән сыгылып терекөмештәй кайнар яшь бөртекләре кипкән иреннәренә акрын гына тәгәрәп төшәләр. Шәфкать туташы кулын аның маңгаена куеп, иелеп, нидер сорый шикелле, ләкин егеткә гүя Таһирәсе дәшкән кебек тоела.

Ә.Еники «Кем җырлады?»

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3–5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

1.1.1. Егетнең кичерешләрен җиткерү өчен Ә. Еники нинди алымнардан, образ-детальләрдән файдалана?

1.1.2. Үз геройларының фаҗигасен сурәтләп, язучы нинди фикерләр җиткерә дип уйлыйсыз?

**1.1.3. биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

1.1.3. Ә.Еникинең «Кем җырлады?» хикәясендә һәм Ф.Әмирханның «Хәят» повестенда бер-берсен яраткан төп геройларның күңел халәтен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Хәят Михаилның үзенә нәрсәдер, бик кирәкле бер нәрсә әйтергә теләп тә, әйтеп бетерә алмаганлыгын томанлы гына сизенә, ләкин, никтер, ул кирәкле нәрсәнең әйтеп бетерелми калганлыгын теләгән шикелле була иде. Кулындагы чәчәкләр бәйләмен борыны янынарак китерде дә, шул чәчәкләргә әйткән шикелле итеп, ул:

– Ишетегез әле, сез әүвәлләрдә бик матур җырлыйдыр идегез. Җырлагыз әле берәр нәрсә, – диде.

Михаил чәчәкләргә карап әйтелгән бу сүзнең үзенә әйтелә икәнен белә иде, назланып тормады: уң кулын чалбар кесәсенә тыкты, йомшак кына тамак кырды да зәгыйфь, ләкин сөйкемле тенор белән:

В темной аллее заглохшего сада
Сидя вдвоем на дерновой скамье, –
дип башлады да, үз-үзеннән көлеп җибәреп, җырын кисте һәм:

– Юк, Хаят, мондый тавыш белән җырлаганны тыңлап утырганчы, әнә ул агачта сайрый торган кошчык сайравын тыңлагыз. Ул сезнең өчен һәм сезнең матурлыгыгызны мактап сайрый, – диде.

Чынлап та, ниндидер бер кошчык, башкаларыннан аерым бер осталык вә аерым бер дәрт белән, болар утырган скамья каршысындагы агачның яфраклары арасына яшеренеп сайрана иде. Соңгы сүзләрне әйткәндә, Михаилның тавышы бик чынлыклы вә бераз каушанкырак чыга иде. Хәятның йөрәге тыпырчынган шикелле итеп тибә башлады: Михаилга әйтергә аның теленә җавап килми иде. Бер минутлык тик торыштан соң Михаил, уң кулы белән Хәятның сул кулыннан йомшак кына тотып, уйчан гына тавыш белән:

– Ачуланмагыз, Хаят, мин сезне сөям... Минем күңелемдә сез генә... – ди башлаган иде, Хәятның кулының үз кулыннан ычкынган икәнен сизде.

Хәят болай итеп әйтелгән «сөям» дигән сүзне әүвәл мәртәбә ишетә иде. Ул әле күптән түгел генә укып чыккан русча бер романда сөю, сөелү дигән сүзләрне күргән вә хәтта үзен шул романда язылган кызларның берсе итеп уйлап укыган булса да, һәм мондый эшләрне үзеннән зуррак иптәш марҗа кызларыннан әллә ничә мәртәбәләр ишеткән булса да, хәзер аптыраушта калган: кирәк укыган романындагы кызның вә кирәк үзенең иптәш кызларының үзләрен мондый вакытларда ничек тотканлыкларын хәтереннән чыгарган иде. Михаилның «сөям» дигән сүзен ишеткәч тә, ул ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән:

– Сез бик мәхәббәтле!.. – диде дә, йөзен куллары белән каплап, олы юлга таба йөгерде.

Михаил да аның артыннан китте. Аның колагындагы Хәятның сүзе шатлыклы яңгырый иде:

– Сез бик мәхәбббәтле!

Хәят үзенең кызарганлыгын белә, колакларының ялкынсыз янганлыгын да сизә; һәм хәзер генә булып узган эш аның алдында томан эченнән карап, шатлыклы елмаеп торган шикелле була да, йөздәге кызыллык, колаклардагы яну тагы да көчәя иде.

Яңадан бер минут – Хәят күңелендә куркугарак охшый торган бер китеклек сизде: кинәт бу бик күңелле һәм бераз оялткычрак эшнең бер чите җимерелеп төште. Кай җире житешми? Кай җире китек? Анысын Хәят әле белеп җиткерми иде. Ләкин сизгер яшь йөрәк бу китеклекне тойды.

Ф. Әмирхан «Хәят»

2 НЧЕ ВАРИАНТ

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.
Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.
Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.
Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.
Г.Тукай «Туган авыл»

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3–5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

1.2.1. «Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә, / Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем» юллары белән Г.Тукай нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

1.2.2. Шигырьдә кулланылган нинди тел-сурәтләү чараларын билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

1.2.3. Г.Тукайның «Туган авыл» һәм М.Әгъләмовның «Матурлык минем белән» шигырьләрендә лирик герой нинди фикерләр җиткерә? Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Зур, матур, биек йортлар,
Тәрәзәләрдә – утлар...
Ишектән килеп керәм.
Кая гына барсам да,
Матурлык минем белән.

Алда – күл, янда – болын...
Уйнаклап йөри колын...
Мин дә тәгәрим, көләм.
Чөнки, кайда гына булсам да,
Матурлык минем белән.

Сикереп төшәм суларга,
Шундый рәхәт суларга!
Тауларга күтәреләм.
Кайда гына булсам да,
Матурлык минем белән.

Җирем – иркен, илем – киң,
Горур йөрергә мөмкин,
Имичә башны түбән...
Чөнки, кайда гына булсам да,
Матурлык минем белән!
М.Әгъләмов «Матурлык минем белән»

2 НЧЕ БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

2.1. Г.Ибраһимов иҗатында тематик төрлелек.

2.2. Г.Камалның «Беренче театр» пьесасында Биби образы.

2.3. М.Җәлил иҗатындагы лирик геройга хас сыйфатлар.

2.4. А.Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» повестенда күтәрелгән проблемалар.

Татар әдәбиятыннан 2024 нче елгы бердәм республика имтиханының төзелеше, нигездә, моңа кадәрге структурага тәңгәл. Аның нигезендә татар әдәбиятыннан КИМнар төзүнең берничә еллык, эффектив тәҗрибәсе ята. Биредә дә 2024 нче елга үзгәрешләр, нигездә, әсәрләр исемлегенең үзгәрешенә бәйле.

Татар әдәбиятыннан БРИ биремнәрен төзү барышында берничә принцип, критерий алга куела. Имтихан материалы, структурасы, эчтәлеге әлеге предметның үзенчәлегенә, мәктәптә әдәбиятны укыту тәҗрибәсенә нигезләнә. Икенчедән, сораулык аерым әдәби фактларны гына билгеләүгә кайтып калмыйча, татар әдәбиятыннан алган белемнәрне комплексლы тикшерүгә йөз тота.

Имтихан эшенең эчтәлеге һәм төзелеше укучының әдәбияттан алган белемнәрен; әдәби текстка төр һәм жанр үзенчәлекләреннән чыгып анализ ясый белүен; әдәби әсәрнең темасын, идеясен, автор позициясен, ул күтәргән проблемаларны, әдәби әсәрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен, әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын дөрес билгели алуын; геройга характеристика бирү сәләтен, дәрәҗәсен бәяләргә мөмкинлек бирә. Шул рәвешле гадидән катлаулыга таба анализ ясала: үзәктә күтәрелгән проблемадан һәм әсәрдә автор әйтергә теләгән фикердән аларны сәнгатьчә гәүдәләндерү чараларын ачыклауга; шулардан чыгып, әдәби процесста авторның, әсәрнең урынын билгеләүгә, аның башка әсәрләр белән бәйләнешен күрсәтүгә, әсәрдә күтәрелгән проблемаларның башка әсәрләрдә күтәрелгән проблемалар белән охшашлыгын дәлилләүгә, проблемаларның чишелеше ягыннан аваздаш булуын анализлауга кадәр юл үтелә.

Бердәм республика имтиханы эше укучының белем дәрәҗәсен төрле яклап билгеләүче өч бүлектән гыйбарәт. Беренче һәм икенче бүлектә мәҗбүри белем бирү эчтәлегендә урын алган эпик (драма) һәм лирик әсәрләргә анализ ясау тәкъдим ителә, әдәби әсәрне эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан тулысынча үзләштерү күздә тотыла. Анализ өчен алынган текстлар әдәбиятның төрле чорларын колачлый: XIX йөз әдәбияты – XX йөз башы – XX йөз (1917 нче елдан соң) әдәбияты – хәзерге әдәбият. Имтихан эшенә тәкъдим ителгән вариантларның беренче һәм икенче бүлекләрендәге әдәби текстлар, эшнең туплануына карап, әдәби процессның төрле этапларын чагылдыра.

***Дәвамы 76–82 нче битләрдә***

16




# ЛЕВ ТОЛСТОЙ БЕЛӘН АРАЛАШКАН ТӘТЕШ МӨГАЛЛИМЕ

**Эльмира СӘЛАХОВА,**

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты

XX йөз башында җәмгыятьтә фикер төрлелеге барлыкка килә башлый, хөрлеккә омтылыш, үзгәреш теләү алгы планга чыга. Бу хәлләр уку йортларында бигрәк тә ачык чагылыш таба, чөнки яшь кешеләр дөньяга киңрәк карый, алар заман үзгәрешләре белән бергә барырга тели, шуңа да элекке укыту тәртипләре белән килешми башлыйлар. Элек катгый итеп кабул ителергә тиешле дини тәгълиматларны да анализлый, фикерли башлыйлар. Татар мәдрәсәләренең барысында да диярлек үтеп кергән шәкертләр хәрәкәте – шуның нәтиҗәсе. Аннан революцион фикерләрнең тәэсире дә көчәя. Мөгаллимнәр, шәкертләр арасында да жандарм күзәтүенә эләккән яшьләр арта башлый.

Казаннан шактый читтә булса да, бу хәлләр Тәтешкә дә бик тиз килеп җитә. Тәтеш шәһәренең ир балалар мәктәбендә эшләгән булачак тарихчы Гайнетдин Әхмәрев 1903 елда Тәтештән күчеп киткәч, мәктәпкә җитәкчелеккә шунда укыткан Исхак Казаков билгеләнә, аның улының хатирәләре буенча, ул эшли башлау белән үк укыту системасын үзгәртә башлый, дини предметларны, догалар ятлауны кыскартып, алар урынына телләр өйрәнү, табигать белеме, география, химия, физика, кул эшләре буенча дәресләр кертә. Исхак Мостафа улы Казаков Тәтеш мәктәбендә 1900– 1911, 1917–1918 еллар аралыгында эшли. Ул эшләгән елларда Тәтеш мәктәбенә революцион фикерләр керә башлый, ул – күренекле татар революционеры Мулланур Вахитовның абыйсы, бу да – гаиләдә инкыйлаби фикерләрнең шактый нык булуына мисал. Шушы ук нәсел кешесе – Рабига Казакова Акъегет авылы мәдрәсәсенә 1910 елда рус теле укытучысы булып килә, әмма аның инкыйлаби карашлы булуы властьларны канәгатьләндерми, аны укытучылыктан алалар.

Тәтеш мәктәбендә шушы елларда башланган үзгәрешләрдә монда белем алган укучылар да катнаша. И. Казаковны, хөкүмәткә каршы алып барган пропаганда, укучылар белән бергәләп сәяси характердагы җырлар җырлаганы өчен 1911 елның июнендә кулга алып, төрмәгә утырталар, аннан ул гаиләсе белән Сембер губернасына сөрелә, алга таба укытучылык итү хокукыннан мәхрүм ителеп, Оренбург тарафына җибәрелә. Казаков шәһәрнең сул карашлы татар яшьләре арасында бик популяр, хөрмәтле кеше булган.

И. Казаков кулга алынганнан соң, аның урынына Тәтешнең ике сыйныфлы рус-татар мәктәбе белән идарәгә килгән Шәмсетәбриз Салиховка карата 1913 елда укучылар белән «Россиянең сәяси дәүләт төзелешенең үзгәреше» турында сүз алып барганы өчен яла ягыла. Мәктәпнең югары сыйныфында 1912 елның декабрендә уздырган дәресенә сылтама ясап аның өстеннән шикаять итәләр. Бу хәлләрне тикшерүдә шул мәктәптә белем алучы Иске

Карамалы авылының (Кама Тамагы) 18 яшьлек Ярулла Исмаев, Чиргү-Бураш авылының (Апас районы) 19 яшьлек Мөхәммәдша Заһидуллин, Самара губернасы Бөгелмә өязе Сарабиккол авылының (хәзерге Лениногорск районы) 19 яшьлек Фәтхелбари Ногманов, Олы Тормы (Тәтеш районы) авылының 18 яшьлек Садретдин Алтынбаев, Гыйльфан Гыймранов, Югары Урысбага авылының 16 яшьлек Шәһиәхмәтев һәм шул мәктәпнең дин гыйлеме буенча белем бирүче Камалетдин Мостафиннан сорау алулар була. Салихов эше буенча укучылар каршылыклы җаваплар бирсәләр, Камалетдин Мостафин, берни җавап бирмичә, бары елмаеп кына тора. Тәтеш мәктәбе җитәкчесе Салиховның өендә, ул бу вакытта Казаков өендә яши торган була, тентү уздыралар, әмма шикләнерлек берни табылмый. Тикшерү нәтиҗәсе буларак, зыялы мөгаллимгә нахак яла ягылган дигән нәтиҗә ясала.

Шәмсетәбриз Салихов чыгышы белән Малмыж шәһәре мещаннарыннан, ул заманы өчен шактый алдынгы карашлы, кызыксынучан кеше була.

Тентү вакытында аның өендә атаклы рус язучысы Л. Н.Толстой тарафыннан тупланган «Мысли мудрых людей на каждый день» дип аталган китап һәм аның Лев Толстой белән язышкан хатлары табыла. Л. Н.Толстой, 1903 елның гыйнвар аенда авырып китеп, гадәти эшләре белән шөгыльләнә алмый башлый. Шул вакытта акыл ияләренең төрле хикмәтле сүзләре язылган бүлмә календаре аны шундый типтагы хезмәт язарга этәрә. Ул, бөек шәхесләрнең тормышы турындагы уйлануларын, фәлсәфәләрен туплап, кызыклы хезмәт тәкъдим итә. Бу китабына аның төрле чор кешеләре, бөекләре: Эпиктет, Диоген, Марк Аврелий, Сократ, Конфуций, Будда, Аристотель, Паскаль, Руссо, Спиноза, Кант, Шиллер, Шопенгауэр, Вольтер, Теккерей, Достоевский фикерләре тупланган. Гап-гади татар егете, мөгаллим Шәмсетәбриз Салихов дөньякүләм атаклы акыл ияләренең фикерләре, аларның дөньяга карашлары белән Л.Н.Толстой хезмәте аша таныша, хезмәтне укып кына калмыйча, үз фикерләрен, күңелендә калган сорауларны бөек рус язучысына хатлары аша юнәлтә.

1910 елның августында Шәмсетәбриз Салихов, Ходай турында үзен кызыксындырган сорауларын биреп, Лев Толстойга хат белән мөрәҗәгать итә. Озак та көттермичә, 1910 елның 22 августында ук язучы җавап та бирә, хат машинкада басылган, хатка Лев Николаевич үз имзасын куйган. Ходай, аңа ышану турында фикерләгән хатында Л.Н.Толстой: «Верить надо, и нельзя не верить, потому что одно и тоже во всех верах, есть признание высшего совершенства – Бога, к которому надо приближаться, и любовь ко всем людям – братьям», – дип яза. Татар мөгаллименең фәлсәфи фикерләве, югары көч, хаклык эчтәлеген аңларга тырышу, дөньядагы халыкларның дини аермалыкларына карамастан, бердәм дуслы, мәхәббәттә яшәү һәм башка шундый төшенчәләр турында төпле фикерләре аеруча кызыклы. Шәмсетәбриз Салихов: «На мой рассудок непоколебимо шепчет мне, что Он есть,

Он – добро и я Ему верю, хочу верить и верить». Мөгаллимнең икенче хатына да Л.Н.Толстой шунда ук җавап яза. Рус язучысы хатында: «…письмо Ваше от 5 сентября я получил и прочёл с удовольствием, Ваши суждения о Боге и жизни человеческой, прочёл с удовольствием, чем согласен с Вами», – дип, үз фикерләрен белдереп. «А это одно и тоже во всех верах есть то, что все люди равны, все братья, п.ч. во всех один и тот же Дух Божий и что поэтому нужно со всяким человеком обращаться с любовью и уважением и что этого самого и хочет Дух Божий, живущий в нас. Если будешь верить в это, т.е. стараться жить в любви со всеми людьми, не разбирая того, все ли или много ли людей живут так, и жить самому по этому закону, зная, что в такой жизни найдёшь самое большое благо», – ди.

Алар арасында барган язышу, хатлар эчтәлеге җылылык, бер-берсенә хөрмәт белән сугарылган. Бөек язучы гап-гади мөгаллимгә зур хөрмәт, сабырлык белән хатлар яза, берүк дәрәҗәдә торып фикерләшә, аның җавабы белән килешүен, аны кабул итүен дә күрсәтә. Салихов үз хатларында Лев Николаевичка: «Многоуважаемый Лев Николаевич», – дип дәшсә, язучы үз хатларын: «Любезный брат Табриз Салехов», – дип башлый. Хатына: «Брат Ваш Л.Толстой», – дип имза куя. Тәтеш мөгаллиме Л.Н.Толстойга язган хатларын: «Уважающий брат Ваш юноша татарин, мусульманин Табриз Салехов», – дип тәмамлый.

Л.Н.Толстой Салиховка 22 августта ук язган хатында мөгаллимгә китаплар җибәргәнен хәбәр итә: «Посылаю Вам несколько книг, из которых Вы яснее поймёте эту единую веру», әмма бу китаплар ни сәбәпледер адресатка килеп җитми, Салихов икенче хатында «…письмо Ваше от 22 августа сего года я получил, за что искренне благодарю Вас, но упомянутые Вами книжки до сих пор не получил, и не знаю какая тому причина». Л.Н.Толстой, аңа бу китаплардан кала, алдагы – 1910 елның 18 сентябрендә язган хатында да тагын китаплар җибәрәчәге турында яза: «Удивляюсь, что книги мои не дошли до Вас, когда вернусь домой, я живу теперь не дома, и вернусь 22-го, узнаю почему. Теперь же посылаю Вам отсюда несколько книг». Бу җибәрелгән китапларның барысы да мөгаллим Шәмсетәбриз Салиховка килеп ирешкәнме – бу хакта төгәл генә әйтәсе авыр, әмма тентү вакытында аның өендә «Мысли мудрых людей на каждый день» табылган икән, бу Л.Н.Толстой аңа күндергән китапларның берсе булуы бик ихтимал.

Бөек рус язучысы, фәлсәфәчесе Л.Н.Толстой белән аралаша алырлык, аның белән әңгәмә тотарлык татар яшьләренең булуы, аларның белем дәрәҗәсе, фикерләү югарылыгы XX йөз башы татар җәмгыятенең күрсәткече була ала. Бу яшь мөгаллимнең Казаннан шактый читтә булган Тәтеш төбәгендә булуы, андагы фикер үсешенә йогынты ясавы, аның шундагы яшьләрне тәрбияләве – Тәтешнең инде гадәти генә авыл тормышы белән яшәүче төбәк түгеллеген, ә иҗтимагый фикер формалашкан, камилләшкән төбәк, татар җәмгыятенең мөһим бер үзәге



15

# ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕ ҺӘМ БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ИМТИХАНЫ

**Нурфия ЮСУПОВА,**

филология фәннәре докторы,
Казан (Идел буе) федераль
университеты профессоры,
татар әдәбиятыннан республика фән
комиссиясе рәисе

Эпик (яки драма) әсәрдән алынган өзеккә анализ ясау каралган 1 нче бүлектә кыска җавапны таләп иткән 7 (1–7) һәм чикләнгән күләмдәге җавап соралган 2 (8–9) бирем тәкъдим ителә. Кыска җавап соралган биремне үтәү барышында сорауга бер сүз яки сүзтезмә белән җавап бирү күздә тотыла. 4 биремдә укучыга тәңгәллеккә китерү юнәлешендә бирем тәкъдим ителә.

Коры фактларны, күренешләрнең атамаларын яисә теоретик төшенчәләрне билгеләү белән генә чикләнмичә, предметның үзенчәлеген күздә тотып, беренче һәм икенче бүлекләрдәге киңәйтелгән җавап соралган биремнәр әдәби контекстка юнәлтелә: анализ өчен алынган өзектә күтәрелгән тема-проблемалар ачыклана, аларның уку дәверендә өйрәнелгән башка әсәрләр белән авазпдашлыгы, охшашлыгы билгеләнә, әдәбият дәресләрендә өйрәнелгәннәр башка фәннәрдән алган белемнәр белән дә бәйләнештә карала. Шул рәвешле укучыга үз фикерен җиткерү мөмкинлеге тудырыла. Мондый биремнәргә җавапта чикләнгән күләмдәге, 5–10 җөмлә ярдәмендә бәйләнешле фикер тупланган текст язу сорала.

2 нче бүлектә укучыга лирик әсәргә анализ ясау өчен 7 бирем тәкъдим ителә. Аларның бишесенә (10–14) – кыска, икесенә (15–16) чикләнгән күләмдәге (5–10 җөмлә) җавап язу күздә тотыла. 13 биремдә тәкъдим ителгән 4 яки 5 алымнан әсәрдә кулланылган өчесен сайлап алу таләп ителә. 1 нче һәм 2 нче бүлектә бирелгән 12 (1–7; 10–14) бирем мәктәп программасы материалыннан алына, 4 бирем (8–9; 15–16) өлешчә катлауландырылган бирем дип санала.

Татар әдәбиятыннан имтиханны БРИ форматында оештыру барышында укучының язу, анализлау, үз фикерен җиткерә алу, әдәби тоемлау сәләтен тикшерү, ачыклау максаты да күз уңында тотыла. Шуңа мөнәсәбәттә имтихан эшенең соңгы (өченче) бүлегендә билгеләнгән әдәби темага сочинение язу сорала, укучының билгеле бер әдәби әсәр (әсәрләр) турында тупланма фикере, билгеләнгән үзенчәлекне аңлата белү дәрәҗәсе тикшерелә. Бу бирем (17.1, 17.2, 17.3) дәрәҗәсе ягыннан катлаулы бирем дип санала. Укучыларга билгеләнгән әсәрдәге яки әдипләр иҗатындагы аерым үзенчәлекләрне (образлар бирелешен, тема-проблемаларны, алымнарны) ачыклауга йөз тоткан 3 тема тәкъдим ителә. Имтихан эшендә бу сорауларның берсенә генә сочинение формасында киңәйтелгән җавап язу сорала. Сораулар әдәби-тарихи процесстагы төрле чорларны үз эченә ала. Проблемалы сораулар укучының тормышны танып белү, логик һәм иҗади фикерләү, фикерен дәлилли алу дәрәҗәсен ачарлык итеп куела. Мондый төр эшләрне башкару укучыдан танып белүдә мөстәкыйльлек таләп итә, сәнгатьнең бер төре һәм укыту фәне буларак, матур әдәбиятның үзенчәлеген ачарга ярдәм итә. Сочинение язу барышында җавапның төгәллеге, тирәнлеге, мөстәкыйльлеге; әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлау, алар белән эшләү дәрәҗәсе; җавапның, әдәби текстларны кулланып, нигезле, дәлилләнгән булуы; җавапның эзлеклелеге, фикерне җиткерү мөмкинлеге; җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе төп критерийлар итеп билгеләнә.

Татар әдәбиятыннан БРИ үткәрү татар әдәбиятын укытуда, балаларның әдәби әсәр белән эшләү барышында проблемаларның да

булуын дәлилләде. Бер яктан ул татар әдәбиятыннан БРИ бирергә теләүче укучылар санына бәйле. Билгеле, аларның аз санда булуы иң беренче чиратта әлеге имтихан нәтиҗәләренең югары уку йортларына керү барышында исәпкә алынмавына бәйле. Моңа кадәр имтихан биргән укучылар һәм аларның укытучылары – татар әдәбиятын ихластан яратучылар яки үзләренең мөмкинлекләрен сынап караучылар. Шуңа мөнәсәбәттә ассызыклап китү урынлы булыр: татар әдәбиятыннан имтихан тапшырган укучыларның белем дәрәҗәсе шактый югары.

Укучылар күбрәк кыска җавап таләп иткән биремнәргә җавап язу барышында кыенлык кичерә, түбәнрәк баллар да, нигездә, шушы биремнәргә туры килә. Әдәбият дәресләрендә укучылар әсәрнең эчтәлеген яки әдипнең биографиясен сөйләргә, әдәби әсәрләрне анализларга күнегә, ә бер сүз белән җавап таләп ителгән сораулар аларда кыенлык тудыра. Укучылар авторларның иҗатларын, теге яки бу әсәрне гомуми планда яхшы белсә дә, төгәллек җитми, теге яки бу әдәби күренешнең теоретик атамасын төгәл билгели алмый, димәк, имтиханга әзерләнгәндә, теоретик төшенчәләргә аерым игътибар бирү сорала. Чөнки мондый биремнәргә бик төгәл җавапны таләп иткән сораулар гына куелырга тиеш, ике төрле уйларга урын калдырыла алмый (җаваплар алдан компьютерга кертеп куела һәм автомат тикшерелә). «Бу герой нинди, аны билгеләүче төп сыйфат, нинди тема, проблема» кебек сораулар бу биремнәргә куела алмый, аларга укучылар төрлечә җавап бирергә мөмкин. Мәсәлән, «бу геройны билгеләүче төп сыйфат» дигән сорауга укучылар «яхшы, әхлаклы, белемле» һ.б. төрле җаваплар бирә ала, бер караганда алар барысы да дөрес булып чыгарга мөмкин, ә компьютерга шул җавапларның берсе генә кертелә һәм компьютер техник яктан шунысын гына дөрес дип саный. Укучылар киңәйтелгән җавап язу бырышында үз фикерен җиткерә, теоретик әзерлек дәрәҗәсен күрсәтә ала, ә төгәл бер сүз яки сүзтезмә белән җавап язуда кыенлык кичерә. Шуңа да татар әдәбиятыннан бу төр имтиханны сайлап алган укучылар белән мондый күнекмәләрне камилләштерү сорала.

Киңәйтелгән җавап соралган 8–9, 15–16 биремнәренә җаваплар безне куандыра, укучылар, кагыйдә буларак, аларда таләп ителгән яки соралган җавапны төгәл, тулы, матур итеп җиткерә ала.

Бердәм республика имтиханында 3 бүлек биремнәре әһәмиятле санала. Биредә татар мәктәбен тәмамалаучылар 200 дән, рус мәктәпләрен тәмамлаучылар 150 сүздән дә ким булмаган инша язарга тиеш. Укучыларда сочинение язу күнекмәсе бар, төрле дәрәҗәдә булса да, алар шәхси фикерләрен җиткерә ала. Шулай да укучыларда әсәргә таянып эшләнгән сочинение, инша язу күнекмәсен камилләштерү мөһим. Укучылар еш кына зур күләмле инша язу белән мавыга яки үз язмасындагы сүзләрне санап, нәтиҗә чыгарып куя. Моннан тыш, иншаларда кабатлаулар да очрый, бу исә логик эзлеклелекне бәяләү барышында баллның кимүенә йогынты ясый.

Моннан тыш, әдәби әсәрне – текстны яхшы белү таләп ителә, ләкин, тәҗрибә күрсәткәнчә, имтиханны тапшырган укучылар бу яктан авырлык кичерми, алар текстларны яхшы белә, чөнки

укучыларга алдан расланган әдәбият исемлеге тәкъдим ителә һәм имтихан эшенә бары шушы әсәрләргә нигезләнгән сораулар һәм биремнәр генә кертелә. Шигырь текстлары исә тулысы белән укучының алдында тора, чөнки алар кыскартуларсыз имтихан эшендә урын ала.

Сезнең игътибарга туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен эшләнгән бер вариантны тәкъдим итәбез. Һәр юнәлеш өчен эшләнгән үрнәк вариантлар һәм имтиханга кагылышлы документлар ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына (https://mon.tatarstan.ru/obschee-obrazovanie.htm) һәм белем сыйфатын мониторинглау үзәге сайтына (https://rcmko.ru/gia-9-po-rodnym-yazykam-i-rodnoj-literature-2024/) урнаштырылган.

1 НЧЕ БҮЛЕК

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез.**

Авыр тойгылар белән мин бу йортның капкасына барып сугылдым. Әүвәл заманнарда көне буе ачык була, аның аркылы өзлексез йөрелеп торыла торган бу картайган капка хәзер эчке яктан бикләп куелган иде.

Иске, тузанлы, бераз бүртенгән бер сүс арканны тарттым да ишегалды эчендә шалтыраган кыңгырауның яңгырашын тыңлап тордым: ул әллә ничек тупас һәм моңлы шалтырый да искергән һәм кытыршыланган тавыш чыгара иде. Таш койма һәм таш капкалар аркылы сизелеп тора торган серле тынлыкка баткан ишегалды бу яңгыраштан ыңгырашып куйды. Берничә минуттан соң инде аның эчендә нindидер бер хатынның картлык йөткереше белән йөткерә-йөткерә чыгып килгәнлеге сизелде. Тагы бераздан соң минем алдымдагы авыр капка ыңгырашып кына, теләми генә ачылган төсле ачылды. Аның эченнән күренгән озын буйлы, бер күзенә ак төшкән куркыныч кыяфәтле карчык, кем икәнлегемне бик җентекләп сорашканнан соң гына, мине ишегалдына кертте.

Биек таш койма белән чолганган киң һәм озын бу ишегалды, таш белән түшәлгәнлегенә карамыйча, ямь-яшел үләнлеккә әйләнгән, әүвәл заманнарда гөрләп, шаулап торган бу ишегалды хәзер әллә нинди серле тынлык, җанны авырайта торган тынлыкка батып калган иде. Ишекләре кәкрәйгән сарайлар, урыны-урыны белән түбә калайлары купкан амбарлар, ташланган кое, түрдә күренеп торган, искергән һәм бераз артка таба ауган рәшәткәле бакча коймасы бу хәятсыз ишегалдына әллә нинди, җанга авыр булып торган шыксызлык һәм ташландыклык төсе биреп тора иде.

Мин ишегалдына кереп җиткәч, өрәк төсле озын буйлы, берсе ак, берсе кара күзле карчык, йөткеренә-йөткеренә, капканы тагы бикләп куйды да, сүз дәшмичә генә, яңадан бер кат мине баштанаяк карап чыкты. Таш койма, бикле авыр таш капка бу карчык белән мине бөтен хәятлы дөньядан, бөтен адәм кыяфәтле кешеләрдән аерып торалар иде. Бу кыяфәтсез карчык белән бу хәрабә ишегалдында ялгыз калганлыгымны күргәч, мин, куркына башлаган шикелле, җәһәт-җәһәт өй ишегенә таба атладым. Кайчандыр бөтенлектән, чисталыктан ялтырап тора торган

бу ишек хәзер каралган, сүнгән, пычранган, кырылып беткән килеш, алдындагы сүсәреп яшелләнгән һәм кыегайган баскычларына карап җылаган шикелле итеп тора иде.

Мин баскычларның берсенә аягымны куям дигәндә, артымнан килә торган карчык, йөткеренә-йөткеренә:

– Чү, анда ярамый! – дип кычкырып җибәрде. Аннан соң игътибарсыз гына, карамый гына мине узып китте дә үзенең җеннәренә сөйләп барган сымак кыяфәт һәм әллә нинди төссез тавыш белән: – Күптән өйнең ул ягында кеше тормый. Анда бичура ияләнгән, – диде.

Ф.Әмирхан «Бер хәрабәдә»

**Бер сүз яки сүзтезмә белән җавап таләп иткән биремнәргә җавабыгызны регистрация һәм җаваплар бланкының беренче битенә урнаштырыгыз. Биремнәргә җавабыгызны шушы бирем номерының уң ягына беренче шакмактан башлап сүз яки сүзтезмә рәвешендә языгыз. Һәр хәрефне аерым шакмакка ачык итеп языгыз. Сүзләр янына бернинди дә тыныш билгеләре куелмый һәм буш шакмаклар калдырылмый.**

1 Сайланган әсәрнең кайсы әдәби төргә каравын ачыклагыз һәм җавапта языгыз.

Җавап: .

2 Әлеге әсәрнең кайсы әдәби жанрга каравын билгеләгез һәм җаваплар бланкына языгыз.

Җавап: .

3 Өзекнең беренче абзацында урын алган, Сөләйман абзый йортын тышкы дөнья белән аерып торган, шартлы мәгънәгә ия булган образны табыгыз һәм җаваплар бланкына язып куегыз.

Җавап: .

4 Тәкъдим ителгән образларны һәм әсәр сюжетындагы аларга хас сыйфатларны тәңгәлләштерегез. Икенче баганадан беренче баганадагы образга туры килгән детальне сайлап алыгыз.

Образлар:

А) Ишегалды;

Б) Карчык;

В) Кыңгырау.

Детальләр:

1. Озын буйлы, бер күзенә ак төшкән куркыныч кыяфәтле;

2. Әллә ничек тупас һәм моңлы шалтырый да искергән һәм кытыршыланган тавыш чыгара;

3. Серле тынлыкка баткан.

Җавапта үзегез дөрес дип уйлаган җавап санын таблицадагы хәрефләргә туры китереп куегыз:

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |

5 Карчык образы кайсы образ (герой) төренә карый?

Җавап: .

6 Карчыкның өзектә тышкы кыяфәте җентекләп сурәтләнә. Аның әдәбият белемендәге атамасын языгыз.

Җавап: .

7 «Кайчандыр бөтенлектән, чисталыктан ялтырап тора торган бу ишек хәзер каралган, сүнгән, пычранган, кырылып беткән килеш, алдындагы сүсәреп яшелләнгән һәм кыегайган баскычларына карап җылаган шикелле итеп тора иде» юлларында кулланылган лексик чараның төрен билгеләгез һәм җаваплар бланкына языгыз.

Җавап: .

**Киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәрне үтәү өчен җаваплар бланкының икенче битен кулланыгыз. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, 5–10 җөмлә күләмендә эзлекле җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Биремгә җавап бирү барышында чагыштыру өчен китерелгән мисаллар ике әсәрдән дә ким булмаска тиеш. Бер үк авторның ике әсәрен мисалга китерергә дә мөмкин.**

8 «Бер хәрабәдә» әсәрендә Ф.Әмирхан ни өчен йортның элеккеге һәм хәзерге сурәтен капма-каршы куеп сурәтли дип уйлыйсыз?

9 Әлеге әсәрендә автор нинди проблемалар күтәрә, бу яктан ул кайсы әсәрләр белән аваздаш? Җавабыгызны мисаллар белән дәлилләп языгыз.

2 НЧЕ БҮЛЕК

**Түбәндә тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез.**

Күңелгә минем, туган як,
Бигрәк тә якын шул син.
Кырларың өстеннән искән
Җилләргә хәтле сусыйм.

Тезләнәм чишмәләреңә,
Бетми тик сусау гына.
Мин бәхетле бары тик син
Бәхетле булсаң гына.

Ник болай сагышлы иттең,
Бу кадәр мине соң син?!
Аерылып бер көн дә узмый,
Яңадан сиңа сусыйм.

Ник болай гомерем буена
Бетмәгән сусау икән?
Сусаудан янган күңелгә
Су салып торсаң икән.

С.Хәким «Сусау»

**Бер сүз яки сүзтезмә таләп иткән биремнәргә җавабыгызны регистрация һәм җаваплар бланкының беренче битенә урнаштырыгыз. Биремнәргә җавабыгызны шушы бирем номерының уң ягына, беренче шакмактан башлап, сүз яки сүзтезмә рәвешендә языгыз. Һәр хәрефне аерым шакмакка ачык итеп языгыз, сүзләр янына бернинди дә тыныш билгеләре куймагыз.**

10 Әлеге шигырьнең кайсы әдәби төргә каравын билгеләгез.
Җавап: .

11 Шигырьнең беренче строфасында сусауның дәрәҗәсен, көчен, асылын җиткерергә ярдәм иткән образны языгыз.
Җавап: .

12 Әлеге шигырьнең жанрын билгеләп языгыз.
Җавап: .

13 Тәкъдим ителгән исемлектән шигырьнең соңгы строфасында кулланылган өч сурәтләү чарасын һәм алымын сайлап алыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсү тәртибендә языгыз.
Сынландыру;
Эпитет;
Антитеза;
4. Риторик сорау.
Җавап: .

14 «Ник болай сагышлы иттең, Бу кадәр мине соң син?!» юлларында кулланылган, җөмләдә сүзләр тәртибенә нигезләнгән

стилистик чараның төрен билгеләгез һәм җаваплар бланкына языгыз.

Җавап: .

**Киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәрне үтәү өчен җаваплар бланкының икенче битеннән файдаланыгыз. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, 5-10 җөмлә күләмендә җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Биремгә җавап бирү барышында чагыштыру өчен китерелгән мисаллар ике әсәрдән дә ким булмаска тиеш. Бер үк авторның ике әсәрен мисалга китерергә дә мөмкин.**

15 Шигырьгә таянып, «Мин бәхетле бары тик син / Бәхетле булсаң гына» юлларына салынган мәгънәне аңлатып языгыз.

16 Шигырьдә лирик геройга хас сыйфатларны ачыклагыз. Мондый тип лирик герой тагын кайсы авторларның шигырьләрендә урын ала? Җавабыгызны дәлилләгез.

3 НЧЕ БҮЛЕК

**3 нче бүлек биремнәрен үтәү өчен җаваплар бланкының икенче битеннән файдаланыгыз. Җавап бирү барышында тәкъдим ителгән биремнәрнең бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Үзегез сайлаган биремгә, әдәби материалга таянып, киңәйтелгән җавап языгыз.**

17.1 К.Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»нда мәгърифәтчелек идеяләре. Фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.

**Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш, 150 сүздән дә ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә. Җаваплар бланкында сайлап алган биремегезнең номерын күрсәтегез.**

17.2 М.Фәйзинең «Галиябану» драмасында күтәрелгән проблемалар. Фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.

17.3 М.Әгъләмов иҗатында урын алган лирик герой үзенчәлеге. Фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.

Бер сүз яки сүзтезмә белән җавап таләп иткән биремнәргә җаваплар

| **Биремнең саны** | **Җавабы** |
|---|---|
| 1 | Эпик төр / Проза |
| 2 | Хикәя |
| 3 | Капка |
| 4 | 312 |
| 5 | Ярдәмче |
| 6 | Портрет |
| 7 | Антоним |
| 10 | Лирик төр < Поэзия |
| 11 | Җил / җилләр |
| 12 | Күңел лирикасы |
| 13 | 124 |
| 14 | Инверсия |

***Ахыры. Башы – 65–71 нче битләрдә***

17



# ГАЛИМӘ ФӘҺИМӘ ХИСАМОВА

**Гөлназ ГАЙНУЛЛИНА,**

филология фәннәре кандидаты, доцент

**Әлфия ЙОСЫПОВА,**

КФУның гомуми тел белеме кафедрасы профессоры, Каюм Насыйри институты директоры, филология фәннәре докторы

Ә. Еники үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза: «Мин – борынгы зыялыларны күреп калган кеше. Аларның бөтен нәрсәләрендә – үз-үзләрен тотуларында булсын, сөйләшүләрендә булсын, ниндидер бер мәдәнилек сизелеп тора иде. Бик чиста, пөхтә киенәләр. Зыялы кешенең тышкы кыяфәте генә түгел, күңеле дә матур булырга тиеш бит әле». Зыялылыклары белән аерылып торган, үзләренә күпләрне җәлеп иткән шәхесләр бүгенге көндә дә юк түгел. Сүзебез татар теле белеме фәнендә тирән эз калдырган сирәк зыялыларның берсе, исеме җисеменә туры килгән Фәһимә Миргали кызы Хисамова хакында.

Профессор Ф.Хисамова аспирантураны татар филологиясендә беренче фән докторы, Казан университетында беренче хатын-кыз деканы, татар хатын-кызларыннан беренче булып академик дәрәҗәсенә ирешкән күренекле тюрколог Диләрә Гариф кызы Тумашева җитәкчелегендә уза.

Фәһимә Миргалиевна Хисамова – беренче чиратта, татар теле белеме фәнендә үз урынын тапкан күренекле галим. Ул 1971 елда «Хәзерге татар әдәби телендә сыйфат фигыльләр» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Әлеге тикшеренү нәтиҗәләре татар һәм рус телләрендә дөнья күргән «Татар грамматикасы» дип аталган академик басмаларда аерым бүлек буларак урын ала. 1995 елда Ф. Хисамова «Иске татар рәсми эш кәгазьләре стиленең формалашуы һәм кулланылыш үзенчәлекләре (XVI йөз – XIX йөзнең беренче яртысы)» дигән темага язылган докторлык диссертациясен яклый. Хезмәте фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә.

Тел тарихы – тел гыйлемендә катлаулы, җаваплы, тикшеренүчедән һәр өлкәдә мәгълүматлы һәм тирән белемле булуны таләп итә торган юнәлешләрнең берсе. Әлеге тармакта фәнни эзләнүләр алып бару иң элек архив материаллары, язма истәлекләр, төрле графикада язылган чыганаклар белән эш итүне күз алдында тота. Бу нисбәттән, Ф.Хисамованың «Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.)» дип аталган монографиясе игътибарга лаек. Күпсанлы архивларда гарәп графикасындагы ярлык, кулъязма, хатларны табып, укып, аларның күчермәләрен алып, тикшеренүләр үткәрү нәтиҗәсендә Фәһимә ханым беренчеләрдән булып татар теле рус дәүләтендә дипломатия теле буларак ике-өч гасыр кулланылышта була дигән нәтиҗәгә килә [1; 399], Урта Идел һәм Урал төбәкләрендә төрле милләттәге халыклар өчен татар теле аралашу теле булуын, Россия дәүләтенең Кавказ һәм Якын Көнчыгыш, Урта Азия, Көнчыгыш Азия илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләрнең татар телендә алып барылуын халыкка җиткерә. Монографиянең нәзари әһәмиятен билгеләп, Э.Грунина болай ди: «Хезмәтнең әһәмияте татар әдәби теле тарихы мәсьәләләре белән генә чикләнми. Әлеге проблеманың бай язма традициягә ия булган башка төрки телләр материалында өйрәнү җәһәтеннән дә актуаль» [2; 181].

2011 елда журналистларга биргән бер интервьюсында Фәһимә Хисамова: «Безнең бурыч – телебез бик борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр нинди үзгәрешләр кичергәнлеген барлап, тарихи грамматиканы эшләү» – дигән иде. [3]. Әйтергә кирәк, галимә бу юнәлештә дә үзеннән саллы өлеш кертте. 2017 елда «Татар теленең тарихи грамматикасы. Фонетика. Морфология» дип аталган китабы дөнья күрде. Шуны искәртү мөһим: бу хезмәт – татар теленең авазлар системасының, сүз төркемнәре һәм грамматик категорияләренең эволюциясен бер монографиядә чагылдырган беренче фундаменталь хезмәт. Монографиянең беренче бүлегендә автор, татар телендәге вокализм, консонантизм, басым, аваз үзгәрешләре мәсьәләләре белән беррәттән, классик тюркология фәнендә Идел буендагы төрки телләрдә сузыклар күчеше дип аталган катлаулы күренешнең

бәхәсле якларына да (хронологик чикләре, региональ үзенчәлек булу-булмавы, табигате, сәбәпләре, субстрат теориясенә мөнәсәбәте һ.б.) ачыклык кертә. «Морфонология» бүлегендә татар телендәге иҗек калыплары, кушымчалар һәм аларның килеп чыгышы фәнни нигездә анализлана. «Тарихи морфология» бүлегендә исә төрки телләр семьялыгына кергән аерым телләрнең, беренче чиратта татар теленең, грамматик категорияләрен өйрәнү реконструкцияләнгән борынгы төрки нигез телгә, шулай ук төрле региональ төрки телләрнең реконструкцияләнгән нигез телләренә мөнәсәбәттә өйрәнелә.

Монография «Татар теленең тарихи грамматикасы» дип аталса да, хезмәт башка бик күп төрки телләрнең (төрек, чуваш, якут, тува, кыргыз, хакас, алтай һ.б.) тарихи грамматикаларына, төрле чорга караган төрки язма истәлекләре теленә нисбәтле фактлар турында да бай фәнни мәгълүмат бирә, шул рәвешле татар теле тарихи грамматикасының эволюциясен тикшерү чагыштырма-тарихи ысул ярдәмендә тормышка ашырыла. Хезмәттә чыганак материалларын латин графикасына нигезләнгән Халыкара фонетик ассоциация кабул иткән язуда һәм кириллицада бирү, безнең фикеребезчә, үзен аклый.

Ф. Хисамованың фәнни-тикшеренү өлкәләренең берсе – хәзерге татар теле морфологиясе. 2006 елда аның күпьеллык эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак «Татар теле морфологиясе» дәреслеге дөнья күрде. Әлеге хезмәт турында академик М. Зәкиев болай дип яза: «Бу татар теленең морфологик системасын логик эзлеклелектә ачып бирә торган беренче дәреслек булачак» [4; 6]. Хезмәттә морфология, аның өйрәнү объекты, морфемика, сүз ясалышы, сүз төркемнәре һәм аларның грамматик категорияләре турында фәнни яктан төгәл мәгълүмат бирелә. Дәреслектә һәр грамматик күренеш җентекле анализлана, теге яки бу төшенчә белән бәйле бәхәсле фикерләр, карашлар төрлелегә китерелә, автор аларга үз мөнәсәбәтен җиткерә. Хезмәттә белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм морфологик анализ үрнәкләре дә бирелә. Шул рәвешле, бирелдә Фәһимә Миргали кызының фәнни һәм педагогик тәҗрибәсе кушылып, югары дәрәҗәдә эшләнгән хезмәт барлыкка килә. 2015 елда дәреслек яңадан бастырыла.

Ф. Хисамова татар теленең графикасы һәм орфографиясе юнәлешендә дә фәнни тикшеренүләр алып бара. Латин графикасының зарурлыгын беренчеләрдән булып фәнни дәлилләп, «Татар теле: латин әлифбасына кайтуның фәнни нигезләре» фәнни-популяр хезмәтен татар һәм рус телләрендә бастырып чыгара.

Фәһимә Миргали кызы Хисамованың хезмәт юлы Казан дәүләт университеты белән бәйле: башта ассистент, аннан өлкән укытучы, доцент, 1998 елдан профессор вазифаларын башкарды. 1999 елдан 2004 елга кадәр ул татар теле кафедрасы белән җитәкчелек итте. Университетта ул татар теле морфологиясе, тел тарихы, тарихи грамматика, фонетика буенча лекцияләр укый, иске татар теле, язма истәлекләрнең текстологиясе һәм тел үзенчәлекләре фәннәре буенча гамәли дәресләр, махсус курслар алып барды. Аның һәр дәресе үзе бер ачыш иде. Лектор буларак, катлаулы, бәхәсле, теоретик материалларны да үтемле, логик эзлекле итеп җиткерә, конкрет мисаллар белән дәлилле белде. Бу сыйфаты аның хезмәтләрендә дә чагылыш тапты.

Галимәнең фәнни-педагогик эшчәнлеге төрле программалар, вуз дәреслекләре, методик кулланмалары төзү белән үрелеп барды. Ф.Хисамова – «Татар теле морфологиясеннән күнегүләр җыентыгы», «Хәзерге татар теле. Морфология», «Хәзерге татар теле фонетикасы. Студентлар өчен лекцияләр һәм методик күрсәтмәләр» авторы, күп сандагы

программаларның редакторы да.

Фәһимә Миргалиевнаның мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп укучылары, тәрбиячеләре, укытучылары өчен төзелгән методик хезмәтләре дә фәнни-педагогик җәмәгатьчелек арасында лаеклы урынын тапты. «Татар теле өйрәнә нәниләр. Балалар бакчалары тәрбиячеләренә кулланма»сы (автордашы Р. А. Борһанова) тәрбиячеләр өчен әле дә өстәл китабы ролен үти.

Ф.Хисамова гомуми белем бирү оешмалары өчен татар теле дәреслекләре төзүдә дә катнашты. Рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен дәреслекләре Ч.Харисова, Ф.Харисовлар белән авторлыкта берничә тапкыр басылып чыкты.

Тынгысыз галимә телнең үткәне турында гына түгел, киләчәге турында да уйланып яшәде. Халыкара тюркологик конференцияләрнең берсендә ул: «Билгеле инде телнең төзелешен, үзенчәлеген өйрәнү тукталып тормаячак. Моңа кадәр без күбрәк телнең тышкы ягын – структур юнәлешен өйрәндек. Менә хәзер эчтәлек ягы алга чыга: телнең нәкъ үзенең, һәр милли телнең хосусиятен чагылдыра торган һәр кушымчаның, һәр сүз кисәгенең үз мәгънәсе бар һәм аларның сөйләмдә урнашуы тәртибе һәр телдә үзенчәлекле. Хәзер телне өйрәнүдә менә шушы функциональ-тематик юнәлешкә күчү бик әһәмиятле», – дип, тел белеменең киләчәктә үсеш-үзгәреш юлларын, юнәлешләрен дә билгеләгән иде.

Фәһимә ханым – татар халкы, татар милләте, татар теле өчен җан атып йөргән милләтпәрвәр затларның берсе иде. Бер әңгәмәсендә ул: «Татар теле беренче чиратта ул шәхеснең үзенә кирәк. Шул тел аша балаларыбыз рухи һәм җан байлыгы ала, ул шуның аша күңелен баета, туган теле аша уйлый. Татарча белеп үскән бала рухы бай була», – ди. Фәһимә апа белән Нурмөхәммәт абыйның өч баласы да, Дәрвишләр бистәсенә йөреп, татар мәктәбендә белем ала.

Фәһимә Миргали кызы Хисамова җитәкчелегендә күпсанлы кандидатлык диссертацияләре якланды. Хәзерге вакытта төрле уку йортларында, фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә хезмәт куючы шәкертләре Р. Йөзмөхәммәтов, Г. Гарипова, Р. Хөрмәтуллина, Ф. Мөхәммәтшин, В. Фәхретдинова, Л. Садыйкова, М. Сәйхунов, Л.Хисамоваларның эзләнүләре татар теле һәм, гомумән, төрки тел белеменең төрле мәсьәләләрен өйрәнүгә лаеклы өлеш керттеләр.

Көч-егәрен телне өйрәнүгә, үстерү һәм саклауга, фәнгә, студентларга белем бирүгә багышлаган галимнең исеме һәм мирасы татар теле белеме тарихында гына түгел, гомумтюркология фәне тарихында да хаклы рәвештә мактаулы урын алды.

**Әдәбият**

1. Хисамова Ф.М. Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.) – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 399.

2. Грунина Э.А. Ценный вклад в изучение истории тюркских языков (рецензия на книгу. Хисамова Ф.М. Татарский язык в восточной дипломатии России. – Казань: Мастер-Лайн, 1999. – 401 с.) // Фәнгә багышланган гомер: Нурмөхәммәт һәм Фәһимә Хисамоваларның 80 яшьлегенә / Төзүче һәм җаваплы мөхәррир Э.И.Сафина. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 176 б.

3. Фәһимә Хисамова: «Хәзер телне өйрәнүдә функциональ-тематик юнәлешкә күчү бик әһәмиятле» // URL: http://tatar-inform.tatar/news/tatarstan/2011/10/20/70212/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 11.10.2016)

4. Зәкиев М.З. Кафедраның бишенче мөдире // И газиз туган телем! Казан: КДУ нәшр., 2006. – 6 б.

*Султан Исхаков фотосы*

18




# ТӘНКЫЙДИ ФИКЕРЛӘҮНЕ ҮСТЕРҮ ТЕХНОЛОГИЯСЕ АЛЫМНАРЫ

*(Осталык дәресе)*

**Алсу СӘФӘРОВА,**

Казандагы күппрофильле 189 нчы «Заман» гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Хәзерге көндә киләчәген алдан күрә белгән, планлаштыра алган һәм шуны тормышка ашыру юлларын ачык төсмерләгән шәхес кирәк. Мәктәп бусагасын атлап чыгучы үзендә җаваплылык хисе, дисциплина, белем күтәрүгә омтылыш, эзләнүчәнлек кебек сыйфатларга ия булырга тиеш. Ул бүгенге базар икътисады шартларында югалып калмаска, тәнкыйди уйлый һәм мөстәкыйль карарлар кабул итә белергә, ярдәмләшеп эшли һәм аралаша алырга тиеш.

**Максатым –** аралашучан, үз фикерен әйтә белүче, критик һәм креатив фикерләүче, кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль эзли, таба алучы, максатчан шәхес тәрбияләү.

Аралашучан, үз фикерен әйтә белүче шәхес тәрбияләр өчен, беренче чиратта, аның телдән сөйләмен үстерергә кирәк, дип уйлыйм. Укучыларда коммуникатив күнекмәләрне тагы да баету, сөйләмнәрен үстерү максатыннан төрле инновацион технологияләрдән хәбәрдар булу кирәк. Хәзерге көндә мин тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясенә игътибар бирәм.

Тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясе илебез мәгарифенә 1997 елда керә. Аның авторлары – Америка галимнәре Ч.Темпл, К. Мередит, Д. Стилл. Әлеге технологиянең төп максаты – укучыга мөстәкыйль укырга мөмкинлек бирә торган интеллектуаль сәләтләрен үстерү. Критик фикерләү – интерактив, иҗади, рефлексив фикерләү ул. Әлеге фикерләү тибы:

– кешегә шәхси һәм профессиональ тормышындагы үз өстенлекләрен билгеләргә ярдәм итә;

– индивидуаль җаваплылык тоюны күздә тота;

– мәгълүмат белән индивидуаль эш дәрәҗәсен арттыра.

Критик фикерләүне үстерү технологиясенең татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә түбәндәге алымнарын кулланырга мөмкин, дип уйлыйм:

– кластерлар;

– синквейн;

– «Чыганакларны чагыштыру» таблицасы;

– фикерләр кәрзине;

– күрәзә итүләр агачы;

– дөрес/ялгыш фикерләр;

– тукталып уку;

– фишбоун;

– Блум ромашкасы;

– Венна боҗралары һәм башкалар.

Мин Венна боҗралары, икенче төрле Эйлер-Венна диаграммасы, алымын татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яратып кулланам. Әлеге алым инглиз галиме, философы Джон Венн тарафыннан кулланылышка кертелә. 1881 елда дөнья күргән хезмәтендә урын алган. Ул – ике яисә аннан да күбрәк төшенчәләрне, күренешләрне, предметларны чагыштырырга, аларның уртак һәм аермалы якларын ачыкларга кирәк булганда кулланыла торган график ысул.

Венна боҗралары алымы белән эшләү алгоритмы:

– дәрестә чагыштырылырга тиешле ике яисә аннан да күбрәк төшенчәләр, күренешләр ачыклана;

– укучылар боҗралар ясый һәм аларны тутыра;

– билгеләнгән төшенчәләрнең, күренешләрнең уртак һәм аермалы яклары турында укучылар (парларда, төркемнәрдә) фикер алыша.

Укучыларга Венна боҗралары алымы белән эшләү ошый, дип әйтә алам. Алар билгеләнгән тема буенча аермалы һәм уртак якларны җиңел һәм тиз табалар. Аларның һәрберсе эзләнә, мәгълүмат туплый, аның белән эшләргә, кирәклесен генә аерып алырга, төшенчәләрне, күренешләрне сайларга, чагыштырырга, анализларга, системалаштырырга өйрәнә. Шулай ук әлеге алымның соңгы этабында укучылар үз фикерләрен тәкъдим итәләр, аны дәлилиләр, сыйныфташлары ярдәмендә башка яңа һәм кызыклы вариантлар ишетәләр. Бу алымны куллану укучыларда иҗадилыкны, өйрәнелә торган темаларга кызыксынуны арттырды. Венна боҗралары укучының үсешенә юнәлгән, бу исә аның яңа идеяләргә ачык булуы, үз уй-фикерләренең рефлексиясе белән билгеләнә.

Мин Венна боҗралары алымын һәр дәрескә җайлаштырырга тырышам.

Шул рәвешле, педагогик эшчәнлектә инновацион технологияләрне куллану, аерым алганда, тәнкыйди фикерләү үстерү технологиясенең Венна боҗралары алымын файдалану уңай нәтиҗәләргә ирешергә, аралашучан, үз фикерен әйтә белүче, критик һәм креатив фикерләүче, максатчан шәхес тәрбияләргә ярдәм итә.

19




# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЦИФРЛЫ РЕСУРСЛАР

**Айсылу ХӘЙРУЛЛИНА,**

Казан шәһәре Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 71нче татар-рус урта мәктәбенең югары квалификация категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы

Без мәгълүмати технологияләр зур тизлек белән үзгәрә барган, яңа ачышлар ясала торган чорда яшибез. Җәмгыять алга барган саен, белем бирү системасы да үзгәрешләр кертүне, яңача фикерләүгә игътибар бирүне таләп итә. Туган тел укытучысы да заман белән бергә атлап барырга, яңалыклар ташкыны алдында югалып калмаска тиеш.

Мин үзем рус телле балаларга туган тел укытам. Дәресләремне уен технологиясенә нигезләнеп алып барам. Ул чит телне өйрәнгән вакытта кызыксыну уятучы, дәртләндерүче фактор булып тора. Балалар дәресләрдә үзләрен ачып бетермәскә мөмкин, ә төрле уеннар вакытында моңа шартлар тудырыла. Балаларның, беренчедән, үз-үзләренә, икенчедән, үзләре янәшәсендәге иптәшләренә ышанычлары арта.

Яшәешне электрон технологияләр чолгап алган заманда, укучыларга белем бирү процессы да үзгәрешсез кала алмый. Хәзерге заманда компьютер уеннары бик активлашып китте. Шул нисбәттән, мин сезгә туган тел һәм әдәбият дәресләрен мөмкин кадәр заманча, кызыклы һәм сыйфатлы үткәрер өчен онлайн инструментлар җыелмасын тәкъдим итәм.

Цифрлы белем бирү платформаларын куллануны мин шартлы рәвештә ике төркемгә бүлдем: гади цифрлы белем бирү ресурслары һәм катлаулы цифрлы белем бирү ресурслары.

**Гади цифрлы белем бирү ресурслары:** Learningapps, Joyteka, OnlineTestPad, Padlet, Quizlet, Quizziz.

**Катлаулы цифрлы белем бирү ресурслары:** Bookcreator, Flippity, Genially, Ilovepdf, Jigsawplanet, Liveworksheets, Wordwall.

Белгәнебезчә кайбер белем бирү платформалары бүгенге көндә инде эшләми. Ә бу платформалар әле эшли. Хәзер сезгә бу ресурсларны кулланып, нинди уеннар эшләп булуын күрсәтеп узасым килә.

Joyteka – интерактив биремнәр булдыру өчен иң популяр белем бирү платформаларының берсе. Платформа безнең илнеке, Екатеринбург укытучысы Максим Юрьевич Новиков тарафыннан эшләнгән. Бушлай тариф 20 интерактив бирем булдырырга мөмкинлек бирә. Ләкин кайбер квест бүлмәләренә керү чикләүләре бар, алар түләүле. Интерактив биремне төзегәндә, уң якта видеоинструкция барлыкка килә. Шуңа күрә биремнәрне эшләү кыенлык тудырмый. Мин әлеге платформаны квестлар булдыру өчен актив кулланам. Ләкин аның башка мөмкинлекләре дә бар. Андагы веб-квестлар – укучыларда креатив һәм критик фикерләү күнекмәләрен үстерүгә юнәлтелгән. Укучылар, мәгълүматны җыеп кына калмыйча, биремне үтәп, куелган проблеманы хәл итәләр. Квест биремнәрен укучылар бик теләп башкаралар. Әлеге төр эшчәнлекне куллану аларның мотивациясен арттыра. Веб-квестның максаты – шәхси яки төркемләп материалны өйрәнү, биремнәрне үтәү, ә аннары үз проектыңны булдыру. Квест узу яки булдыру белән бәйле эш һәр укучыны актив эзләнергә, иҗади эшчәнлек күнекмәләрен үстерергә, алган белемнәрне яңа контекстта куллану нигезендә барлыкка килә торган проблемаларны хәл итәргә

булыша, бу исә укучыларның фикерләү сәләтенә өйрәтә.

LearningApps.org сервисын кулланып төзегән биремнәрне, уеннарны без инде дистанцион уку вакытында бик уңышлы файдаландык. Бу платформада кроссвордлар чишәргә, пазллар җыярга, парларын табарга, сүзләрне (рәсемнәрне) төркемнәргә урнаштырырга, төшеп калган сүзләрне куярга, викториналар төзергә була. Биремнәрне әзер килеш алып кулланырга да мөмкин, ләкин сайтта укытучы үзе теркәлеп эшләсә, укытучы өчен уңайлырак булачак. Укытучы өчен шунысы уңайлы: биремнәрне тиз арада үзгәртеп, төрле темага, төрле сыйныф өчен яраклаштырырга мөмкин.

«Padlet» ул – укытучы яки укучы тарафыннан булдырылган интерактив такта яки стена. Стена һәрвакыт билгеле бер темага эшләнә. Стенада төрле бүлекләр булырга мөмкин, аларның һәрберсе шул бүлеккә караган материалны үз эченә ала. «Padlet» белдерүләр тактасын төзергә, фикер алышырга, тавыш бирергә, бәяләмәләр җыярга ярдәм итәчәк. «Padlet»та Интернеттан сылтама белән кереп берничә кеше аралаша һәм хезмәттәшлек итә ала. Ул шулай ук класста мәктәп тактасы сыйфатында эшләү өчен дә уңайлы, анда алдан әзерләнгән биремнәрне, мәгълүматны активлаштырып, билгеле бер вакытта җиңел файдаланырга мөмкин. Шул рәвешле, «Padlet» виртуаль такта яки файлларны сакларга мөмкин булган цифрлы дивар дип әйтергә була. Мин бу платформаны укучылар белән бергә проектлар эшләгәндә, виртуаль экскурсияләр оештырганда, онлайн газеталар чыгарганда уңышлы файдаланам.

Мәктәптә рус телле укучыларга туган телне укытуның төп максаты – коммуникатив компетенцияне үстерү, чит телдә мәдәниятара аралашуда катнашырга теләгән һәм алга таба да мөстәкыйль камилләшүгә сәләтле бала шәхесен үстерү. Әмма максатка ирешү сыйфаты, барыннан да элек, шәхеснең ихтыяҗына, аның мотивациясенә бәйле.

Шулай итеп, цифрлы белем бирү ресурсларына нигезләнеп төзелгән уеннарны куллану уңай нәтиҗә бирә, чөнки ул укучыларның эшчәнлеген активлаштырырга, белем бирүне сыйфатлы итәргә, педагогның һөнәри дәрәҗәсен күтәрергә, белем бирү процессында укучыларның аралашу формаларын төрләндерергә мөмкинлек бирә.

Цифрлаштыру – тормышның аерылгысыз өлеше, шуңа күрә аннан өйгә кереп качып, күрмәмешкә салышудан мәгънә бар дип уйламыйм. Әлбәттә, һәр нәрсәнең чиге булырга тиеш. Әгәр теләсә кайсы даруны күбрәк куллансаң, ул агуга әйләнергә мөмкин. Санлаштыру белән дә шул ук хәл. Безгә гаҗәеп мөмкинлекләр биргән цифрлаштыруны файдалы итеп куллана белергә кирәк.

**Берничә уенга QR-код**:

20



# ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫКНЫ ҮСТЕРҮ

**Лариса ИСМӘГЫЙЛОВА,**

Казан шәһәренең 39 нчы мәктәбенең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартларында әйтелгәнчә, бүгенге шартларда укучыларның функциональ грамоталыгын үстерү иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора, һәм ул, беренче чиратта, укытучының функциональ грамоталыгы дәрәҗәсе белән тыгыз бәйләнгән[1]. Әлеге мөһим мәсьәләне хәл итү максатыннан, Казан шәһәре 39 нчы муниципаль автономияле гомуми белем бирү мәктәбенең педагогик коллективы эзлекле һәм системалы эш алып бара. Агымдагы уку елында педагогик эшчәнлек «Белем һәм тәрбия бирүнең югары сыйфатына ирешү факторы буларак укучыларның функциональ грамоталыгын үстерү» дигән фәнни-методик теманы гамәлгә ашыруга юнәлтелгән[2]. Мәктәпнең төп максаты – иҗади, социаль һәм профессиональ яктан компетентлы шәхес тәрбияләү өчен, барлык мөмкинлекләр булдыру һәм шартлар тудыру. Куелган максатка ирешү өчен, мәктәптә эшләүче һәр укытучы үз фәне буенча белем бирүнең сыйфатын тагын да яхшыртырга омтыла, заманча педагогик технологияләрдән файдалана, үзенең методик осталыгын өзлексез арттыруның кирәклеген аңлап эш итә. Бүгенге көндә төп игътибар укучыларның функциональ грамоталыгын үстерүгә юнәлтелә, чөнки әлеге мәсьәлә иң мөһимнәрдән санала.

Галимнәр һәм педагоглар фикеренчә, функциональ грамоталык формалаштыру өчен, уку-укыту процессына кайбер үзгәрешләр кертү сорала. Алар арасында иң әһәмиятлеләре: дәресләрдә укучыларның гамәли эшчәнлеген тәэмин итә торган ситуацияләр куллану; коллективта, төркемдә яки парлап аралашу аша яңа белемнәрне үзләштерүгә ирешү; эзләнүгә корылган төрле биремнәр эшләтү һәм проектлар яклатуга өстенлек бирү; укучыларны мөстәкыйль рәвештә үзбәя бирергә күнектерү[3](25 б).

Алдыбызда торган актуаль бурычларны исәпкә алып, мәктәптә «Педагогның функциональ грамоталыгыннан укучыларның функциональ грамоталыгына ирешү» дигән темага педагогик совет утырышы үткәрелде. Анда укытучылар алдынгы эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Мәсәлән, башлангыч мәктәп укытучылары балаларның уку грамоталыгын үстерүгә юнәлтелгән дәрес эшкәртмәләре белән таныштырдылар. Татар теле, рус теле, инглиз теле укытучылары укучыларның функциональ грамоталыгын формалаштыру максатыннан үткәрелгән сыйныфтан тыш чараларның эшкәртмәләрен тәкъдим иттеләр. Мисал буларак укучыларның төрле темаларга эшләнгән иҗади эшләре күрсәтелде. («Укыйбыз һәм укыганның эчтәлегенә карата үз мөнәсәбәтебезне белдерәбез: моңсуланабыз, шатланабыз, гаҗәпләнәбез»; «Кемне чын китап укучы дип атап була?») Технология укытучылары укучыларның функциональ грамоталыгын формалаштыруга багышланган мастер-класс күрсәттеләр. Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, мәктәп укытучылары әлеге юнәлештә максатчан эш алып баралар. Кайсы гына дәресне алсак та, укытучы балаларны, беренче чиратта, мәгълүматны кабул итәргә, аңларга һәм аның нигезендә үз текстын булдырырга өйрәтә. Әлеге эшкә рус теле, әдәбият, туган тел укытучылары аерым игътибар бирәләр. Функциональ грамоталык турында сүз алып барганда, беренчедән, алган белемнәрне тормышта куллану күнекмәләре булдыруны күз алдында тотабыз: яңа мәгълүматны табу, аның

дөреслеген раслау, шуның нигезендә мөстәкыйль эшчәнлек оештыра алу. Проблемалы биремнәрне эшләгәндә, укучыларның максатчанлыгы, фикерләү сәләте, аралашу культурасы үсеш ала. Аңлашыла ки, укучыларда шундый күнекмәләр булдыру өчен, укытучы үзе дә әлеге сыйфатларга ия булырга тиеш. Педагогик тәҗрибә күрсәткәнчә, укучыларның функциональ грамоталыгы үсеш алсын өчен, берничә таләпне үтәргә кирәк: аларның тәнкыйди фикер йөртү һәм коммуникатив күнекмәләрен үстерү; фикер алышуларда катнашып, үз мөнәсәбәтен телдән яки язмача белдерергә күнектерү; дөньяны танып белү процессын оештырырга өйрәтү (максат кую, план төзү, кирәкле карарны кабул итү, анализлау, нәтиҗә ясау һ.б.).

Без 39 нчы мәктәпнең туган тел һәм әдәбият укытучылары барыбыз да рус төркемнәрендә «Сәлам» УМКсына нигезләнеп белем бирәбез. «Сәлам» УМКсында түбәндәге функциональ грамоталылыклар исәпкә алынган.

(2 нче слайд)

**1. Компьютер грамоталылыгы үсеше өчен җирлек тудыру. ( 3нче слайд)**

Эш төрләре:

– Өй эше итеп Интернет чыганакларыннан мәгълүмат табып килергә.

– Проект эшләрен башкару.

–Диаграммалар төзеп килү һ.б.

**2. Коммуникатив грамоталылык үсеше өчен җирлек тудыру. (4 нче слайд)**

Эш төрләре:

– Төркемнәрдә эш.

–Текстка сораулар уйлау.

– Диалоглар төзү.

– Репликалар өстәү.

**3. Чит телне үзләштерү грамоталылыгы (рус телле укучылар татар телен чит тел буларак өйрәнәләр). (5 нче слайд)**

– Яңа сүзләр өйрәнү.

– Сүзлекләр белән эш.

**4. Көнкүреш проблемаларын хәл итү грамоталылыгы. (6 нчы слайд)**

Мәсәлән, «Ашамлыклар» темасында кибеттә сатып алырга, сайлап алырга өйрәнәләр; «Өем зур» темасы – җиһазлар, бүлмәләр, өйдәге техникалар, савыт-саба белән танышу һ.б.

**5. Финанс грамоталылыгы үсеше өчен җирлек тудыру. (7 нче слайд)**

Мәсәлән, мегаполис, шәһәрләр, кечкенә шәһәрләр турында сөйләшкәндә, кайда яшәү яхшырак? Ни өчен; эш хакы турында сөйләшү һ.б.

**6. Уку грамоталылыгы – функциональ грамоталылыкның иң мөһим өлеше. Ул – укучыда текстларны аңлау, куллану, бәяләү, алар турында уйлау сәләтен үстерә.**

**Эш төрләре. (8, 9, 10 нчы слайдлар)**

– Текстларны укыйлар, тәрҗемә итәләр, сүзлек өстендә эшлиләр, сорауларга җавап бирәләр;

– Текст буенча өстәмә биремнәр – дөрес/ялгыш, тоташтыр, җөмлә төзе, абзацларга исем бир, план төзе, төшеп калган сүзләр белән текст (аудиоязма тыңлыйлар);

– Җыр текстлары укыйлар, җырлыйлар;

–Тексттагы рәсемнәрне сүзләр белән алмаштыру;

«Сәлам» УМКсы белән танышуны йомгаклап шуны әйтеп була: дәреслектә функциональ грамоталылыкка карата барлык юнәлешләр дә кулланылган.

Булган мәгълүматны укып, язу белән ныгыту, аңлаганны, истә калганны башкаларга җиткерү һ.б.

Функциональ грамоталылык ул кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәтләргә керү һәм анда

җайлашу һәм эзләнү сәләтен күзаллый. Ә «Сәлам» УМКсында уеннар аша, кешенең чын тормышын күрсәтү һәм ачып бирү чагыла. Уенда булган ситуацияләр соңыннан кайчандыр гамәлгә ашырылачаклар. Укучылар уен аша үзләре «тормышта катнашып» карыйлар.

Татар телен чит тел буларак укытканда, уку грамоталылыгының төп компонентлары:

сүз байлыгын киңәйтү

контексттан таныш булмаган сүзләрне аңлау

грамматик категорияләрне ныгыту

сөйләм күнекмәләрен камилләштерү

Эш вакытында укучыларда универсаль уку гамәлләре формалаша: танып белү, коммуникатив, регулятив, шәхси.

Әйдәгез, «Сәлам» УМКсы тәкъдим иткән текст өстендә эш формалары белән танышыйк. (3 нче сыйныф дәреслеге)

**Текст өстендә эшләүнең 3 этабы бар.**

1. Укуга кадәр.
2. Уку вакыты.
3. Укудан соң.

**Укуга кадәрге этап :**

Бу этапта укучыда мотивация тудырабыз, тел һәм сөйләм авырлыкларын киметү өстендә эшлибез. (11 нче слайд)

1.Текст белән танышуны мәкальдән башлап җибәреп була. (12нче слайд)

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» – бу мәкаль нинди максат белән язылган?

2.Текстның исеме белән бәйле ассоциацияләрне әйтү (сәламәтлек, саф һава һ.б.).

3. Рәсемнәр ярдәмендә текстның тематикасын уйлау. (13 нче слайд)

**Уку вакыты этабы:**

**Бу этапта укучыларның тел күнекмәләрен үстерү, сөйләм осталыкларын киңәйтү өстендә эшлибез. (13 нче слайд)**

**Күнегүләр. (14 нче слайд)**

1. Текстта сорауларга җавап тап.
2. Дөресме/ ялгышмы.
3. Җөмләләрне тәртип буенча урнаштыр һ.б.

**Укудан соң этап. (15 нче слайд)**

**Бу этапта укучыларда тел һәм язу күнекмәләрен, танып белү активлыгын үстерәбез. (16 нчы слайд)**

Укучылар текстның төп фикерен әйтәләр, текстны өлешләргә бүләләр, план төзиләр һәм, планга таянып, текстны сөйлиләр.

Йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: укучыларның функциональ грамоталыгын үстерү яшь буынны үзгәреп тора торган тормыш шартларында үзара хезмәттәшлеккә әзерләүне үз эченә ала. Әлеге юнәлештә уңышка ирешү өчен, мәктәпнең педагогик коллективының бердәм эшчәнлек алып баруы зарур.

***Әдәбият исемлеге***

[1] ФГОС ООО https://www.garant.ru/products/ipo/prime/doc/401333920/ (дата обращения 15.01.2022).

[2] Сайт МАОУ «СОШ №39» https://edu.tatar.ru/vahit/kzn/sch39 (дата обращения 15.01.2022).

[3] Фролова П.И. К вопросу об историческом развитии понятия «Функциональная грамотность» в педагогической теории и практике // Наука о человеке: гуманитарные исследования. 2016. №1 (23). URL: https://cyberleninka.ru/article/n/k-voprosu-ob-istoricheskom-razvitii-ponyatiya-funktsionalnaya-gramotnost-v-pedagogicheskoy-teorii-i-praktike (дата обращения: 15.01.2022).

[4] Мониторинг формирования функциональной грамотности http://skiv.instrao.ru/support/demonstratsionnye-materialya/ (дата обращения: 15.01.2022).